Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

2
февраль 2021
ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

Татарлар һәм удмуртлар

18 бит

Җәүһәр иясе Җәүһәриягә

32 бит

МУСА ҖӘЛИЛ

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +

2
(326)
февраль 2021

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рузәл Мөхәммәтшин
Григорий Родионов (Гәрәй Рәхим)
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Ирек Шәрипов
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Ләйлә Лерон
(843) 222-09-83 (17-92)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

**«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал
(на татарском и русском языках)**

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Хакимҗан Халиков

ТАРИХИ МИРАС

4 Тимербәкнең ил-йортына сәяхәт (1404-1406) көндәлеге. *Руи Гонсалес де Клавихо*
8 Бәҗәнәкләр. *Л.Гобәйдуллин*
10 Казан ханлыгында салымнар. *Н.Гариф*
12 Хәзәрләр сабагы. *Ф.Нафиев*
18 Татарлар һәм удмуртлар. *И.Газизуллин*
24 Әҗегә археографик сәфәр. *М.Госманов*
29 Коточкыч ачлык. *Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин*

ТАТАР ГАМЕ

32 Җәүһәр иясе Җәүһәриягә. *Ә.Зарипов*

ДИНИ МИРАС

40 Ислам дөньясы. *Габдрәшит Ибраһимов*
46 Мәңгелеккә юнәлеш. *И.Таһиров*

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

52 Мөхәммәд (с.г.в.) сөннәте һәм татар галимнәре. *Р.Файзрахманов*

ӘДӘБИ МИРАС

56 Безнең өчен мәңге изге йорт... *Г.Төхвәтова, Л.Медведева*
60 Садрый Хәмид (1905-1987) шигырьләре
64 Хәсән Туфан ядкяре
68 Тукай һәйкәле янында. *С.Баттал*
70 Сыкрау. *Р.Туфитуллова*
74 Горурлык хисе. *Э.Шәрифуллина*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

80 Мөгаллим язмалары. *Ф.Садыйков*
86 Кара тәкъдир. *Р.Батулла*
88 Истә, һаман да истә!

ФИКЕР ДӘРЬЯСЫ

90 Нигез. *Р.Садриев*
94 Театр яктысы. *Р.Сәгъди*

СӘНГАТИ МИРАС

96 Затлы дәвам фестивале. *Г.Сафиуллина*
104 Чал тарихка бер караш. *М.Хәбибуллин*
110 Татар җырчылары. Кадерле мизгелләр. *З.Гыйльметдинова*
112 «Тәфтиләү» җыры

ШАЯН МИРАС

114 Көлке куа килә...

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Февраль*



Заказ №А-Е-237. Тираж – 2470 данә. Формат 70х100 $^1/_{16}$
Басарга кул куелды: 28.01.2021. Чыгу көне: 02.02.2021.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән әзерләнде.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә: Муса Җәлил Татар рабфагын тәмамлаганда, чыгарылыш альбомына төшкән фоторәсем (1925 ел). Фото Татарстан Республикасының Милли музее фондыннан алынды

Хәзинәләр диңгезе
Син бит, Ватаным минем –
Татарстаным минем!

Хакимҗан Халиков

Шигырь бәйрәмендә журналист Нургали Булатов (сулда) белән. 26 апрель, 1974 ел

Хакимҗан Халиков

(16.01.1933-12.02.2002)

Туган телем*

Нинди җәберләр күрмәгәнсең син,
Алай да ничек үлмәгәнсең син?!
Бабаларымның иң зур мирасы,
Сынмас канатым кебек миңа син.
И туган телем,
Ягымлы сүзең,
Күрсәтәсең син
Халкымның йөзен.

Хәтта кошның да туган теле бар,
Теле булганның гына иле бар.
И туган телем, үсә бар һаман,
Яңа чорларга күчә бар һаман.
Яшә мәңгегә,
И татлы телем,
Һәр сүзең энҗе,
И затлы телем. ■

* Мәсгудә Шәмсетдинова көе.

*Текстны журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.*

Тимербәкнең ил-йортына сәяхәт (1404-1406) көндәлеге

Руи Гонсалес де Клавихо

Испан сәяхәтчесе, дипломат, язучы, тарихчы Руи Гонсалес де Клавихо XIV гасырда Мадридта туган. Испания короленең Тимербәк ил-йортына җибәргән илчелеге уңышлы эш йөртеп әйләнеп кайтканнан соң, Руи Гонсалес де Клавихоны король 1404 елда икенче тапкыр оештырылган илчелекнең башлыгы итеп билгели.

Корольнең Тимербәккә юлланган хатын алып, ул 1404 елның май аенда яраннары белән юлга кузгала һәм сентябрь аенда Сәмаркандка барып җитә. Шунда яшәгән чорында ул Европа дин әһелләре «икенче Чыңгыз хан» дип атап йөрткән, дөньяны тетрәтеп торган Тимербәкне еш кына якыннан күрә, аның кыяфәтен, холык-фигылен сурәтли, ил-йортындагы хәлләрне тәфсилләп көндәлегенә язып бара. 1405 елда Тимербәк үлгәннән соң, Руи Гонсалес де Клавихо яңадан үз иленә кайту хәстәренә керешә һәм 1406 елның мартында Кастилиягә кайтып җитә. Картлык көнендә ул, дәүләт эшләреннән читләшеп, юлъязмаларын тәртипкә китерү белән шөгыльләнә.

Руи Гонсалес де Клавихо 1412 елда Мадридта дөнья куя.

Марсель Галиев

Бөек зат Тимербәк (Тимерләнг), Сәмаркандның әмирен юк иткәннән соң, анда үз хакимиятен җәелдереп җибәрә; сез моны алдарак күрерсез, аннары ул Кече Һиндстан чигенәчә җәелгән бөтен Могулстанны яулап ала.

Тимербәк аннары Хорасан мәмләкәтенә кергән җирләрне, Рей дип аталган таҗик йортын, Фарсы һәм Мидия, Тәбриз һәм Солтанияне басып ала. Аннары Дербент җирләрен дә үз биләмәсенә кертеп, Эрзинҗән җирләре белән Кече Әрмәнстанны, Көрдестанны буйсындыра. Яуларда җиңеп чыгып, Кече Азиянең күп җирләрен, Һалип, Бабил, Багдадларны яулап алып, Дәмәшекъне җимергәннән соң, ул гаскәрләрен дөньяда иң шөһрәтле патша дип танылган төрек илбашы Баязид Елдырымга каршы юнәлтә, Анкара кальгасы янында Баязидның үзен һәм улларының берсен әсир итә; олуг һәм данлы галиҗәнап Энрике илчеләре, Кастилия һәм Леон короле (Ходай аңа саулык иңдерсен) ризалыгы белән, җибәрелгән Пайо белән Эрнан Санчес бу яу-орышның шаһиты булалар. Алар Тимербәк һәм Елдырым гаскәренең нинди көчкә ия икәнен белү һәм сугышның барышын күзәтү өчен җибәреләләр. Пайо белән Эрнан Санчес хакында белүгә, Тимербәк, Кастилия королена хөрмәт йөзеннән аларга зур кунакчыллык күрсәтеп, үз янына чакыртып бәйрәм ясый, бүләкләр бирә, шул арада христиан корольләре арасында мәртәбәле саналган Кастилиянең данлыклы илбашы хакында мәгълүмат ала; аның белән аркадаш мөнәсәбәтләр урнаштыру өчен, яудан соң бүләк, юллама белән, аңа илче җибәрә. Илче булып Мөхәммәт Әлкаги бара һәм Кастилия королена Тимербәкнең юлламасын, кыйммәтле бүләкләрен һәм, үз гадәтләренчә, кәнизәкләр тапшыра. Галиҗәнап король, Тимербәк юллаган тантаналы хатны, илче тарафыннан әйтелгән җылы сүзләрне кабул итеп, дуслыкны ныгыту өчен бүләкләр әзерләргә һәм Тимербәккә үз ягыннан илчеләр җибәрергә боера. Болар – дин эшләре буенча магистр Руи Альфонс Паэс де Санта Мария, Руи де Гонсалес Клавихо һәм үзенең тән сакчысы Гомес де Саласар. Бик еракка кузгалган илчеләрнең хәл-әхвәле, күз күрмәгән ил-җирләр турында онытылганчы язып бару бик тә кулай булыр дигән нәтиҗәгә киленде. Кадистан ерак түгел Изге Мария портына җитүгә үк, безнең белән Тимербәк илчесе дә кузгалды. Бар да Ходай кулында, аның ярлыкавы астында. Изге Марья хакына багышлап яза башладым.

28 августта, атнакич, төш вакытларында Кеш дигән зур гына шәһәргә килеп җиттек. Шәһәр һәрьяклап сугару канаулары, инешләр белән чуарланган, бакчалы йортлар рәте күз күреме ераклыкларга җәелгән, бу җирләр җәен бик хозур буладыр. Сугарулы кырларда бодай, мамык игәләр, бакчаларда йөзем, кавын, һәртөрле җимеш агачлары үстерәләр икән. Кала үзе дамба белән уратып алынган, тирән урлар аша үтеп, күтәртмәле капкалардан керәсең. Тимербәкнең әтисе дә, үзе дә шушы Кеш каласында туып үскәннәр. Монда зур-зур биналар, мәчетләр, бигрәк тә берсе, Тимербәк әмере белән төзелә башлаганы, мәһабәт күренә. Аның ихатасында Тимербәкнең әтисе җирләнгән төрбә бар. Икенче төрбәне Тимербәк үзе өчен дип төзетә башлаган. Бер ай элек ул монда килеп киткән дә, имеш, канәгатьсезлек белдергән, төрбәнең ишеге тәбәнәк, дип, үзгәртергә боерган. Без күргәндә анда осталар эшли иде. Мәчеттә исә аның беренче улы Җиһангир җирләнгән икән. Бу мәчет һәм андагы төрбә бик бай, алтынланган ачык зәңгәр төсләр белән бизәкләп-сырлап эшләнгән, тирәягы фонтанлы бакча эченә чумган. Әтисенең һәм улының җәсәде күмелгән бу мәчеткә, Тимербәк әмере буенча, сәдака рәвешендә, көн саен яңа суелган ике дистә бәрән түшкәсе җибәрелеп тора.

Кеш каласына җитүгә үк, илчеләрне шушы мәчеткә алып килделәр, бик мулдан ит, төрледән-төрле җиләк-җимешләр белән сыйладылар. Тамак ялгаганнан соң инде, зур сарайга алып килеп, торыр урыныбызны җайладылар.

Җомга көнне илчеләргә илбашы күрсәтмәсе белән салынган зур сарайны тамаша кылдырдылар. Әйтүләре буенча, монда егерме ел буена туктаусыз эш барган. Хәзер дә әле анда, әле монда нидер эшләп йөргән осталар күзгә чалына иде. Сарайның биек капкасы биниһая зур, керә-керешли, уңда да, сулда да – кирпечтән хикмәтле сыр-бизәкләр белән эшләнгән аркалар. Шул аркалар астында ишексез генә уемтыклар. Бизәкле идәнле бу уемтыкларда Тимербәк сарайда чакта кешеләр утырып тора икән. Зур капкадан керүгә, тагын капкалар ачыла, аннары ак таш җәелгән, бик бай бизәкләргә күмелгән галереялы олы ишегалды мәйданына килеп чыгасың. Мәйдан уртасында зур бассейн, ишегалды киңлеккә өч йөз адымнар булыр, түрдә – сарайның иң мәһабәт өлеше, зур ишеге алтынланган бизәкләр уелып, гаҗәеп сәнгатьле эшләнгән, ишек өстендә – кояш эчендәге арыслан сурәте, як-якта да шундый ук сурәтләр. Бу инде Сәмәрканд хакиме тугърасы була. Сарай Тимербәк әмере белән салынды дисәләр дә, монда төзелеш элеккеге хаким чорында ук кузгатылган, чөнки кояш уртасындагы арыслан сурәте шуның тугърасы, ә Тимербәкнеке исә өч түгәрәктән тора. Мәгънәсе «дөньяның өч тарафында хакимлек итәм» дигәнне аңлата. Бу герб-туграны акчаларга сугарга, ясалган бөтен әйберне дә шуның белән тамгаларга боерылган. «О» хәрефе сыман өч түгәрәк хакимнең мөһерендә дә чагыла. Тимербәк үзенә буйсындырылып, ясак түләп торучы илләрнең дә тәңкәләренә шундый ук тамга сугарга әмер биргән.

Шушы мәһабәт ишектән алтынлап, ак-зәңгәр төсләрдә бизәкләнгән залга үтәсең. Түшәме — тоташ алтыннан. Илчеләрне икенче катка алып менделәр. Бөтен сарай эче гаҗәеп төстәге бизәкләргә, алтынга чумганлыктан, моны хәтта тел белән сурәтләп бирү дә мөмкин түгел, хәтта осталарга бай искиткеч Парижда да моны югары бәһаләрләр иде.

Аннары хакимнең хатыннары белән ял итә торган бүлмәләрен күрсәттеләр. Идән-түшәм, диварлар искиткеч гүзәллек белән эшләнгән. Шулай булмыйча, монда бит бихисап осталарның кулы кергән. Аннары хакимнең мәҗлес үткәрә торган олы залына таба алып киттеләр. Анда кергәнче, әллә нинди җимеш агачлары күләгәсеннән фонтаннар атып торган, бассейннар белән чуарланган бакча аша уздык. Шулкадәр бай, зиннәтле иде ки бу сарай, аны сурәтләү өчен ашыкмыйча гына йөреп, барын да карап чыгарга кирәк. Мондагы мәчет һәм сарай — Тимербәк әлегә кадәр төзеткәннәрнең иң күркәме. Бу күркәм биналарны ул шушында туып үсеп, шушында җирләнгән әткәсе рухына багышлап кордырган. Шушы калада туса да, Тимербәк үзе төп чыгышы белән монда яшәүче кавемнән түгел, ул татарларга караган чыгытай кавеменнән. Икенче тапкыр яулап алып хакимлек иткән чорда бу кавем Тарталиядән килгән (бу хакта әле искәртербез) һәм монда чыгытай дип атала башлаган.

Тимербәкнең әтисе чыгытай кавеменнән чыккан вөҗданлы кеше була, уртача яши, саны өч-дүрттән артмаган җайдак тота. Кеш шәһәренең үзендә түгел, ә аксөякләргә хас булганча, кала читендәге авылда, табигатьтә яши. Аның улы Тимербәк тә башта җан асрарлык кына мөлкәткә ия була, дүрт-биш җайдак кына тотарга хәленнән килә. Мин моны шушындагы кешеләр сөйләгәнгә таянып, ышанып язам. Бервакыт ул, үзенең кул астындагы укчы җайдаклары белән кавемдәшләренә һөҗүм итеп, әле бәрән, әле эре мал хайванын тартып алып, мәҗлес оештыра башлый. Бәлки, аның кыюлыгы, соңгы кабымлыгын да бүлешә алу юмартлыгы тәэсир иткәндер, күпмедер вакыт үтүгә, аның кул астында инде өч йөз җайдак туплана. Шундый

көчкә ия булгач, ул күрше җирләргә һөҗүмнәр оештыра, олы юлдан үтүче сәүдә кәрваннарын талап, юлбасарлык итә башлый. Аның турындагы хәбәрләр Сәмәрканд әмиренә дә барып ирешә. Ул Тимербәкне тотып алып, җәзалап үтерергә боера. Сәмәрканд әмире сараендагы берничә аксөяк чыгытай кавеменнән була. Алар Тимербәкне шундый итеп аклап күрсәтәләр ки, ахырда әмир аны гафу итә һәм, сарайга алдырып, үз янында яшәргә рөхсәт бирә. Ә теге чыгытай аксөякләре Гомәр Табар, Ходайдад морза – хәзерге Тимербәк сараенда. Ул аларны зур дәрәҗәгә күтәргән, бай җирләр бүлеп биргән. Тимербәк, имеш, Сәмәрканд әмиренең сараенда яшәгәндә шундый астыртын эшләр алып барган ки, түземе төкәнгән әмир аны үтертергә әзер була. Әмма Тимербәкне алдан кисәтеп өлгерәләр. Ул үзенең яраннары белән качып китә һәм тагын юлбасарлык кыла башлый. Тимербәк бервакыт бик бай сәүдә кәрванын талауга ирешә. Аннан соң ул, көтүлекләргә бай Систан дип аталган якларга китеп, аяклы мал талау белән шөгыльләнә. Бу вакытта инде аның биш йөзләп атлы укчысы була. Бу бәлагә каршы Систан халкы берләшә. Бервакыт төнлә сарык җәйләвенә басып кергәч, систанлылар угрыларны төрле яктан уратып алалар, Тимербәкне ияреннән сөйрәп төшерәләр, шунда аның уң аягы яраланып, гомерлек аксак булып кала, шулай ук уң кулын да яралыйлар, ике бармагы кылычтан өзелә, систанлылар һуштан язган Тимербәкне үлгән дип ташлап калдыралар. Аңына килеп, ул шуыша-шуыша даладагы күчмәннәр чатырына барып җитә. Хәл кергәч, алардан китеп, тирәсенә тагын тугры кешеләр туплый башлый.

> **«**
> **Тимербәк, имеш, Сәмәрканд әмиренең сараенда яшәгәндә шундый астыртын эшләр алып барган ки, түземе төкәнгән әмир аны үтертергә әзер була. Әмма Тимербәкне алдан кисәтеп өлгерәләр.**

Сәмәрканд әмирен исә күпләр яратмый, яраннары да, гади халык та, аксөякләрнең дә күбесе аны күралмый. Әгәр әмирне юк итә алсаң, хаким итеп сине куябыз, дип, алар Тимербәкне әмиргә каршы котырта башлыйлар. Шундый хәл килеп чыга: әмир Сәмәркандтан ерак түгел бер шәһәргә юл тоткан чакта, Тимербәк моңа һөҗүм ясый, теге тауларга качып китә, анда яшәүче берәүгә юлыгып, яраларын бәйләвен, үзен яшереп тотуын үтенә, соңыннан мин сине баетырмын, дип, аңа бик кыйммәтле йөзеген салып бирә. Теге кеше исә моның хакында Тимербәккә җиткерә. Ул, тиз генә килеп җитеп, әмирне үтерә. Тимербәк шуннан соң Сәмәркандны үз кулына төшерә, элеккеге хакимнең хатынына өйләнә. Биби ханым хәзерге көндә Тимербәкнең иң олы хатыны санала. Шуннан соң Тимербәк, ике бертуганның үзара килешә алмавыннан файдаланып, ягъни берсен үз ягына аударып, Хорасан мәмләкәтен басып алуга ирешә. Шулай итеп ул, Хорасан һәм Сәмәрканд йортын берләштереп, үз дәүләтенә нигез сала.

Тимербәккә баштан ук ярдәм итеп, иңен куючылар арасында үз кавеменнән булган бик тугрылыклы чыгытай егете була. Ул аңа үзенең сеңлесен кияүгә бирә, аны күпсанлы гаскәр башлыгы итеп куя. Әлеге затның улы Җиһаншаһ морза — бүгенге көндә хакимнең иң якыны. Ул бик күп җирләргә хуҗа, төп гаскәр башлыгы, Тимербәктән кала ул иң көчле хакимияткә ия һәм аңа буйсынучылар канәгать.

*Текстны журналга **Марсель Галиев** әзерләде.*
Дәвамы бар ■

Бәҗәнәкләр

IX-X гасырлардагы төрки сугышчы

Бәҗәнәкләр – VIII-IX гасырларда Идел елгасының уң як ярында оешкан күчмә төрки кабиләләр берләшмәсе. Димәк, күпмедер дәрәҗәдә алар татар халкының этник үсешендә роль уйнаганнар. Татар халкы тарихы турындагы барлык китапларда да аларның исеме бар.

Бәҗәнәкләр күчмә тормыш алып барганнар, терлекчелек һәм барымтачылык белән шөгыльләнгәннәр һәм, әлбәттә, оста яугир, мәргәннәр булганнар. Алар Византия белән Киев Русе арасындагы транзит сәүдәне кулда тотканнар.

Бәҗәнәкләр IX гасырның икенче яртысыннан Кара диңгезнең төньягындагы далалардан хәзерге Румыния белән Украина чигенә чаклы, ягъни Дунай елгасы тамагына кадәрле җирләрне биләгәннәр.

Алар күрше дәүләтләргә, аеруча Венгрия белән Руська яу чабып, анда яшәүче халыкны еш борчып торганнар.

Бәҗәнәкләр 965 елда Киев кенәзе Святослав белән бергә Хәзәр каһанлыгына һөҗүм итәләр.

1036 елда бөек кенәз Ярослав Мудрый Киев шәһәре янында бәҗәнәкләрне җиңә.

Бәҗәнәкләр 11 нче йөзнең уртасында Карпат таулары тарафына, Дунайның урта агымына табарак күченәләр. Бу җирләрнең хуҗасы булу өчен 1040-1090 нчы елларда аларга Византия белән көрәшергә туры килә.



VIII-X гасырлардагы картада бәҗәнәкләрнең (печенеги) урнашу урыны. ***С.А.Плетнева***

IX-X гасырлардагы төрки сугышчы.
Ю.С.Худяков реконструкциясе

Әмма византиялеләр, кыпчаклар (шулай ук төрки кавем) белән солых төзеп, бәҗәнәкләрне тар-мар итә.

Нәтиҗәдә, бәҗәнәкләрнең бер өлеше янәдән Киев Русенең чик буйларына әйләнеп кайта. Анда исә алар без тарихи чыганаклардан укып белгән «чёрные клобуки», ягъни каракалпаклар берләшмәсен төзүдә катнашалар, Русь белән башка күчмә төрки кабиләләр арасындагы буфер зонага урнашып, казаклар (сословие) башкарган кебек хезмәтне үтиләр, дәүләт чиген саклыйлар.

XII гасырда бәҗәнәкләр, кыпчакларга һәм Дунай буйларында яшәүче башка халыкларга кушылып, аларның этник үсешендә сизелерлек роль уйныйлар. Шуннан соң алар, ассимиляцияләнеп, Европада төрки кан калдырып, тарихи аренадан юкка чыгалар.

Журналга ***Ленар Гобәйдуллин***
әзерләде. ■

Безнең мирас №2 февраль 2021

Казан ханлыгында салымнар

Нурулла Гариф

Казан ханлыгында салымнарның зур өлеше берничә төргә бүленә:

1) Дәүләт һәм идарә системасын тотуга киткән җыемнар (ясак, калан, салыг, кулуш, хәреҗ, сусун, илче яки кунак тоту, даруг салымы);

2) Хәрби хезмәт һәм сугышка бәйле җыемнар (салыг, мөсми, хәрәҗәт, глүфә, сусун);

3) Җирле феодал-хаким, тархан, бәк, угланнар җыемнары (салыг, мөсми, глүфә, кулуш, хәреҗ, хәреҗ-анбар, сала хәреҗе);

4) Сәүдә белән бәйле җыемнар (баҗ, тамга, хәреҗ-анбар);

5) Дини җыемнар (гошер, зәкят, җөзъи, мөсми).

Хәзер аларга аерым-аерым тукталыйк:

1. Ясак (монгол телендә – боерык, канун, кагыйдә мәгънәсендә) – байлыкның уннан бер өлеше дәүләт хисабына җыелган.

2. Калан – эшкәртелгән җирләр хисабыннан түләнмә. Ул утрак тормышта яшәп җир эшкәрткән халыклардан җир һәм терлек исәбеннән натуралата алына торган салым.

3. Салыг – кеше башыннан (саныннан) түләнгән салым. Әлеге салым төре Алтын Урда дәүләте, Кырым ханлыгы ярлыкларында да искә алына.

4. Мөсми – балигъ булган ир кешеләргә салынган салым төре. Мөсми-мөсафир (юлчы, юлаучы, кунак) мәгънәсендәге әлеге салымның юлчылардан яисә, киресенчә, юлга чыгучы гаскәриләр өчен җыелган булуы да мөмкин.

5. Кулуш – кул эше, һөнәрчелек белән бәйле рәвештә түләнгән салым дип уйларга кирәк. Ул Казан ханлыгында хакимнәргә кайгылы яисә истәлекле вакытларда бирелгән бүләк (салым) буларак күзаллана.

6. Култка – хәрби кол. Ярлык бирелгән хуҗаларының колларына һәм бәйле кешеләренә салынган.

7. Баҗ – игенчеләр тарафыннан шәһәр һәм зур авыллар базарларында икмәк, яшелчә, җиләк-җимеш сатуга бәйле җыем салымы (юл салымы). «Баҗ» терминын рус телендәге «пошлина» белән чагыштырып була.

8. Хәреҗ. Монысы җир биләү күләменә бәйле түләнгән салым. Хәреҗ атамасы Гарәп хәлифәте чорыннан билгеле. Ул, төп түләү салымы буларак, җыелган бар уңышның 1/5еннән 1/3 өлешендә алынган. Хәреҗ салымы азык-төлек белән хан яисә аның буйсынуындагы феодал-тарханга түләнгән. Ул урыс телендәге «поземельный налог»ка туры килә.

9. Хәреҗ-анбар (амбар). Әлеге төр салымы Ибраһим хан ярлыгында күрсәтелә. Аны, аерым салым буларак, амбардагы җыелган уңыш исәбеннән саналган түләнмә-салым дип кабул итәргә мөмкин.

10. Сала (авыл) хәреҗе. Бу салым төре авыл хуҗалыгыннан кергән бар салымнарны берләштерүче атама.

11. Хәрәҗәт. Ул чыгымнар, тотылган, сарыф ителгән акча яки мал мәгънәсендә аңлатыла. Әлеге салым төре монгол чорыннан ук билгеле. Хәрәҗәт идарәче һәм аның кул астындагы ямчеләр өчен җыелган. Казан ханлыгында да әлеге салым төре җирле элемтә, хәрби халык җыеннары, үзәк белән хәбәрләшү чыгымнары өчен тотылган дип уйларга кирәк.

12. Глүфә – ханның җирле атлы гаскәре өчен җыелган фураж, азык салымының атамасы. Гаскәрне туендыру бурычы да җирле халык өстенә йөкләнгән.

13. Сусун. Бу – ханның шәхси атлы гаскәре өчен җыелган салым. Әлеге салым ямче, илче кебек дәүләт эшендәгеләр өчен дә тотылган дип уйларга кирәк.

14. «Өйләрендә көчләп илче, кунак кундырмасыннар» (Ибраһим һәм Сәхибгәрәй хан ярлыкларыннан). Илче һәм кунакларны, хан чапкын-хәбәрчеләрен, ямчеләрне, төрле бурычларын үтәүче хәрби һәм дәүләт хезмәтендәге дәрәҗәле кешеләрне ашатып-эчертү, кундырып чыгару, аларның атларына һәм хезмәтчеләренә хезмәт күрсәтүгә бәйле салым түләме, ягъни йөкләмә булып саналган. Хан даирәсе һәм башка дәрәҗәдәге хакимнәрнең әлеге төбәктә узган күңел ачу, ауга чыгу, хәрби уеннарына хезмәт күрсәтү дә шул җирлектә яшәүче халык өстенә йөкләтелгән. Еш барган феодаль сугышлар аркасында, гади халык һәм аларның гаиләләре төрле җәбер, кысынкылык һәм талауларга тарыган.

15. Төтен саны. Сүзнең мәгънәсенә бәйле әлеге салым өй (морҗа), гаилә яисә хуҗалык саны буенча алынган. Бу салым төре кытай һәм уйгыр документларында искәртелеп, монголлар тарафыннан яулап алынган бар төбәкләргә дә кертелгән.

16. Җир хәбләсе – җир салымы. Әлеге термин бу салым төренең мәгънәсен тулаем ачыкламый. Аның шәригать кануннары салымыннан тыш булган барлык салымнарның җыелма атамасы булуы мөмкин.

Казан ханы бәйрәм киеменнән. М.В.Горелик реконструкциясе

17. Урман, кырлар салымы. Җир бүленешенә бәйле бирелгән урман, кыр һәм көтүлекләрнең күләме, төре, кулланылышына бәйле булган салым түләнмәсе.

18. Олау һәм менү (чапкын) атлары. Сугыш, хәрби уен, ау вакытларында салынган салым. Ул сугыш һәм башка хәрби хәрәкәтләрдә сугыш кирәк-яракларын йөртүче олау атлары, өстәмә атлы гаскәр өчен хәрби атлар туплау салымын күздә тотып салынган. Әлеге салым төре илче-чапкын, ямчеләрне атлар белән тәэмин итүне таләп иткән.

19. Тамга – һөнәрчелеккә бәйле салым атамасы. Тамгачылар – әлеге салымны җыючылар. Ул күп очракта шәһәр халкыннан җыелган салым төре буларак карала. Әлеге төр салым халык санына бәйле рәвештә унның бер өлеше исәбеннән җыелган.

20. Гошер – унынчы тәртип саны. Шәригать кануннары буенча, җыелган уңышның яки малның уннан бер өлеше мөселман җәмгыяте файдасына бирелгән. Мөселман илләрендә (Казан ханлыгында) гошер салымы (сәдака) дини җитәкчеләр кул астындагы җирлекләрдә яшәүчеләрдән җыелган. Гошер салымы дәүләт яисә җирле феодал-бәк казнасына тапшырылган җыемның уннан бер өлешен тәшкил иткән.

21. Зәкят – байларның кеременнән 1/40 өлеш нисбәтендә фәкыйрьләр файдасына алынырга тиешле салым. Зәкят салымын түләү Коръәндә Аллаһ тарафыннан мөселман кешесе өчен билгеләнгән биш фарыз гамәлнең берсе булып тора.

22. Җөзъи – өлеш, кисәк, вак, кечкенә мәгънәсен белдерүче атама. Ул мөселман булмаган халыклардан алынган салым түләме дип санала. Әлеге салымның Казан ханлыгында йөрештә булуы турында хәбәрләр юк.

23. Кияү белән кәләштән алынган салым. Авыл халкыннан туй салымы алынган. Әлеге салым төре Казан ханлыгы чорыннан калган дип санала.

24. Даруга (өлкә) салымы. Әлеге салым даругалардан җыелган салым төре буларак күзаллана. ■

Безнең мирас №2 февраль 2021

Төрки империяләр

Хәзәрләр сабагы

Фарук Нәфиев

Каһан хөкүмәте башлыгы Иша Иосиф (ул үзен-үзе патша дип игълан итә) үзенең җариясе белән Святослав гаскәрләренең Итил башкаланы ничек җимерүен карап тора. ***Рәсем «Плач по неразумным хазарам» романыннан***

Ярты гасыр буена, күзәтеп баруымча, Татарстан матбугатында – ни журнал, ни газеталарда заманында бик дәһшәтле, көч-куәтле Хәзәр империясе турында телгә алырлык саллы язмалар күргәнем юк. Гаҗәп бит. 1500 еллар элеккеге тарих булса да, ул гасырлар тузанына күмелеп калырга тиеш түгел, дип, бу халыкның язмышы белән кызыксына башладым.

Хәзәрләр турында бердәнбер зур әдәби әсәр «Ваемсыз хәзәрләрне жәлләп» – «Плач по неразумным хазарам» романын (авторы – Александр Байгушев) берничә кат укып чыктым. Чөнки ул әсәр гадәтигә бөтенләй охшамаган, шул заман хроникаларыннан алынган легенда-мифлар белән мул бизәлгән. Шуңа өстәп, татарларга һәрвакыт сокланып караган, бай тарихларын яратып сурәтләгән, төрле «бөек» тарихчыларның нахак гайбәтләреннән безне аралап, яклап килгән чыннан да бөек рус тарихчысы Лев Гумилев (әнисе юкка гына Анна Әхмәтова түгелдер), галимә Людмила Плетнева, профессор Михаил Артамонов хезмәтләре һәм монографияләре белән дә танышу бәхетенә ирештем.

Менә шулар тәэсирендә туган фикерләрем, белгән кызыклы вә гыйбрәтле мәгълүматлар белән сезне дә таныштырырга уйлыйм.

* * *

...Һәр тарафта гарәп гаскәрләре тантана иткән давыллы-дәһшәтле бер чорда Итилнең түбән агымында төрки халык – Хәзәр дәүләте оеша башлый. Бөек Даланың яртысын биләп торган көнбатыш төркиләр каһанлыгының борынгы ашина ыругыннан булган көчле бәкләрнең берсе – Турун хан 651 елда беренче булып Хәзәр каһаны дәрәҗәсен ала. Ул да, һуннар һәм куктөркиләр сыман, эшне бик тиз тотып, яңа оеша башлаган дәүләтне ныгыту өчен конкрет чаралар күрә башлый. Турун хан чик буйларында, беренче чиратта, шәп ныгытылган таш кирмән – крепостьлар торгызуга керешә. Шул ук вакытта Беленҗир, Сәркел Сур, Байда һ.б. шәһәрләргә нигез салына.

Күп гасырлык тәҗрибә күрсәткәнчә, Ходай әллә кайлардан әллә нинди ярдәм көтеп утыручыларга түгел, гамәл артыннан гамәл кылып, халкының исәнлеге-иминлеге турында кайгыртучы, дәрт-дәрманы ташып торган Турун каһанга булыша. Хан-Балык (Атил-Итил) каласы-кальгасы Хәзәр дәүләтенең башкаласы буларак салына. Хан сараен Итилнең түбән өлешендәге уң як ярга якын гына урнашкан иркен утрауда яндырып ясалган кирпечтән төзиләр. Ә башкала Итилдә берничә ел эчендә халык өчен җәмәгать мунчалары, илдә ислам дине актив таралганга, мәһабәт таш мәчетләр калкып чыга, алар янында балалар өчен мәдрәсәләр дә салына.

Гади халык өйләрен балчык һәм камыш саманнан төзи. Теләгәннәр, күчмәннәр гадәте буенча, тирмәләр куя. Халык һәр тарафта, кырмыскалар кебек, мәш килә. Берничә ел эчендә шәһәрләр җиләк-җимеш бакчаларына күмелә. Каһанлык халкы, нигездә, терлекчелек, игенчелек белән шөгыльләнә. Бөтен яктан су-дәрья белән уратып алынганга, табигый, балыкчылык та киң тарала. Хәзәр (Каспий) диңгезе һәм мул сулы Итил буйлап төрле тауар, ефәк һәм парча төялгән сәүдә кораблары йөзеп, килеп-китеп тора. Византиядән хатын-кызлар өчен бизәнү әйберләре, кәсепчеләр җитештергән тауарлар китерәләр. Дәүләт аркылы үткән чит ил сәүдәгәрләренә салым 10 процент тәшкил итә.

Казнага һәр тарафтан акча агылып керә. Дәүләт ныгый, күзгә күренеп байый башлый. Гөмбәләр төсле һәр тарафта калкып чыгып торган кала-кирмәннәрдә, сәүдәгәрләрдән тыш, зәркәнчеләр, чүлмәк, савыт-саба ясаучылар, тимерчеләр һ.б. һөнәрчеләр яши. Алар җитештергән әйберләр читкә чыгарып та сатыла.

Тел, мәдәният һәм әдәбиятны үстерү өчен менә шундый вазгыять – үз илеңдә, туган җиреңдә гөрләп-җәйләп яшәү кирәк тә бит инде. Бер уңайдан моннан 1400 елга якын элек әнә шундый җайлы-уңайлы тормыш корып яши башлаган, болгар, һун, татар, кыпчак кебек үк бер-берсен туганнарча аңлаган төрки хәзәрләрнең сөйләмен күз алдына китерү өчен, аларның бай фольклорыннан берничә генә булса да мисал карап үтик әле: *«Акчасы табылдый, түргә ултырдый»*. Моны бит һәр төрки халык вәкиле, шул җөмләдән, без, татарлар да, 100 проценты белән аңлый. Игътибар итегез: түрдә утыру – югарырак көрси-кәнәфиләргә үрмәләү өчен, нихәтле байлар, чиновник-түрәләр акча җыя, байлык туплый түгелме соң?! Акча букчалары кабардымы, хакимият кирәк була башлый. Бу бит инде аксиома. Икенчерәк бер мәкальгә багып карыйк: *«Дошманны өйрәнмәк, өйләк белән су сөзмәк»*. Моннан да ачыграк әйтеп булмыйдыр да. АКШта – ЦРУ, СССРда КГБ нәкъ менә шул максатны күздә тотып оештырылмаганмы? Безнең Исхак Әхмәров кебек разведчиклар, дошманны бик шәп белү өчен, дистә еллар АКШта (тотылмыйча!) яшәп, илебезгә исән-сау әйләнеп кайтканнар (дөрес, барысы да түгел). «Халыклар атасы» Иосиф һәрберсен диярлек юкка гына шәхси контролендә тотмагандыр! *«Әйтельян шүз (сүз) – атыльян ук»*. Хәзәрләрдә барлык төркиләр өчен уртак мәкаль-әйтемнәр дә күп. *«Күн (көн) – эшләргә, түн – төшләргә»* – монысы да шулар рәтеннән. Кыскасы, хәзәрләр, барлык төрки халыклар кебек, күзәтүчән, тапкыр, тирән акыллы, бай мәдәниятле булган. Нәтиҗәдә, бер сорау туа: шундый көчле, мәдәниятле, уңган-булган хәзәрләрне ни өчен бер тарафта да күрмибез? Төрле тарихи сүзлекләрдә телләре-сүзләре сакланган. Ә үзләре юк! Кайларга гына китеп югалдыгыз икән төрки туганнарыбыз, ни булды соң сезләргә, дала тетрәтеп йөргән кара чәч, зәңгәр күзләргә?!. Моңа бик ачык җавап бар чал тарихта. Аның турында сүз алга таба булыр.

Ул чорда Бөек Даланың зур өлешен биләп торган кыпчак-күктөркиләр каһанлыгы, дәһшәтле империя буларак, яңа оешкан Хәзәр дәүләтенә эшлекле ярдәмен күрсәтә, аның мәнфәгатьләрен, мөстәкыйльлеген – суверенитетын яклый. Шунлыктан формаль

яктан гына күктөркиләр союзына кергән хәзәрләр сюзерен-хуҗаларының көчәюен генә телиләр. Бәйрәм ашы – кара-каршы, дигәндәй, менә шуңа күрә күктөркиләр каһанлыгы хәтта яңа туган Хәзәр дәүләтенә дә биләмәләрен ишәйтергә-киңәйтергә ярдәм итә. Аның чикләре Хәзәр (Каспий) һәм Кара диңгезләр (алар арасындагы Кавказны да Дербентка кадәр кертеп), төньякта бүгенге Удмуртия җирләренә кадәр барып җиткән. Яшь каһанлык вассаллары көнчыгышта – Уралга, көнбатышта Днепрга хәтле җәелгән чикләрдә яшәгән. Борынгы без белгән «Бөек Болгарстан» да Хәзәр каһанлыгы кул астына килеп керә. Чөнки бу дәүләт, дөньяда нибары 50 ел гына яшәп, 650 елда аның ханы Кубрат үлгәч үк таркала башлый.

Биредә бик урынлы булган лирик чигенүдән соң, хәзәрләргә әйләнеп кайтыйк.

Шактый байлык туплап, үзенең көчле гаскәрләрен дә булдырган, көчәеп киткән Хәзәр каһанлыгы, Урта Азия төркиләре кебек үк, VII-VIII гасырларда искиткеч куәтләнеп киткән гарәп хәлифәлеге гаскәрләренә төньяк өлкә-биләмәләргә бару юлында киртә булып тора. Шунысы ифрат кызык: Византия һәм Иран кебек көчле даими армияләре булган державаларны пыр туздырып аткан гарәпләр, яңа гына оешкан Хәзәр дәүләте белән 150 ел буена тарткалашып, берни майтара алмыйлар! Шуңа күрә ике арада статус-кво, тынычлык урнаша.

Ахырга таба гына, Хәзәр империясе яһүдләр кулына эләгеп зәгыйфьләнүдән файдаланган Идел Болгарстаны ханы Алмуш Сәлки, илендә ислам динен тарату өчен, Багдад хәлифәсе Әл-Мөктәдирдән ярдәм сорарга җөрьәт итә. Шуның нәтиҗәсендә, Хәзәр дәүләтен ерактан урап, Болгарстанга Ибн Фадлан җитәкчелегендәге зур кәрван-миссия килеп, Биредә 922 елда рәсми рәвештә ислам дине кабул ителә.

Хәзәр каһанлыгы маҗар (венгр) дәүләтен төзүдә хәлиткеч роль уйный. Күбебезгә мәгълүм булганча, Мәдьяр-маҗарлар Урал тавының көнбатыш ягындагы урманлы итәгендә 400 ел буена төрки Огур кабиләләре белән дустанә ярдәмләшеп яшиләр. Маҗар-уңгар-хунгар атамасы да шул чордагы төрки «оногур» сүзеннән килеп чыккан.

Хәзәр каһанлыгының Русь дәүләтен оештыруга да турыдан-туры катнашы бар. Хәзәрләр, дәүләт оешкач ук, скандинавлылар белән сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштырган. Тауарлары белән килгәннәр арасында үзләрен русь дип атаучы кабилә вәкилләре дә була. Рос-Русь – шведча диңгезче дигән сүз. 862 елда Рюрик, Синеус, Труворь исемле өч бертуган, үзләренең русь кабиләсе гаскәрләре белән, Новгород, Изборск, Белозерск исемле славян шәһәрләрен яулап ала һәм үз кенәзлеген төзи. Менә шул рәвешчә, урыс халкына һәм аның дәүләтенә дә рос-русь исемен варяглар бирә! Димәк, шуңа хәтле бу халыкның гомуми исеме-атамасы да булмаган.

Славян сүзе бит ул шул телдәге кабиләләрнең гомуми атамасы гына. Озакламый, ике энесе үлгәч, Рюрик кенәзлекнең хуҗасы булып кала. Ә 879 елда, Рюрик үлгәннән соң, аның улы Олег (аларча, Хелг) кенәз тәхетенә утыра. Ул исә, варяг гадәте буенча, тирә-яктагы тотып ашарлык «куян-корбан»нарны ачыклый башлый. Урысларга хас булганча, ул иң элек гаскәр турында кайгырта. Аннары берничә гасыр элек бөек Атилла империясе составында төзелгән, славяннар белән бергә төркиләр дә яшәгән Кияв (Киев) каласын басып ала һәм, Хәзәр каһанының рөхсәте белән генә, аны Русь кенәзлегенең башкаласы итә. Киев белән идарә итү дә хәзәрләр үрнәгендә башкарыла. Хәтта Русьның кенәзләре дә башта каһан дип атала. Русь кенәзе менә шулай үзләрен бер селтәнүдә юк итә алырлык империя алдында ялагайлана, ә соңыннан, зәгыйфьләнүеннән файдаланып, буып ташлый – юк итә. Кыргый җанвар, ерткыч өчен бу табигый хәл. Тарихта мондый аналогияләр бик күп.

…Турун ханның вафатыннан соң тәхеткә утырган каһаннар, империя ныгып, автомат режимга күчүдән файдаланып, үзләрен Күк Тәңренең җирдәге вәкилләре

санап, күп вакытларын зиннәтле сарайларында кәеф-сафа корып үткәрә башлый. Ә көндәлек гамәли җитәкчелек-хакимият хөкүмәт җитәкчесе кулына күчә. Хөкүмәт исә каһан белән «шартнамә» төзергә дә онытмый. Аның нигезендә каһан, елга бер тапкыр сарай алдындагы мәйданга чыгып, халыкка күренергә тиеш була. Калган вакытын ул сараенда хатыннары һәм җарияләре арасында үткәрә. Хөкүмәт каһан җарияләренең санын 365 итеп калдыра, ягъни елдагы көннәр санынча «чикли». Вакытында үлә белгән каһан, дөнья оҗмахыннан ахирәт оҗмахына гына күчәм, дип, моңа бер дә кайгырмый. Әгәр дә инде каһан тәхеттә шартнамәдә күрсәтелгән 40 елдан артык утыра икән, кулларына ефәк бау тоткан хөкүмәт әгъзалары, аның янына кереп: «Бу дөнья оҗмахында күп рәхәтләндең, әйдә, теге дөнья оҗмахында яшәп кара!» – дип, тегенең муенына ефәк элмәк салалар.

Һәр кагыйдәнең чыгармасы да була, дигәндәй, әгәр инде каһан хөкүмәткә дә, халыкка да ошаган абруйлы шәхес булса, аңа, бер көнлек коры паек биреп: «Үз көнеңне үзең күр!» – дип, сахрага-далага сөрәләр.

Бу гайре кызыклы да, гыйбрәтле дә нәрсәләрне мин уйлап чыгармадым. Алар тарихи хроникаларда, әсәрләрдә тәфсилләп сурәтләнгән.

Хәзәрләрнең төп дине, табигый, борынгы тәңречелек була. Ә каһанлык оешкач, Византия үзенең миссионерлары, сәүдәгәрләре ярдәмендә бу илдә дә христиан динен киң тарату өчен көчен һәм акчасын җәлләми. Күршедәге Иранны яулап алган гарәпләр дә кимен куймый. Шул рәвешчә, Хәзәрстанда чиркәүләр, мәчетләр пәйда була. Бүгенгечә әйткәндә, «тулы толерантлык» өчен бер генә «мөһим элемент» җитми.

Менә, ниһаять, бер көнне югарыда әйтелгән «җитешмәгән элемент» әһелләре пәйда була. Дәүләткә каршы кылган мәкерле гамәлләре өчен күрше Ираннан сөрелгән яһүдләрнең зур гына төркеме, сыену урыны сорап, Хәзәр каһанына мөрәҗәгать итә. Төрки илнең хәерхаһлы даирәләре: «Болар бит бик укымышлы, акыллы халык, дәүләтебез белән идарә итүне камилләштерүдә, дипломатиябездә бик зур файда китерәчәкләр», – дип, аларга башкалада урамы-урамы белән үз бистәләрен төзеп урнашырга рөхсәт бирәләр.

Бөек каһан һәм аның хөкүмәте бу гамәлнең әлегә чаклы исән-имин яшәгән илнең һәр күзәнәгендә, эндокрин системасында бүгенгедәй таҗлы вирус зәхмәте оялап, аны төзәлмәс авыруга сабыштырачагын һәм ахыр чиктә җан тәслим кылдырып юкка чыгарасын белсәләр, бу мәкерле кавемне якын да китермәсләр иде. Моның өчен бары тик Иран шаһы Хөсрәүдән яһүдләрне ни өчен иленнән сөрүе турында гына сорарга кирәк иде. Әмма яһүдләрнең матур сайрауларыннан башлары әйләнгән хәзәр хакимнәренең уена мондый шик-шөбһә килми шул...

Зур алтын запасы белән килгән төркем исә эшне кызу тота. Озакламыйча, сокланырлык итеп бизәлгән яһүд өйләре, сарайлары, шәһәрдә элек эзләре дә булмаган синагогалар пәйда була. Шулай җайлап кына урнашкач, яһүд җәмгыяте үзенең алдан уйлап куйган традицион «эшчәнлеген» җәелдереп җибәрә. Беренче нәүбәттә, үзләренең чибәр кызларын җыеп, каһан гаремына (хәрәменә) тапшыралар. Икенчедән, хөкүмәт әгъзаларына алтын-көмешләрен җәлләмичә, җайлы-җылы урыннарга кереп утыралар. Мөһим саналган сәүдә эшләрен кулларына алып, империянең һәр тарафындагы базарларга хуҗа булалар. Үзләренең менталитетыгадәте буенча байлык, зиннәт, зур алтын запасы туплыйлар.

Озакламый илнең һәр күзәнәгенә үтеп кереп, һәр тарафны җентекләп өйрәнгән яһүдләр, елтыр-елтыр хөлләләрен кигән раввиннарын да ияртеп, бөек каһан хозурында «тантаналы очрашу» церемониясе оештыралар. Бөек каһан, хөкүмәт әгъзалары, олы бәкләр катнашында үткәрелгән «симпозиум»да күзләрне камаш-

Хәзәр кызының, каладагы дус кызларында кунакта булып, өенә кайтып килеше. Тирә-юньдәге халык, аның чибәрлегенә сокланып, өстенә чәчәкләр яудыра. ***А.Байгушев романыннан алынган рәсем.***

тырып торучы җилән-хөлләләргә төренгән яһүдләр ил алдында ачылачак «перспектива» турында, бөтен тел байлыкларын, дипломатия осталыкларын җигеп, дәлилләп, бик матур «сайрыйлар». Бүгенге заманнан артта калмас һәм бөтендөнья Олимпында лаеклы урын биләр өчен, «актуальлеген югалткан» тәңречелекне чүплеккә ташлап, иң алдынгы яһүд диненә күчү мәслихәт, дип, мәсьәләне кабыргасы белән куялар.

Мондый вәгазьләрдән тәэсирләнеп, империянең аллы-гөлле киләчәген күз алдына китереп, чиксез эмоция дәрьясына чумган бөек каһан: «Барыгызга да боерам: иртәгәдән яһүд диненә күчәбез, аның алласына турылыкка ант эчәбез», – дип, хәтта поэтик телгә күчүен сизми дә кала.

Шулай итеп, 790 елдан башлап Хәзәрстанның барлык хаким-идарәче даирәләре синагогаларга, раввиннар вәгазен тыңларга йөри башлады.

Шунысы кызык вә гыйбрәтле: мондый сәер очрак бөтен дөньяда бердәнбер. Урыс мондый очракларда: «Это было началом конца», – дигәндәй, әлеге вакыйга чәчәк атып утырган империяне юкка чыгаруның башы була.

Әле совет чорында Казанның мәшһүр Матбугат йортындагы бик зур һәм бай китап кибетеннән борынгы хәзәрләр турында бердәнбер күләмле әсәр – Александр Байгушевның «Плач по неразумным хазарам» дигән 560 биттән торган тарихи романын сатып алган идем. «Байгыш-байгуш» – төрки телдә «ябалак» дигән сүз. Шуңа күрә автор үзе дә, бәлки, рус түгел, ә берәр төрки халык вәкиледер. Чөнки Байгушев хәзәрләрне чын күңелдән жәлләп елаган төсле яза. Ул, яһүд динен кабул итеп, килмешәк яһүдләр коткысына бирелгән, шул рәвешчә, әшәке тозак-капкынга эләгеп, хәлсезләнеп таркалган һәм ахыр чиктә тарих сәхнәсеннән төшеп калган бөек халыкны чын күңелдән кызгана.

Армиясез һәм коралсыз гына, күз буяу, мәкер-хәйлә, ялган белән ил хакимиятен кулга төшерү, халкын буйсындыру көчәеп киткән яһүд килмешәкләренең төп максатына әйләнә. Башта яһүд хатынынннан туган метис – ярым гыйбри Булан каһан ил халкын бердәм, дус яшәргә чакыра, центристик сәясәт үткәрергә тырыша. Әмма мондый гамәл үз планнарына туры килмәгәнгә яһүд җәмгыяте җитәкчеләре, махсус фетнә оештырып, Буланны хакимияттән «читләштерәләр» (сәясәттә ул чорда да, бүген дә «үтерү» дигән тупас сүз юк), саф гыйбри Обадий дигән каһанны тәхеткә утырталар. Ул исә, үзен уратып алган яһүд сәясәтчеләре кулындагы марионетка-курчак сыман, алар кушканны гына эшли, чит илләрдәге кавемдәшләре белән элемтәгә кереп,

галим-голәмәләрне, яһүд акыл ияләрен Хәзәрстанга чакыра. Нәтиҗәдә, христиан һәм мөселман илләрендә иркенәеп, җәелеп китә алмаган Исраил уллары Хәзәрстанга агыла башлый. Алар, беренче чиратта, Обадийны уратып ала һәм дустанә эш итеп, хөкүмәттәге барлык җаваплы урыннарга кереп утыра. Каһанлык, шул рәвешчә, тиз генә төркидән яһүди-төркигә әверелә. Аларны төп халыкның һәм дәүләтнең язмышы кызыксындырмый, шөгыльләре халыктан салым җыюга гына кайтып кала. Чөнки каһанны, ялланган хәрби көчләрне асрау кыйммәткә төшә.

Шулай итеп, хәзәр халкы кайчандыр үзе төзегән иректә илендә читтән килгән килмешәкләр колына әйләнә. Хәтта эш шуңа барып җитә ки: яһүд сәүдәгәрләре, эчке һәм тышкы базарларда хәзәр балаларын коллыкка сатып, акча җыя башлый. Барлык тарихи хроникаларда, тарихчылар язмаларында күрсәтелмәсә, мондый метаморфозаны уйлап чыгарып та булмас иде.

Җәбер-золымга чыдамаган халыкка ни кала?! Әйе, изүчеләргә каршы көрәшкә күтәрелү. Рәхимсез сугышта хәзәрләр белән рәттән яһүд даирәләренең дә күренекле вәкилләре – хәтта каһан үзе һәм аның ике улы да җан тәслим кыла. Киң даланың һәр тарафында көрәш уты дөрли. Илдә хаос барлыкка килә. Кайчандыр чәчәк атып торган ил хәрабәләргә әйләнә.

Обадий урынына тәхеткә утырган энесе Ханукка халыкка каршы күршедәге бәҗәнәк һәм угыз гаскәрләрен яллый. Алар исә, каһан вәгъдә иткән алтын тауларына кызыгып, хәзәр халкын рәхимсез кыра башлый. Ахыр чиктә баш күтәрү бастырыла. Күбесе, үзләренең йорт-җирләрен, мал-туарларын калдырып, чит илләргә качып китә.

Килмешәк оккупантлар тантана итә. Ялланган армияне, күпсанлы чиновникларны асрау өчен алар илдәге халыктан гына түгел, хәтта тирә-яктагы үзләренә буйсынган илләрне, кабилә-кавемнәрне дә зур салымнар түләргә мәҗбүр итәләр. Яһүдләр өстенә һәр тарафтан ләгънәт-каргыш ява, ризасызлык туа. Нәтиҗәдә, элек гөр килеп яшәгән империя, бизгәк белән авырган җанвар кебек, калтырана башлый һәм хәлсезләнеп егыла. Бу хәлләрне игътибар белән күзәтеп торган күршедәге Киев кенәзе Святослав, күчмә бәҗәнәк һәм угыз кабиләләре белән килешеп, 965 елда бергәләп килеп, хәзәр шәһәрләрен җимереп, башкала Итилне дә пыран-заран китерә.

Ә баш күтәрү вакытында ватылган-җимерелгән, күп халкы гаиләләре белән читкә качып китәргә мәҗбүр ителгән хәзәр илендә Святославка каршылык күрсәтүче булмый. Святослав, илне яулап алуны кирәк дип тапмыйча, гаскәрләре белән Киевка кайтып китә. Һөҗүм вакытында качып котылган Ханукка инде күпме тырышса да, империяне аякка бастыру аның хәленнән килми. Шулай да шактый вакыт – ике дистә ел буена ул, саламга ябышып котылырга теләгән суга батучы сыман, ара-тирә өскә калкып, нәрсәдер майтарырга маташа.

Атасы походыннан соң 20 ел үткәч, аның улы Вальдемар (урысча Владимир), зур ладья-көймәләрдә Итил буйлап килеп, Хәзәрстанга басып керә һәм, һәр кала һәм авылны хәрабәләргә әйләндереп, каһанны, аның хөкүмәт әгъзаларын юк итеп, империя гомеренә соңгы ноктаны куя. 651дән 985кә хәтле яшәп, дөнья сәхнәсендә 334 ел торып, матур гына яши башлаган Хәзәр империясе әнә шулай фаҗигале рәвештә һәлак була.

Чал тарих шаярырга яратмый, үзен санламаучыларны гафу итми. Әйе, империяләр дә, кеше кебек үк, күпме яшәсәләр дә, ниндидер сәбәпләр аркасында, барыбер юкка чыгалар. Алар ничәмә дистә булган бит югыйсә! Хәзәр империясе фаҗигасенең дә үз сәбәбе бар. Чит-ят килмешәкләрнең диненә күчеп, аларга буйсынып, үз йөзен җуйган хәзәрләр, гафу ителмәслек ваемсызлык күрсәтеп, әнә шундый хурлыкка кала. Гыйбрәтле һәм аяныч сабак!.. ■

Татарлар һәм удмуртлар

Илнур Газизуллин

Туган авылым Яңа Смәил Киров өлкәсенең Малмыж районында урнашкан. Ул революциягә кадәр Малмыж өязенең Вятка губернасына караган. Авылдан бер чакрым тирәсендә генә ике удмурт авылы бар – Пор Китәк һәм Удмурт Китәк.

Язмабыз шушы төбәктәге удмурт-татар мөнәсәбәтләре хакында. Бер искәрмә – бу шәхси (субъектив) караш, төгәлрәге, Яңа Смәил авылы татарларының биредә яшәүче удмуртларны XIX гасыр ахырында һәм XX гасырда ничек күзаллаганнарын тасвирлау.

Топонимнарда – удмурт эзләре

Смәил татарларының сөйләвенчә, удмуртлар бу җирләргә аларга хәтле үк килеп урнашканнар. Киров өлкәсенең белешмә сүзлегендә татарларның төпләнүе 1714 ел дип теркәлгән. Әмма каршылык килеп чыга: шул ук удмурт авылларының да нигезләнүе 1714 елда дип күрсәтелә. Ә риваять буенча, алар алданрак килеп урнашырга тиешләр. Яңа Смәил авылы барлыкка килү турындагы риваятьтә шундый тарих бәян ителә: хәзерге ТРның Балтач районындагы Иске Смәилдән татарлар килеп өйләр төзи башлагач, елга буйлап түбәндәрәк утырган удмуртлар агып килгән йомычкаларны күреп аптырыйлар һәм өскәрәк менеп карыйлар – татарларның йортлар төзи башлаганын күрәләр. Әйтергә кирәк, мондый риваятьләр татар авылларының килеп чыгышлары тарихында еш очрый.

Риваятьләрдә бу җирләрдә бик куе урманнар булган дип сөйләнелә. Бирегә килгән татарлар, урманнарны чистартып һәм яндырып, ашлык үстерергә яраклы

«ышна» басулары ясаганнар. Мәсәлән, «Көллек», «Көллек басуы» нәкъ удмурт авыллары янында урнашкан. Удмуртлар белән бәйле башка микротопонимнар да сакланып калган: мәсәлән, «Ар урманы» – Пор Китәктән Зур Китәккә таба урнашкан агачлык (посадка). «Ар юлы» урамы. Хәзер рәсми исеме «Хезмәт урамы» дип аталса да, сөйләмдә ул әле дә «Ар юлы» булып кала. Бу урам Яңа Смәилдән Пор Китәккә бара торган юлда урнашкан. Авылда аны «арларга бара торган юл» дип тә әйтәләр.

Исем-фамилияләр ни сөйли?

Җирле удмуртларның этнограф күзлегеннән кызык тоелган фамилияләре бигрәк тә игътибарга лаек. Мәсәлән: Баширов, Арсланов, Асанов һәм Утямышев, Сабанов. Аңлашылганча, бу фамилияләр күбесенчә төрки сүзләрдән ясалган: Бәшир, Арыслан, Үтәмеш, Сабан. Шулардан бер-икесе генә гарәп теленнән алынган, мәсәлән, Әсән (Хәсән). Гадәттә, татар һәм удмурт фамилияләре аерыла. Әмма кайбер фамилияләр, әйтик, Камаевлар күрше удмурт авылларында да, Смәилдә дә очрый. Шулай ук Арслановлар да күршедәге Чәти (икенче исеме Югары Китәк яисә Нослы Пучинкәсе) керәшеннәрендә, Үтәмешевлар исә күрше удмуртларда һәм ТРның Кукмара районына караган Мәчкәрә авылы татарларында бар.

Интернетта бик кызык материалга тап булдык. Бөек Ватан сугышында катнашканнар исемлегендә шундый мәгълүмат бар: «Камаев Виталий Ахмедзянович 1895 г.р. из д. Пор Китяк, призван в 1942 г., погиб в 1944 г.» Камай төркиме, әллә удмурт исемеме – монысын ачыклауны тел галимнәренә калдырыйк. Әмма Әхмәтҗанның мөселман булуы бернинди шик уятмый. Әлеге факт татарларның биредәге удмуртларга бик зур тәэсир иткәнен күрсәтә. Авылның төп нәселеннән булган 1896 елгы бабам Шаһимәрдән улы Хәбибрахман 1970 нче елларда: «Әле XX гасыр башында күрше авыл арлары безнең авыл мәчетенә килеп йөриләр иде», – дип сөйләде. Мөселман булганнармы алар яисә бабалары рухына сәдака китергәннәрме – анысын төгәл генә әйтеп бетермәде. 2016 елда бу мәгълүматны минем әни дә: «Бабаең сөйләде», – дип раслады.

XIX гасыр ахыры-XX гасырга караган кайбер удмурт исемнәренә күз салсак, кызыклы нәтиҗәләр ясарга була. Күрше удмурт авылларында үзенчәлекле, безгә кызыклы тоелган исемнәр билгеле: Гөлҗамал, Гөлбикә, Назбикә, Миңҗамал, Чәчәби (паспорт буенча Клавдия); ир-ат исемнәре – Тукай, Тукми, Туканай. Болар – информаторларның әби-бабалары, ягъни XIX гасыр ахырына-20 нче йөзнең беренче яртысына караган исемнәр. 2002 елда Милли музейның этнографик экспедициясе вакытында (ТРның Кукмара районына) Җанбикә Баймурзина, Гөлбостан Сабанаева, Гөлҗамал Ишмурзина, Минзирә (Байбикә) Апанова, Тухтар Вәлиев дигән исем-фамилияле удмуртлар белән таныштык. Бу – без аралашкан информаторларның үз исемнәре. Әлеге анализ җирле удмуртларның үз вакытында ни дәрәҗәдә татар тәэсирендә булганлыгын күрсәтә.

Удмурт-татар мөгамәләсе

Удмурт-татарларның үзара мөгамәләсенә күз салыйк. Удмуртлар татарларны «бигер» дип атыйлар, яисә «бигер пиез» – «татар малае». Соңгы терминны алар кайвакыт үзләренең татар авылында яшәгән һәм беркадәр татар тәэсиренә бирелгән милләттәшләренә карата кулланалар.

Үз чиратында, без, татарлар, удмуртларны «ар(лар)» дип атыйбыз. Хатын-кызлары турында «ар хатыны» дибез. Ни өчендер, мариларны – «чирмеш-әкәй»гә, русларны «мужик-марҗа»га аерган шикелле, удмуртларны җенескә бүлү юк. Моның, бәлки, берәр сәбәбе бардыр. Ихтимал, без удмуртлар белән алда аталган халыклардан соңрак элемтәгә кергәнбездер.

Удмурт авылларын гомуми термин белән «ар, арлар» дип атап йөртәбез һәм «Югары авыл» (Удмурт Китәк) белән «Түбән авыл»га (Пор Китәк) бүләбез.

Төбәктәге татар-удмурт мөнәсәбәтләрен тикшергәндә татарлар белән удмуртлар арасында ниндидер бәйләнеш барлыгы, үзара ярашып яшәүләре игътибарны җәлеп итә. Мәшһүр этнограф Л.Гумилев буенча бу «комплиментарность» дип атала. Кагыйдә буларак, җирле удмуртлар татарлар белән янәшә (бергә түгел, ә янәшә, аларның «канат астында») урнашырга яраталар. Мәсәлән, ТРның Балтач районындагы татар авылы Смәил һәм күрше удмурт авылы Иске Торҗа (Старая Турья). Безнең татар Яңа Смәиле һәм күрше удмурт авыллары Пор Китәк, Удмурт Китәк яисә ТРның Кукмара районындагы татар авылы Березняк һәм күрше удмурт авылы Түбән Кумор һ.б. «Нишләп алай?» – дип сорагач, Ижаудан килгән удмурт галимнәре: «Удмуртлар үзләрен татарлар янында уңай һәм рәхәт хис итәләр», – дип җавап бирделәр.

Бу хәлне галим Марсель Әхмәтҗанов үзенчә аңлата. Аның күзаллавынча, удмуртлар әлеге җирләргә төньяктан күчеп килгән. XIV гасырда Пермь краендагы җирле халыкларны, шулай ук удмуртларны көчләп чукындыралар, алар, моңа түзә алмыйча, рус митрополитын үтерәләр. Шуннан соң Мәскәүнең тискәре мөнәсәбәтеннән, җәберләвеннән, казасыннан куркып, удмуртлар, Алтын Урда морзалары канат астына сыенып, көньяккарак күченә.

Сөйләшкәндә удмуртлар татарларга хөрмәт белән карыйлар. Аларның үзләрен түбәнчелекле, оялчанрак тотуларын да искәртергә кирәк. Җирле татарлар удмуртларны темперамент ягыннан тыныч, хәтта артык тыныч дип санайлар. Шул ук вакытта аларны үчле, эчтә усаллык саклыйлар, диләр. Бу караш, бәлки, удмуртларның тышкы агрессиягә җавап кайтармауларыннан килеп чыккандыр. Үзләрен тыныч тотуларын, агрессиягә җавап кайтармауларын удмуртларның этикет саклавы, ханлык заманыннан түрә булган татарларга карата ихтирам-хөрмәте дип аңлап була.

Удмуртларның «тынычлыгы» турында сүз алып барганда, мәшһүр Л.Н.Гумилевның «этносның пассионар энергиясе бетеп килүе» турындагы тезисы искә төшә. Галимнең теориясенә таянсак, удмуртлар бик борынгы этнос булырга тиеш, Евразия территориясендәге озын гомерләрендә аларның «пассионар энергиясе» инде табигать белән тигезлеккә кергән, алар «тынычланганнар», ә чагыштырмача «яшьрәк» татар этносының кызу каны әле суынып бетмәгән. Шуңа безнең халыкларның темпераментларында зур аерма бар.

Авыл татарлары фикеренчә, удмуртлар бик кире халык дип санала. Безнең якта күпмедер дәрәҗәдә калыплашкан «кире ар», «киребеткән ар», «кире ар кебек» сүзтезмәләр киң таралган. Шул ук вакытта, кирелек удмурт халкы өчен гомумән уңай сыйфат дияргә кирәк. Кире һәм үзсүзле булмаса, удмурт халкы этнос буларак сакланмас, күптән тирә-як халыклар арасында эреп беткән булыр иде.

Кагыйдә буларак, теге яки бу халыкның тискәре сыйфатына кагылганда, бик сак эш итәргә тырышабыз. Халыкларның үзенчәлекләрен тикшергәндә, шундый нечкәлекләрне дә атап китәргә туры килә. 2016 елда Ижауда конференциядә чыгыш ясаганда, бу турыда әйткәч, удмуртлар: «Әйе, без кире халык», – дип, бу фактны ничектер горурланып кабул иттеләр.

1934 елгы әнием Халисә Хәбибрахман кызының сөйләвенчә, татарлар һәм удмуртлар бик дус яшәгәннәр, бер-берсенә кунакка йөрешкәннәр. Шул ук сүзләрне әни Малмыж турында сөйләгәндә дә кабатлый иде. Әти ягыннан бабам Тимергали Газизуллин Малмыж шәһәрендә яшәгән. Ул 1894 елгы, тумышы белән хәзерге Кукмара районына кергән Уразай авылыннан. Гаилә коргач, ул Казакъстанның Кустанай шәһәренә китеп, шунда сәүдә, НЭП чорында сабын ясау белән шөгыльләнә. Бабам – озак еллар үткәч, бик зур газаплар күреп, Малмыжга кайтып төпләнгән кеше. Малмыжда үтә торган Казан ярминкәсе чорында бабай йортының ишегалды Кукмара районыннан килгән удмуртлар, атлар белән тула торган була, башлыча, туган авылы Уразайның күршесе Лельвиждан киләләр. Алар өчен махсус зур самавыр кайнатканнар. Тумышы белән хәзер ТРның Кукмара районына кергән Купкадан булган 1892 елгы әбием Бибиһадия Сабит кызы яңа стиль буенча 21 июльдә үткәрелә торган Казан ярминкәсенә «әмирхан» сортлы бәрәңгене махсус үстерергә өлгерә иде.

Шулай якыннан дус булсалар да, татар белән удмуртлар катнаш гаилә кормаганнар. Этник үзенчәлектән башка, монда төп рольне дин уйнагандыр.

Удмуртлар – татар халык авыз иҗатында

Янәшә яшәгәнгә күрә, удмуртлар татар халык авыз иҗатында да зур эз калдырганнар. Сәмаилдә бу уңайдан хәлләр ничегрәк тора соң? Мисалга үземнең нәсел кушаматының килеп чыгуы турындагы вакыйганы китерергә булдым. Ул шулай ук удмуртлар белән бәйле. Сүз XX гасыр башы турында бара. Пор Китәктән ерак түгел урнашкан тауда җил тегермәне булган. Ул тегермән 1970 нче елларда да исән иде әле, балачакта иптәшләр белән барган идек. Үз вакытында тирә-юнь авыл кешеләре анда он тартырга йөргәннәр. Бу ачлык елларында булган хәл дип әйтелә. Тегермәнче милләте буенча удмурт, бик кире һәм усал булган. Хатыны аңа ашарга дип сызык (русча «шкварки») китергән. Бабаем, бик шук кеше, бу сызыкны Мәчкәрәдән килгән крестьяннарга ашатып бетергән. Әлбәттә, аны тегермәнченең төшке ашы икәнен әйтмәгән. Тегермәнче моңа бик ачуланган. Шуннан соң ул бабайның онын тартканмы-юкмы – анысын белмим, ләкин шушы тарихтан соң бабайга «Шыжык» («сызык»тан үзгәртелгән) дигән кушамат тагылган. Удмуртлар бабайга күбрәк «Хапи пиез» дип эндәшәләр иде, тәрҗемәсе: «Хапи» – Хәбибрахман, «пиез» – малай. Шулай итеп, удмуртлар безнең нәсел кушаматының килеп чыгышында зур роль уйнаганнар.

Кызыклы антропология

Шәхсән, антропологик яктан җирле удмуртларны шартлы рәвештә 3 төргә бүләргә була дип саныйм. Төп антропологик тип – төптән таза бәдәнле, битләр яссы һәм түгәрәк, борыннар уртача (кайвакыт «бәрәңге» борын). Чәчләр, кагыйдә буларак, күбрәк җирән һәм аксыл, бит сипкелле, күз кабаклары кабарынкы. Күзләр кайвакыт сары гәрәбә төсендә. Без боларны «чиста удмурт» яисә чиста фин тибы дип атый алабыз. Икенче тип: ул сары чәчле яисә аксыл да була ала, битләр европеоид, очлы борын, кагыйдә буларак, зәңгәр яки зәңгәрсу күз. Моны славяннар (руслар) тәэсире дип карарга мөмкин. Сирәк булса да, әлеге тип татарларда, берәр төрле генетик тайпылыш булмаса, йөз гаиләнең берсендә очрый. Татарлар моны, нишләптер, удмурт

тәэсире дип карый. Икенче тип удмуртлар беренче типка караганда сирәгрәк очрый. Безнең өчен иң кызыклысы – өченче тип. Бу – кара чәчле удмуртлар. «Чем-кара» чәчләре хәтта татарларныкына караганда да карарак дияргә була. Битләре күбесенчә түгәрәк, сирәгрәк европеоид (тар битлеләр). Әлеге нәселнең килеп чыгышы белән кызыксынгач, өлкәнрәкләре: «Без бабайга охшаганбыз, борынгыдан шулай килә», – ди. Марсель Әхмәтҗанов бу «каралык» удмуртларның борынгы Урал артында яшәгән чорына – җирле угырларга карый, ди. Мондый төс-кыяфәт иштәкләргә, шулай ук башкортларга да хас. Смәил авылына нигез салучылар арасында Иштәк исеме дә атала. Әмма ул зур исемне кыскартып кына ясалган булырга мөмкин (Иштирәк, Ишморат яисә Ишмөхәммәт).

Татарлар удмуртларның ерак туганнары финнар икәнен шәйләгәннәр. Авылда шундый риваять бар. 1939 елгы совет-фин сугышында татарлар, андагы җирле финнарны күргәч, бик аптыраганнар: «Күрше авылның ар хатыннары монда нишләп йөри икән?» – дигәннәр. Финнар антропологик яктан безнең удмуртларга бик нык охшаганнар.

Гаилә

Гаиләдәге үзенчәлекләрне дә карап үтик. Мәсәлән, татар һәм удмурт гаиләләрендә хатын-кыз статусы, бәһасе. Алар бик төрле, капма-каршы диярлек. Традицион татар гаиләсендә хатын-кызның тоткан урыны ир-аттан бер баскычка «түбәнрәк» торганда, удмурт гаиләсендә хатын-кызның роле, тоткан урыны ир-ат белән тигез һәм хәтта югарырактыр да әле. Элегрәк, күрше удмурт авылы кешеләрен күзәтеп, моңа сирәк очрак итеп карый идем, ләкин 2000 елгы Ижау конференциясеннән соң, аны кагыйдә буларак кабул итә башладым. Удмурт хатын-кызы йорт төзи, гомумән, тормышны алып баручы ролен үти. Удмуртларда матриархат бик көчле. Гадәттә аларда нәсел кушаматлары да хатын-кыз ягыннан бирелеп бара.

Удмуртлар татар телен әйбәт беләләр

Удмурт этнографиясенең үзенчәлекләрен барлауны дәвам итик. Алар урманны, ау эшләрен бик яраталар, бик яхшы умартачылар, игенчеләр һәм, бүтән халыкларга караганда, җиргә ныграк береккәннәр. Хуҗалыклары нык, эшләгәндә үҗәт, тырыш һәм, кагыйдә буларак, татар күмәк хуҗалыкларында да авыр, үҗәтлек соралган хезмәт урыннарында нәкъ менә удмуртлар сыер савучы, тракторчы, көтүче булып эшли. Тәҗрибәлеләргә бригадир, склад мөдире, пилорамщик һәм башка җаваплы эшләрне тапшыралар. Араларында икътисадчылар, сәркатипләр дә бар. Нинди генә хезмәттә булмасын, удмуртлар үз вазыйфаларын зур җаваплылык белән башкара.

Экспедицияләрдә күзәтелгәнчә, удмуртларда этнографик предметлар татарларга караганда күбрәк сакланган. Удмуртлар бик музыкаль халык. Аларда борынгы җырлар күп. Кайбер көйләре татарныкына охшаган. Ә менә татарлар яратып җырлаган «Их, сез, матур кызлар...» – удмуртныкы.

Әнием сөйләвенчә, удмуртларның буыннан-буынга күчеп килгән көтүчеләре белән каз көтүләре сакланып калган. Каз удмурт этнографиясендә, йола-көнкүрешендә зур роль уйнаган. Татарларның туй йоласында да, һичшиксез, каз бар: кодалар ике каз алып килә, берсе – табынга куела, турала һәм ашала, ә икенчесе кире «кайтып китә».

Җирле удмуртлар, бигрәк тә өлкән буын, татар телен әйбәт белә. Гомумән, җирлектә татар теле аралашу теле булып тора яки элегрәк торган. Моны әле үз заманында мәшһүр галим М. Худяков та искәргән. Әнием сүзенчә, удмуртлар татар телен Пор Китәктә – әйбәтрәк, ә Удмурт Китәктә начаррак белгәннәр. Кызганыч, хәзер алар русчага күчеп баралар. Удмуртларның татарча сөйләмнәре үзенчәлекле – акцентлары бар. Кайбер татарча әйтелешләр удмуртларга авыррак бирелә. Ә менә татар авылында яшәүче удмуртлар татарча бик чиста сөйләшәләр. Кайберләре телне хәтта татарларга караганда да камилрәк беләләр дияр идем: бер рус сүзен дә катнаштырмыйча сөйләшәләр. Ә менә татарлар удмуртча бик начар беләләр.

Удмуртларда мәҗүсилек

Удмуртларда «куала» дип аталган борынгы корылмалар сакланган. Күрше авылларда бу биналарны җәен аш пешерә торган бина итеп кенә беләләр. Ә элек алар мәҗүси табыну урыны булып торган. 2002 елдагы экспедициядә Кукмара районының Яңа Кумор авылында без шундый йортны күрдек. Аның хуҗасы Минзирә (Байбикә) Туктаровна безгә бик күп кызыклы мәгълүмат бирде. «Куала»ның төзелеше борынгы чорда биредәге халыкларның йортлары нинди конструкциядә булганын аңларга ярдәм итә. Мәсәлән, кара мич (ачык учак), төтен чыксын өчен төнлек тишеге, киштәләр, шунда ук түшәмсез түбә һ.б. Традицион татар өендә дә төнлек һәм киштәләр сакланып калган. Боларны әле дә кайбер мунчаларда күзәтә алабыз.

Смәилдән елга буйлап ярты чакрым тирәсе түбәнрәк удмуртларның изге урманы сакланган. Әнием сөйләвенчә, Пор Китәк авылы янындагы елганың уң ягында бер карт нарат агачы үскән. Өлкәннәр бу җирне мәҗүси урын буларак хөрмәтләгән. Әнием, ул агачның кәүсәсенә кадак һәм төрле тимер әйберләр кадакланган иде, без балачакта ул җирдән үткәндә бик курка идек, дип сөйләде.

Тумышы белән Татарстанның хәзерге Балтач районына кергән Чутай авылыннан булган 1894 елгы әбием Бибимәптүһә Рамазан кызы, без, татарлар, удмуртлар келәвеннән бик тә курка идек, дип әйтә торган булган. Әбиемнең балачагы даны бик еракка таралган Малмыж өязендәге «Мултан эше» елларына туры килә. Бу елларда мәҗүси удмуртларны, келәү китерүдә гаепләп, Себергә озаталар. Әлеге курку шуннан калгандыр дип беләм.

* * *

Удмуртларның культурасы бездән, татарлардан, төньяктарак, куе урманлы (мәсәлән, тайга) җирләрдә формалашкан дип фаразлыйбыз. Иң әүвәл аучылар һәм җыючылар культурасы, соңрак инде утрак тормыш алып барган игенчеләр культурасы барлыкка килә. Ә менә этник һәм мәдәни үсештә дүрт катламны аерып чыгарырга мөмкин:

1. «Чиста удмурт» (яисә «чиста фин») чоры. Бу – борынгы мәҗүсилек чоры, ул беренче антропологик типка карый – сары сипкелле, кысык күзле удмуртлар.

2. «Иштәк» (яисә «угыр») чоры. Мәҗүсиләр, әмма антропологик яктан чем-кара чәчле, түгәрәк битле, кысык күзлеләр.

3. «Төрки» этап. Бу чорда удмуртлар татарларның, ислам диненең көчле тәэсиренә дучар булганнар.

4. «Славян»нар йогынтысы. Әлеге чорда удмуртларны көчләп чукындырганнар. Алда искәртүемчә, бу этапка сары чәч, зур зәңгәр күз, очлы борын, европеоид, ягъни икенче антропологик тип хас. ■

Безнең мирас №2 февраль 2021

Әҗегә археографик сәфәр[1]

Миркасыйм Госманов



Быел Касыйм шәһәренә һәм Рязань өлкәсендәге борынгы авылларның берсе Әҗегә барып кайтасы иде. Башта Камил Дәүләтшин белән бергә барырга планлаштырдык. Тик ике көннән юлга чыгабыз дигәндә генә, ул барудан баш тартты. Шулай итеп, юлга берүзем генә чыгарга мәҗбүр булдым...

Төп максат: 1. Касыймдагы Ф.Бәшировлардагы язмалар һәм калган басма китапларның язмышын хәл итү. 2. Әҗе авылын күзәтеп, булган хәтле кульязмаларны табып кайту.

28.VI.1966. Бөркү генә кичтә юлга чыктым. Мәскәү аша. Ялгыз чыгуы бигүк күңелле түгел иде...

29.VI.1966. Иртәнге Мәскәү. Касыймга бара торган автобуска билет алып булмады. Шуның өчен төшкә каршы поезд белән Рязаньга киттем. Юлда 3 кенә сәгать булдым. Рязаньда коеп яңгыр ява иде. Монда да автобуска билет алып

[1] Текст 1966 елгы 5 нче археографик көндәлек нигезендә әзерләнде. – ***Ред.***

булмады. Шуңа күрә төкердем дә, «Лесков» дигән теплоходка утырып, Ханкирмәнгә юнәлдем. Дөрес, пароходта баруы яхшы гына булды.

30.VI.1966. Касыймга көндезге 1дә килеп җиттем. Пристаньдагы дебаркадердагы «миһманханәгә» туктадым. Шәп: бер кешелек кечкенә генә каюта. Монда да яңгыр матур гына явып алды. Кибеткә барган арада тәмам чыландым (чалбар адәм карамаслык хәлгә килде…). Димәк, көне буе өйдә ятарга туры килә: чалбарым берәү генә бит!

1.VII.1966. Иртәнге якта шәһәр башкарма комитетына кереп, бер аңгыра сарык белән сөйләшеп чыктым. Гаҗәп: шулхәтле наданны нишләп биредә тоталар икән?

Яңгыр сибәли. Итакаевларга кердем. Онытмаганнар. Мәхмүзә апа бик шатланып каршылады. Ә Нурмөхәммәт абзый чирләп ята икән. Шактый сөйләшеп утырдык. Бәшировларга килдем. Өйдә Һади абзый гына икән. Ул да бик күңелле каршылады. Бераздан мунчадан Фәрхәнас апа да кайтты. Караңгы кичкә хәтле шунда булдым.

2.VII.1966. Педучилищега барып, тиешле кешене күреп сөйләшеп, мәсьәләне хәл иткәч, тагын Бәшировларга килдем. Аларның аталары Фәттахетдин Бәшировтан (мулла һәм мөдәррис) калган шәхси китапханәне карап утырдым. Дини әйберләр белән бергә, дөньяви китаплар да шактый (әдәбият, тарих, философия һ.б.). Ә журналлар бик күп: «Шура»ның бөтен саннары да бар! Тагын әллә нәрсәләр! Мәсәлән «Әл-ислах», «Өлфәт», «Тәрҗеман», «Йолдыз», «Азад халык» һ.б., һ.б.! Бу коллекцияне алырга кирәк. Тик ничек? Әгәр үзләре почта белән җибәреп бирсәләр, букинистик магазин аша түләп тә алырга мөмкин булыр иде. Үзләре риза булсалар, Казанга кайткач ук, андагыларны күндерергә кирәк.

5-6 кулъязма да бар. Арасында Һибәтулла Салихов, Г.Утыз-Имәни шигырьләре, Г.Курсавиның «Һәфтияк тәфсире» һ.б.

3.VII.1966. Төшкә хәтле иске зираттагы ташларны карап йөрдем. Ә төштән соң тагын Фәттахетдин хәзрәтнең китап киштәләрен актардым. Әйе, бу коллекцияне, һичшиксез, алдырырга кирәк!

4.VII.1966. Бүген берничә йортка кереп чыктым. Әһәмиятле әйберләр юк. Дөрес, Николай I дәверенә караган бер ташбасма китап бар. Һәм куфи Коръәннең Петербург басмасы.

5.VII.1966. Көннең беренче яртысын пляжда уздырдым. Шәп тә соң Уканың бу алтын комнары! Көн дә бик матур иде. Төштән соң берничә йортка кереп чыктым. Артык бернәрсә юк. Шулай да Әҗе турында шактый мәгълүматлар җыйдым. Иң мөһиме: Ибраһим карый Урманов[2] дигән зыялы картның бала-чагаларын табарга кирәк!

6.VII.1966. Әҗегә бара торган самолетка билет алгач, шактый вакыт алтын комда хозур итеп яттым. Кичен тагын халык арасына чыгып кердем. Кулъязма бөтенләй юк. Басма китаплардан Г.Исхакыйның «Кәләпүшче кызы», И.Бикмөхәммәтнең «Сәяхәтнамәсе», Саблуков басмасы бар…

[2] Ибраһим Урманов (1873-1958) – Коръән-хафиз, Әҗе авылында туган, «Әл-Әзһар» университетын тәмамлап, туган авылына кайта, совет чорында имам вазыйфаларын башкара.

7.VII.1966. Ермиш, Кадомнарны узып, иртәнге сәгать унда Әҗегә җиттек. Үзәнлектә урнашкан зур гына авыл. 420 йорт булыр. Элек тагы да зуррак булган булырга тиеш: сүтелгән йортларның урыннары бик күп. Башта гел татарлар гына булган, ә хәзер – аралаш. Авыл советы мөдире юк иде. Шул арада ашханә тирәсендә Ерзин Галим дигән кеше (укытучы) белән таныштым. Сөйләшә-сөйләшә Ибраһим карыйларга киттек. Картаеп беткән карчыгы һәм бер зәгыйфь улы бар икән, Исмәгыйль исемле (үзе 4-5 ел элек үлгән). Яхшы гына каршылады. Актара торгач, ике дистәгә якын кулъязма аердым. Шактый борынгы әйберләре дә бар сыман. Иртәгә алырга булыр, хуҗалар ризалар. Мин караган китаплар зур көтепханәнең бер бәләкәй генә өлеше. Димәк, Ибраһим картның көтепханәсе заманында бик бай булганга охшый. Ләкин кызганыч, ул китапханәнең зур өлеше хуҗа үлгәч җиргә күмелгән... Менә әшәке гадәт!..

Авыл советына килдек. Рәис үзендә икән. Сөйләшә торгач, бездә укып чыккан Әхмәт Борнашевның шушы авылдан булуы ачыкланды. Ул үзе дә хәзер авылда икән, тукталыр өчен шуларга киттем.

Әхмәт каядыр киткән иде. Чемоданны өйдә калдырып, авыл янындагы тау башына мендем – авыл да, әйләнә-тирә дә матур гына. Бераздан Әхмәт тә кайтты. Егет шактый үскән, шомарган, кешелеге, кешегә мөнәсәбәте нык үзгәргән (ә бәрәңгегә эшкә барганда шактый дорфа, төксә бер әкәмәт иде!). Ярар, кулъязмалар табыла башлады.

8.VII.1966. Иртәнге якта Әхмәт белән бергә Шәриф абзый Бисеров дигән кешеләргә килдек. Моның хатыны чоланнан йортның элекке хуҗаларыннан калган китап һәм кулъязмаларны чыгара башлады. 4-5 кулъязманы алдык. Шулар арасында Сәгъдинең «Дастаны Бабахан (Таһир-Зөһрә)» поэмасы бар – Урта Азия нөсхәсе. Шулай ук Нәдаи дигән бер галимнең «Нафигъ ән-нас» дигән медицина буенча язган китабы. Сәхибгәрәй хан заманында язган, Кырымда язганга охшый, теле шуңа ишарә ясый...

Зиратны барып карадык, ләкин бернинди таш та юк. Мәчеткә килдек. Анда китаплар шактый икән. Карый башлауга, җомга намазы башланды, тышка чыгып көтеп тордык.

Көн матур гына. Авыл ярыйсы гына яшел. Тормыш та ярыйсы кебек. Мәчет әһеле «йомыш»ын бетергәч, без кереп актарына башладык. Төрки әйберләр аз очраса да, гарәпчәләре шактый. Бик борынгыга охшаганнарын аерып алып, калганнарын калдырып торырга булдым (диниләр бик мөһим түгел, аннары икенче килүгә хәтле сакланып торырлар – барлыгы 20 данә китап).

Кайтышлый, Ибраһим картның карчыгы Маһирә әбигә кереп, кичә сайлап куйган китапларны бер ящикка салып алып чыктык. Ибраһим Урманов язган бер парча «Әҗе тарихы» дигән әсәр караламасы да бар (карчык аны кире җибәрүне сорый...).

Өйгә кайтып ял иткәч, табылган китапларны ике ящикка салып, посылка итеп Казанга җибәрдем. Барлыгы 15 кг. Шулай, кулъязмаларны потлап кына үлчи башладык! Ә табыш, гомумән, начар түгел. Бер «Таһир-Зөһрә»нең яисә «Бабахан» дастанының Урта Азия кулъязмасы табылуы да безнең өчен зур казаныш: аны татарныкы дип маташучыларга клизма куеп була!..

Халык, гомумән, якты чырайлы, кунакчыл. Эчү белән артык мавыкмыйлар – исерекләр юк дәрәҗәсендә.

Бер абзыйларга барып утырып, 1924 елны басылып чыккан Әҗе авылы тарихын карадым. Аны язучы Аллаяр Беляшев 30 нчы елларда туберкулездан үлгән икән. Әсәр ярыйсы гына кызык язылган. Шәҗәрәләрдән яхшы гына файдаланган,

этнографик материаллар да шактый. Кичен Борһан Бикбулатов дигән һәвәскәр язучының улыннан (үзе үлгән) «Гөлбану» исемле сәхнә әсәренең кульязмасын алдым.

9.VII.1966. Көндезге сәгать 11дә Касыймга кайтып төштем. Рәхәт бу «кукурузник» – теләсә кайда утыра, илле метр йөгереп очып та китә. Астагы дөньяны күзәтер өчен дә җайлы. Ә аста – сөзәк урманнар, кечкенә-кечкенә саз күлләре, бормаланып аккан инешләр. Бөтен әйләнә-тирә ямь-яшел.

Сәяхәт ярыйсы гына: әллә ни зур табышлар, мәсәлән, борынгы татар тарихлары табылмаса да, кульязмалар шактый. Әһәмиятле генә әйберләр дә бар. Бәлки, киләчәктә тагы бер кагылып чыгарга булыр… Беренче күзәтүемә караганда, бу тирәдә элек әдәбият бик киң таралган булган. Әллә кайларда басылган әйберләрне дә күрергә насыйп әйләде. Мәсәлән, Каһирәдә басылган Ибн Халдунның «Мөкаддимә»се, Якутның «Мөгаҗҗәмә»се һ.б.

10.VII.1966. Көн яңгырлы булганга, бары төштән соң гына тышка чыга алдым. Бәшировларга барып, аларның китапларын тагы озак кына актардым. Ләкин җен суккан әби котымны алды: имеш, «Казан утлары» журналын япканнар! Редакциядән шундый хат килгән! Нәрсә бу? Күзләрем маңгайга чыкты. Тик шунда ук «хат» дигән әйберне карап, аның почта открыткасындагы «подписка аннулирована» дигән сүзләрне укыгач, үземнән дә, әбидән дә көлеп алдым… Мин тынычландым, тик әбием һаман үзенекен тукый: аңа акчаны кире кайтаргач, журнал ябылган булып чыга, янәсе… Аның үзенә күрә дәлиле дә бар: журнал нигезләнгәннән бирле даими абоненты ул!..

Казанга кайткач белешеп, подписканы рәтләп, үз фикеремне расларга вәгъдә бирдем. Уйлавымча, бу әби жандармнар чоры буенча фикер йөртә шикелле…

11.VII.1966. Иртәнге якта берничә йортка кереп чыктым. Нәтиҗәсез. Төштән соң тагы Бәшировларга бардым. Сайлап алган кульязмалардан тыш, берничә басма китап та алдым. Бер төркемен посылка итеп Казанга җибәрдем. Кыскасы, бу сөйкемле һәм гаҗәеп кызыклы гаиләне ике елдан бирле шактый имдек. Ичмаса, бераз файда да эшләп булса иде! Бәлки, журнал һәм газета комплектларын, басма китапларны сатып алу, ягъни акча түләү хакында тырышырга кирәктер?! Минемчә, шулай эшләү хәерле: алар бу кульязмаларны безгә бушлай бирделәр бит! Китапларны җыюда, саклауда күп көч куйганнар. Димәк, әҗерен дә күрсеннәр. Ярар, иртәгә сөйләшәм һәм арадашлык тәкъдим итәм.

12.VII.1966. Бәшировлардан алып кайткан кульязмаларның берсен (аны почтага салмаган идем) озак кына карап утырдым. Исеме «Монаббиһат», һиҗри белән 1039 елда күчерелгән, ягъни 1629/30 елда. Теле саф төрки. Матур. Күчерелүе Касыймда (колофонда шулай күрсәтелгән). Почеркы да ярыйсы гына. Әлбәттә, татар күзлегеннән караганда. Җентекләп тикшерәсе иде әсәрне…

Төштән соң тагын Бәшировларга бардым. Кичәге планны тәкъдим иттем. Әби чак кына аптырап та калды. Риза, әлбәттә! Саубуллашып аерылыштык.

13.VII.1966. Иртәнге 7дә тордым. Юл настроениесе булганга, йокы иртә ачылды. 9га хәтле йоклап яттым. Аннары калган китапларны посылка итеп салдым. Билет та алынды. Киттем пляжга, ичмасам, озак-озак итеп коеныйм, кызыныйм, рәхәтләнеп


-V- сәфәр

Рязань өлкәсе, Касыйм шәһәре, Әүк авылы

28 июнь – 15 июль 1966 ел

бер ял итим. Бу Касыймга тагы әллә килермен, әллә юк. Ә аның алтын пляжы үзенә күрә шәп!

Ял әйбәт булды. Гомумән, бу юлы бик үк арылмады. Аннары хәрәкәт ягыннан да, хәстәрен алдан күреп чыккач, мул гына яшәдем. Ә Мәскәүгә дигән автобус төнге 10 тулып 35 минутта кузгалачак. Димәк, төнлә ял булмаячак.

Кичен салкын душка кереп керләрне дә, «гөнаһ»ларымны да юып чыктым.

14.VII.1966. Төне буе йөреп, иртәнге сәгать 6да Мәскәүгә җиттек (автобуста йоклап булмады, бер ярты сәгать кенә черем итеп алдыммы-юкмы). Яхшысы, Касыйм автобусы Казан вокзалына килеп туктый икән. Тиз генә Кемерово поездына билет та алдым. Сәгать 11 дә 40 минутта тагы юлга чыктым. Казан ягына. Әлбәттә, көне буе йоклап бардым.

15.VII.1966. Казанга иртәнге сәгать 3тә җиттек. 4тә ишек алдында идем. Ләкин парадный ишеге ябык, үземдә ачкыч юк. Шакып кеше уятасы килми. Хәер, тиздән коридордагы күрше дворниклар уяна башларга тиешләр. Шуңа күрә тамбурдагы ике мәче белән кеше уянганны көтеп утырдым. Ә иртә искитмәле матур, саф иде…

Археографик көндәлекне басмага ***Диләрә Госманова*** *әзерләде.* ■

Коточкыч ачлык

СӘХИФӘ ИДЕЛ БУЕНДАГЫ 1921-1922 НЧЕ ЕЛГЫ АЧЛЫКНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА ҺӘМ АЧЫГЫП ВАФАТ БУЛГАН МӘРХҮМНӘР ИСТӘЛЕГЕНӘ БАГЫШЛАНА.

Үлүчеләр тавышын ишетегез!

Яшәр өчен көрәш Татарстан Җөмһүриятендә куркыныч төс ала. Ачлык көннән-көн көчлерәк һөҗүм итә бара. Менә сезгә төрле оешмаларның һәм вәкилләрнең доклад һәм актларыннан алынган өзекләр: «...кеше түгел, бәлки, шәүлә генә», «аяклар көчкә-көчкә генә кузгалалар, гәүдә урынына бик нечкә тире белән төренгән скелет (сөякләр)», «ата-аналар көченнән тайганнар һәм аларның балаларын күмәргә хәлләреннән килми», «өйләрдәге һавалар җирәнгеч, авыр, аш пешерә торган казаннар күптән бирле тазартылмаган, юылмаган һәм алар анда пешерелгән төрле үләксәләрнең сасы исләрен таратып торалар», «ат тизәкләре ашап ризыкланудан килгән үлем вакыйгалары да бар» (табиб Никольский бәяненнән), «алты кешедән гыйбарәт бер өй җәмәгате соңгы вакытларда бары тик эт һәм мәче ашап кына тереклек итә, минем күз алдымда алар кыздырылып җитмәгән чи мәчене ашый башладылар» (Спас ачларга ярдәм комиссиясе рәисенең докладыннан).

«Беренче гыйнварда Гусихин волостенда Иске Такталы авылында Степан Малов (32 яшендә) һәм аның хатыны Надежда (30 яшендә), ачлыктан үлеп һәлак булу алдыннан (беренче участка халык тәфтишчесе докладыннан) үзләренә кардәш тиешле тугыз яшьлек Никонорның күз алдында, үзләренең үлгән җиде яшьлек уллары Феофилны тураклап, аның төрле кисәкләрен ике мәртәбә салып кайнатып ашарга керешкәннәр».

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2021) санында.

Бу вакыйганы тәфтишче *(тикшерүче)* участкасындагы хәлләрне тәгърифкә *(аңлатуга)* керешеп, анда ачлыктан үлү вакыйгалары бик күп булганын сөйли һәм: «Әгәр хәзер үк ярдәм ителмәсә, бөтен халык ачлыктан үлеп бетәчәк», – ди.

Менә тагы куркынычлы тәнбиһ *(кисәтү)*. Спас кантонындагы балаларга ярдәм рус-америка комитеты әгъзасы иптәш Баринов үзенең докладының ахырында ачыктан-ачык игълан итә: «Әгәр дә тиздән ярдәм булмаса, ул вакытта кеше ашау вакыйгалары бик тизлек белән артачак, ачлыктан үлүләр турысында сөйләп торырга да туры килми», – ди.

Нәкъ шуңа охшашлы торган хәбәр һәм мәгълүматларны бер пункттагы фельдшер белән авыл советы рәисенең имзалары белән бирелгән шикаятьләрдә дә күрәбез: «Кайбер йортлардагы авыруларны караган вакытта моннан соң да шундый мәетләрне ашау вакыйгаларының булуын ихтимал тотарга һәм шуны көтәргә бик мөмкин икәнлеге күренә һәм авыл советларының бөтен үлгән кешеләрне тикшереп торырга хәленнән килми, шул сәбәптән, моннан соң да мәетләрнең ата-аналары тарафыннан ашалу ихтималлары бар», – ди.

«

Юк, булмас, бу дөрес түгел! Бу бит вәхшилеккә әйләнү...

Чистай кантонындагы ниндидер бер тимерченең хатыны әледән-әле, берникадәр тере балалар һәм зурларны суеп, аларны пешереп ашаган. Хәтта ул суелган кешеләрнең гәүдәләрен турап, «запас» өчен кисмәккә тутырып тозлап куярга да батырчылык иткән.

Шундый бик гади, хәйләсез, ләкин шуның белән бергә коточкыч сүзләрне укыган вакытларда чәчләр үрә тора. «Юк, булмас, бу дөрес түгел! Бу бит вәхшилеккә әйләнү, бу кеше кулыннан килә ала торган эш түгел!» – дип кычкырасы килә. Ләкин берни эшләр хәл юк, чөнки алар һәммәсе дә чын хакыйкатьләр. Кеше, ачлыктан үлүнең нык тырнакларына эләкмәс өчен, югары дәрәҗә, гакыллы булып яшәвеннән кул селтәп вәхшиләнә дә кеше ашаучыга әйләнә. Инде шушы хәлләр, вакыйгалар да, әлеге коточкыч хәбәрләр дә аз гына булса да тәэмин ителгән, хәлләре яхшырак халыкларны кечкенә һәм зур оешма һәм союзларны кузгата алмыймы? Болардан бик азлары гына Татарстан Җөмһүриятенең башына килгән бәлаләргә каршы җавап табышы бирделәр.

Чит мәмләкәтләрдән килгән киң ярдәмнәр дә, Татарстан Җөмһүриятендәге ачларга ярдәм комитетының чиктән тыш тырышлыклары да ачлык белән көрәшү өчен җитәрлек түгел.

Без, сифырларга кайтып карасак, Татар Җөмһүриятенең ни дәрәҗәдә ачыгуын күрербез. Менә 1921 елдагы хисаплар нәрсә әйтәләр: 442 678 кеше ашатыла, 2 260 904 кеше ач. 1921 елда җөмһүрияттә 428 803 кеше (бөтен халыкның 12,5 проценты) кимегән. Балалар арасында ачлык корбаннары тагы да күбрәк. 36 536 бала тәрбия ителә, 570 275 бала ач. 1921 ел эчендә 326 106 бала кимегән (бөтен балаларның 25 проценты).

Балалар – киләчәк тормышны төзеп, илне юлга салачак кешеләр. Балалар мәсьәләсе безнең үзәк мәсьәләбез, иң әһәмиятле мәсьәләбез булырга тиеш! Балаларны үлемнән коткару өчен җитди чаралар, ашыгыч ярдәмнәр кирәк!

Балаларны үлемнән коткарыгыз! Менә хәзерге көннең лозунгысы! Гражданнар, сез шул лозунгыны хәтерегездә тотыгыз!

Казаков Исхак

Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 2 февраль.

Балаларын ашаган

Спас кантонының Әлки волостенда Надежда Иванова дигән хатынның 5 баласыннан 2се үлгән. Анасы балаларның берсен бөтенләй ашаган, берсеннән фәкать аяклар һәм туралган кисәкләр генә калган.

Һәммәгез дә ярдәмгә ашыгыгыз. Мондый куркынычлы вакыйгаларның тәкърар ителүенә ирек бирмәгез!

Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 5 февраль.

Ачлык белән көрәш

Ачларга ярдәм комиссиясе һәм АРА тарафыннан бирелә торган паеклар бары кантондагы ачларның 25 процентына гына җитә, калган 75 процент халык төрле җәгълый азыклар белән тора. Боларның, аз дигәндә, өчтән бер өлешенә хәзер үк ярдәм кирәк. Балаларга бирелә торган паекларны киметә төшеп булса да, зурларга паекларны чиреген генә бирмичә, яртысын бирү мәгъкуль күрелә. Чөнки паек белән коткарылган байтак балалар ата-аналарының үлүләре сәбәпле һәлак булалар.

Терлек әкренләп кими. Ач халык, әле сабырлы халык, печән урынына агач яфраклары истигъмаль итеп, ачлык белән көрәшергә тырыша һәм Русиянең эшче-крестьяннары тарафыннан ярдәм килүне өмет итә. Крестьяннарның үзара ярдәмләшү комитетлары бар. Ләкин, сумма булмау сәбәпле, алар рәтләп эшли алмыйлар.

Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 6 февраль.

Ачлык дәһшәтләре. Кеше ашаучылар

Чистай кантоны, Кремень волосте, Аккиреево авылында Михаил Семенов исемле кеше үзенең хатыны Пелагея һәм улы Емельян белән бергә дүрт кешене иткә суеп ашаганнар. Үтерелгән кешеләр шулар: Елена Фомина – 12 яшендә, Кузьма Фомин – 16 яшендә, Евдокия Романова – 26 яшендә, Кузьма Евдокимов – 13 яшендә. Бу җинаятьче гаиләнең фатирында фәкать берничә кисәк адәм ите генә табылган.

Шул ук волостьтагы Карамыш авылында ике атналык бала ашалган.

Бөгелмә кантоны Бигәш авылында халык үлгән кешеләрнең мәетләрен ашый башлаган.

Чистай кантоны Каргалы волостеның Азеево авылында бер крестьян хатыны үлгән баланы ашаган.

Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 12 февраль.

Ачлык һәлакәте

22 гыйнвардан 29ына кадәр бер атна эчендә Татарстан Җөмһүриятендә ачлыктан –3373 кеше, тифтан 568 кеше үлгән.

Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 13 февраль.

*Сәхифәне **Рәйсә Шәрәфиева** һәм **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Безнең мирас №2 февраль 2021

Җәүһәр иясе Җәүһәриягә

(Кыйсса)

Әхтәм Зарипов

Әхтәм Зарипов туган авылы Тәҗәйдә (Илеш районы). Каралты-кураны җыештырган мәл. 1957 ел

Яр җимерелеп төшкәндер, дияр идең, аңа кадәрге һәйкәлләр дә, кабер ташлары да, кабер өемнәре дә төзек, урыннарында. Мәрмәр яки гранитына кызыгып, урлаганнардыр, дисәң, һәйкәле күтәреп чыгарлык түгел. Машина керерлек юл да юк. Газизәдән сорар өчен зират йортына таба атладым.

– Бик тиз борылдың, – дип каршылады Газизә.

– Тегендә очрашып сөйләшергә калсын, – дидем. – Ахирәттә.

– Васыятеңне шушы зиратта җирләргә дип әйтеп калдырасыңмы? Казандамы?

– Анысын онигым хәл итәсенә ышанам.

– Ә нәрсәгә ышанмыйсың?

– Авылыбызның кайбер имансызларына.

– Кемнедер имансыз диярга хакыбыз бармы соң безнең?! Юк бит!

– Минем хакым бар: авиация полковнигы Ривнерның мәрмәр-гранит һәйкәлен урлаганнар.

– Һәйкәлен дә, сөякләрен дә Канадада яши торган улы Литвадагы мөселман зиратына җирләнгән анасы һәм әбисе янына санитар самолетында алып китте.

– Сул колакны уң кул белән кашыйсың, Газизә. Халыкара хәлне беләсең.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2021) санында.

Кем инде әллә кайдагы Канада бандитына урыс полковнигының мәете белән Хәрби комиссариат куйган Совет һәйкәлен самолетта урларга рөхсәт бирсен?!

– Бандит түгел ул, Нобель премиясе лауреаты! Физика-математика ачышлары өчен бирелгән бүләкле галимебез.

– Татар фамилияле лауреат юк. Әкият сөйләмә.

– Ә ул анасы фамилиясендә.

– Белмим-белмим. Әкият бу.

– Документларын тикшереп, КГБ өчен фотога төшердек. Шик тапмадылар. Полковникның сөякләрен җирләп, аңа яңа һәйкәл куйгач суккан телеграммасы мәчеттә саклана. Авиация полковнигын ике һәйкәл саклый. Ата-анасына, әби-бабасы рухына дога кылучыларга сәдакага калдырган долларлары мәчет кассасында.

– Андый халыкның авантюрный эшләргә осталыгын белмәгәч, сезне гаепләп булмый. Лауреатлыгын белдереп, юмартлыгын күрсәтергә сәдака гына таратмасын, ярның ишелүен туктатырга һичьюгы бетон плитәлек акча күчерсен иде ул.

– Анысы инде мондагы варислар эше.

– Син дә варис, мин дә варис, атка печән кем сала?

– Мәчет идарәсе әһелләре сиңа ышана. Җирле үзидарә рәисе дә синнән көтә.

– Мин бит әлегә Нобель премиясе лауреаты түгел.

– Мәчет идарәсе синнән акча өмет итми. Синең абруең үзе акча, диләр.

– Сәдака көтәме?

– Сәдаканың төрлесе бар. Зәкят, гошер, фитыр, фидия вә хәффарат сәдакалары – фәкыйрьләр хакы булган фарыз сәдакалар. Аларны фәкыйрь булмаган кешегә бирү яки юл төзәтү, күпер эшләтү, кое-чишмәләр казыту, күл чистарту, мәчет-мәдрәсәләр салдыру кебек җәмәгать файдасы өчен булган эшләргә тоту дөрес түгелдер. Фәкыйрьләрнеке – фәкыйрьләргә! Гарипләргә!

– Хәзер фәкыйрьне каян табасың? Баедык бит, Газизә, череп баедык.

– Мәзкүр сәдакалардан башка сәдакалар, халык файдасы өчен тотылачаклары – нәфел сәдакаларыдыр. Аларның урналары мәчеттә аерым куелган. Нәфел һәм зәкят – икесе ике нәрсә.

– Нәфел сәдакалары бирү саваплы, мөстәхәб гамәлләрдән дип тә өстә инде, Газизә.

– Нигә көләсең?

– Шома сөйләвеңнән.

– Сүзем озынга китүдә гаепле булсам да, динебез сафлыгы өчен саваплы булуыма ышанам. Ягъни бергә – бер. Пока, бабай, аллаһуәкбәр, хуш.

– Спорт яратасыңмыни шулай?

– Хоккей белән бокс ярышларын күрсәтсәләр, калдырганым юк.

– Минем улым да хоккей дип машинасында үлде. Матчка өлгерәм дип ашыккан… Калдык ялгыз икәүләп.

– Икәүләп булгач, ялгыз түгел ич.

– Күңелләребез генә бергә безнең.

– Аңлашылмый торган хәлдә икәнсез.

– Кайчак үзебез дә хәлебезне аңламаудан гаҗизбез. Газизә, син аңласаң иде шуны.

– Язмышыгыз шулай, димәк. Язмыш бу!

– Язмыштан узмыш бар икән тормышта, Газизәкәй, узыла икән.

– Ишеткәнем юк иде.

– Аны ишетүнең сиңа әлегә кадәр кирәге булмаган. «Газизәкәй балдыз, калдырма ялгыз…» җырын беләсеңме?

– Нигә әбине бу очрашуга алып килмәдең? Бу да язмыштан узмыш хәлме? Ялгыз калдыргансың ич.

– Бриллиант туебызда да кара шәлен салмады шул ул.

– Акча күп тотылыр дип курыккансыздыр.

– Хатын-кыз барысын да исәпкә ала шул.

– Кермәгән сәдакага өметләнергә без мәчет күселәре түгел.

– Үпкәләттем, ахры? Күземне ачтың: димәк, мәзкүр сәдакалардан башкалары халык файдасы өчен тотылырга тиеш? Алар нәфел сәдакалары дип атала. Аларны җыю урналары мәчеттә аерым саклана икән. Шулаймы?

– «Урна» дигәнең гадәти 2 почта ящигы. Өстенә язылган, биклеләр.

– Ачкычы синдә сакланамы?

– Нидән шикләнәсең?

– Безнең илдә миллионнар хатыннары йә оныклары исемендә саклана бит. Шуннан чыгып кына соравым.

– Ул мәсьәләдәге сорауларыңны хәзрәтебезгә бирерсең. Ахшамнан соң ул сине көтәчәк.

– Син анда буласыңмы соң?

– Мин сезнең сөйләшүне язып алырга тиешмен. Диктофонга.

– Органнар өченме?

– Диния нәзарәте өчен. Җирле үзидарә рәисе дә булачак.

Газизә шул сүзне әйтүгә, эчке кесәмдәге телефоным «әтәч булып» кычкырды. Сигнал кунакханәдә кунарга калган инженер Камилдән иде. Үзенә тапшырылган йомышларны үтәгән, күрәсе кешеләрне күреп сөйләшкән. Район китапханәсенең җыелышлар үткәрү залында зур экраны да, видеопроекторлары да бар, очрашу шунда уздырылырга тиеш, кайсы кассетаны калдырып, кайсыларын авылга алырга, дип сорый. «Билет сату-сатмау мәсьәләсен дә, син шалтыратып әйтмичә, кассирга күрсәтмәләр бирмибез. Ничек тә бүген бәйләнешкә кереп, деликатный мәсьәләне хәл итәргә тырыш», – диде. «Деликатный» мәсьәлә, имеш. Мондагы эшләр андагыдан да «деликатныйрак». Минем әле һаман зираттан чыгып китә алганым юк. Судан коры чыкмакчы булып, «саз»га кереп баттым. Әллә кайчангы онытылган хисләрем шул «сазлык»ка тарта. Ярый әле үз вакытында телефоным «әтәч булып» кычкырды. Коткарды димәсәм дә, аркан ташланды, шуңа тотынып, баткаклыктан чыгу минем өстә.

Өстемә алган башка гамәлләрне үтәү йөзеннән, су тегермәнебез булган урынны карарга киттем. Төшереләчәк яңа фильмымда «тегермән эпизодлары» күп, ягъни ул булырга тиеш дип планлаштырылган иде. Тик тегермән түгел, хәтта урыны да юк. Татлысу елгасы башка юл табып ага башлаган. Һич көтмәгәндә-уйламаганда, «елгалар да, хатын-кыз кебек, тиз үзгәрәләр икән» дигән кирәкмәгән уй баштан узды. Киттем авылыбызның чишмәләрен, күлләрен карарга. Тик аларны да тапмадым. Корыганнар-кипкәннәр. Язгы ташу суы кермәгәч, Үлетатлысу дип йөртелгән балыклы зур күл, тәмам корып, җикәнкамыш баскан сасы канауны хәтерләтә. Ә мин бит Үлетатлысу дигән күлдә әткәй ясаган көймәдә үзебезнең бакчага кадәр барган идем. Хәзер Үлетатлысу урынында шакшы су да юк. Кыскасы, фильм өчен кирәкле объектларның берсе дә калмаган. Гомумән, ял итеп рухланырга дигән, без үскән чордагы авыл мохитенең исе дә, хәтта исемнәре дә сакланмаган. Ә кеше исемнәре исә заманга яраклашкан: Эльс, Мэлс, Ленар, Аврора, Казбек кебек атамалар. Нишләмәк кирәк, аты Ферсман булса да, муллабыз шул булгач, киттем мәчеткә. Бәлки, ул аңлатыр.

Ахшам узган булса да, көтәләр иде. Сәлам биреп кердем, исәнләштек. Утырыштык, «әппәр иттек». Көтелгән сүзне, традиция буенча, хәзрәт Ферсман башлады. Газизә, диктофонын чыгарып, өстәл уртасына куйды, язу башланды.

Баштарак сүз мин төшергән кинофильмнар турында барды. Гаҗәпләнүемә каршы, Ферсман хәзрәт күп фильмнарымны караган, искәрмәләре мәгънәле, тәнкыйть сүзләренә дә кушылмаслык түгел иде.

Барысы өчен дә рәхмәтемне белдергәч, хәзрәтем, минем иҗат план-

нарым белән кызыксынып, үзенең киңәшләрен бирде. «Сәнгать ул аксакка култык таягы түгел, ә юлчының «капшау» таягы, урыслар аңа, посох, диләр», – диде. Мин, аны төзәткәндәй: «Сукырга посох култык таягыннан да кирәгрәк», – дидем. Ул: «Иҗатта сукырларга таяну – үзе сукырлык», – дигәч, «пластинка»ны алыштырып, авылыбыздан чыккан күренекле шәхесләрне барлый башладык. Ферсман үзе дә Бүләковлар токымыннан. Ничәнче буыннан, кайчан аерылуын төпченеп тормадым. Аның әйтүенчә, әтисенең энесе партия өлкә комитетының идеология буенча сәркатибе булган. Аның ярдәмендә үзе дә шул юлдан киткән. «Үкенмисездер бит?» – дигәч, ул Тукай сүзләре белән: «Узган эш кайтмый, үкен син, үл, ела», – дип елмайды гына. Шуннан хәзрәт башка күренекле шәхесләрне барлый башлады. Янгуразов булып йөрүче бер Бүләков токымы – нефть заводы директоры; хатыны фамилиясенә күчеп, Волков булып йөрүче Бүләков – «Нерудные материалы» дигән шахтаның директоры, һәркайсының адресы саклана. Кызыксынсаң, бирермен, алар миндә бер дәфтәр. Барысы да шул Бүләков токымыннан. Ә Бүләк бабай авылыбызга исем биргән Таҗый карт сеңлесенең җилдән туган улы кавеменнән икән.

– Җилнең ниндие юк та, кавемдә кемнәр генә булмый, – дигән булдым әңгәмә өзелмәсен өчен генә. Хәзрәт Ферсман, сүзен дәвам итеп, дәфтәрен бирде дә:

– Синең дә, минем дә бер тамырдан булуыбыз бәхәссез. Кайсыдыр буын бабабыз Нурислам 1813 елгы урыс-француз сугышында сотник буларак тимер тәре белән бүләкләнгән. Патша Александрны саклап, Парижда булган. Польшадагы әсирләр бунт күтәргәч, аларны Минскига озатучы өлкән конвой буларак көмеш кылыч, күн ияр, 300 гектар урман, 3000 гектар сөрү җире белән бүләкләнгән.

«Мин, аны төзәткәндәй: «Сукырга посох култык таягыннан да кирәгрәк», – дидем. Ул: «Иҗатта сукырларга таяну – үзе сукырлык», – дигәч, «пластинка»ны алыштырып, авылыбыздан чыккан күренекле шәхесләрне барлый башладык.

– Легенда гынадыр бу, – дидем мин.

– Мәсҗет мөрите Зәкария Коръән кырыена: «Бояр Нурислам җирләрен эшкәртүдә катнашучылар алган уңышның чиреген үзләренә калдыра», – дигән язу калдырган.

– Петр патшаның боярлар сословиесен бетергәнлеген беләбез. Бәлки, Нурислам бабабызга дворян титулы бирелгәндер? Әгәр шулай икән, аңа ничәдер җан крестьян бирелүе турында архивта берәр төрле документы – тәзкирәсе сакланырга тиештер. Бармы шулар?

– Аны табып, авылдашларны куандыру нәкъ менә синең эш инде.

– Мин инде үземнең бабам – картәтәй документларын эзләтеп бер яндым. Кабат андый четерекле эшкә алына алмыйм. Легенда булып яшәсен.

– Көмеш кылыч, күн иярне колхозлашу чорына кадәр буыннан-буынга күчереп саклаганнар. Шул кылыч белән куркытып, синең картәтәңнең патша башлы медален колхозның беренче рәисе күлгә ыргыттырган, имеш.

– Пәри – башка, җен – башка, дигәндәй, бусы бөтенләй башка легенда.

– Димәк, сине тарих кызысындырмый?

– Мине иртәгә якташларым белән булачак очрашу кызыксындыра.

– Аның көн тәртибе билгеле: иҗатың турында сөйләп, сорауларга җавап

биргәч, ияртеп килгән артистларың концерт куялар да, тәнәфестән соң берәр фильмың күрсәтелә.

– Почта ящиклары әзер.

– Нигә кирәк алар?

– Сәдака салырга.

– Зинһар өчен, куймагыз!

– Коры кашык авыз ерта…

– Мин сезгә җиде фильм калдырам. Без киткәч, үзегез карарсыз. Әмма безнең алда билет сатмагыз.

Шушы сүзне әйтүне генә көткәндәй, ике егет килеп керде. Сәлам биреп сәлам алышкач, хәзрәт Ферсман безне таныштырырга булды:

– Күренекле сәнгатькяребезне беләсез инде, ягъни танйсыздыр?

– Аны белмәгән, танымаган кеше республикада бармы икән?! – диде район советы депутаты значогы таккан, җирле үзидарә рәисе булуы йөзендә чагылган егет. Аңа каршы мин сүз әйттем:

– Экология буенча җаваплы түрәләр танымый шул. Танысалар, «Башкирия» һәм «Кызыл таң» газеталарына язган мәкаләләремнең берәрсенә булса да җавап биргән булырлар иде.

– Җавапны алар түгел, ә Министрлар Советы бирә. Әтисенә охшатып таныйсыздыр: менә бу егет Фәрхетдинов Әхнәф улы – Фәрит Әхнәфович – республиканың иң популяр җир-су банкының хуҗасы, безнең авылның инвесторы буларак, соңгы атна-ун көн буе гел Министрлар Советын саклады. Хәзер ул барысы турында да безгә отчет бирер.

– Эшләнмәгән эшләр өчен отчет биреп булмаса да, эшләнгән эшләр өчен, авылдашыбызның республика газеталары аша чаң сугуы өчен рәхмәтебезне журналистка белдерергә тиешбез. Рәхмәт аңа. Ул күтәргән мәсьәләләр тиешле югарылыкта тикшерелеп, махсус карарлар кабул ителде. Менә алар…

Мин шунда тыела алмадым:

– Бездә карарлар кәгазьдә кабул ителеп, аны оныту традиция инде ул, – дидем.

– Үтәлгәннәре дә булгалый ич, – диде җирле үзидарә рәисе Тәлгать, Фәрит Әхнәфовичка карап.

– Киләчәкне юрау дөрес булмас, әмма кабул ителгән карарлар тынычландырырлык. Укыйм: «190 чакрымга сузылган Татлысу елгасы буендагы 3 районның 27 колхозы…»

– Хәзер колхозлар юк ич, – дип кысылдым сүзгә.

– Колхозлар булмаса, авыл җирлекләре, шәхси хуҗалыклар бар.

– Шуннан?

– Кем хуҗалыгы булуына карамастан, барысы да елга буена салынган абзарларын, бәдрәфләрен алырга, елгага шакшы ага торган торбаларын җир өстенә чыгарырга тиешләр. Әгәр хуҗалыкларның кереме миллионнар белән икән, карарны үтәү бер айдан соңга кичектерелсә – 500 мең сум штраф, керемнәре меңнәр белән исәпләнүче шәхси эшмәкәрләргә 100 мең сум штраф түләү каралган.

– Кемгә түләү?

– Хөкүмәткә.

– Зарары – безгә, штрафы – хөкүмәткәме? – димичә түзә алмадым.

– Хөкүмәт органнары елганы терелтү буенча күреләчәк чараларда катнашачак.

– Мәсәлән?

– Хәзердән үк тегермән буасы өчен кирәкле ташларны чыгарып урынына ташыту буенча эшләр башланырга тиеш. Аның өчен тракторлар, бульдозерларыбыз бармы?

– Элекке кебек, буаны глиналы салам белән буып булмый бит, режиссер абый, бу эш кино төшерү түгел. Таш чыгару, таш ташу эшләре белән параллель рәвештә, үлгән сулыкларга су күтәрелгәч, чиста су керсен өчен елга ярыннан каналлар ачып, бетон трубалар салырга нинди техника кирәген тәгаенләргә белгечләр чакырасы бар. Андый эшләрнең барысы да сметада күрсәтелеп, имзалар алынды, графикларга салынды, эшлисе генә калды.

Әхтәм Зарипов Көязтау һәм Базы елгасы буенда. 1957 ел

– Ничә елга сузылачак инде бу кәгазьдәге эшләр?

– Тегермән буасы төзелеп, тегермәне он һәм электр тогы бирә башлаганчы.

– Димәк, аларны күрү миңа насыйп булмаячак?

– Насыйп кына түгел, син әле экология эксперты буларак җавап бирәчәксең, абзыкай.

– Теге дөньяданмы?

– Газеталарда! Эксперт буларак, сиңа эш хакы һәм лаборант штаты бирү каралган. Менә, үзең укып бак.

– Анысы кем тагы?

– Татлысуның исеме аклануын күзәтү лабораториясе хезмәткәре.

– Аңа хезмәткәр кирәкми. Һәркем үзе татып карап әйтә ала.

– Әйе, эш аңа барып җитсә, шакшы белән чистаны гына аерып идек әле.

– Мине корыган күлләребезне чистарту проблемасы борчый, Фәрит Әхнәфович.

– Ике экскаватор килү каралган. Суытып, күлләр экскаваторларны күтәрерлек туңгач, алар көннәр җылыта башлаганчы күләмен ярларына алып ташлаячаклар. Бу эшләрнең һәркайсы үз вакытында эшләнсә генә, буа буылып, шлюзлар ябылачак.

– Җәмәгать! – диде хәзрәт Ферсман. – Ясыйгъ намазы вакыты җитте. Хыял-планнарыбыз тормышка ашсын өчен догада булыйк та иртәгәгә кадәр хушлашыйк.

– Хушлашканчы, килгән кунакка берике сәлам бар иде, – диде Тәлгать.

– Тыңлыйм, – дидем. – Әмма мин килгән кунак түгел, ә өенә кайткан хуҗа.

– Килгәндә, кайтканда әүвәл рәискә күренеп, исәнлек-саулык сорашалар иде. Ә син туп-туры зиратка.

– Чөнки зират минем якын киләчәгем бит.

– Тәүбә, диген. Кайттым, дисең, ә үзең Җәүһәрия җиңгине дә алып кайтмагансың.

– Кем инде урманга – утын, болынга самовар күтәреп бара?!

– Кара аны, иртәгә кайтасы кунакларның күзеннән саклан. Таҗыйлыларның егетләре генә түгел, кыз-хатын, киленнәре дә күз тидерергә һәвәс.

Очрашу мин күз алдыма китергәннән дә кызыклырак узды. Җавап сүземдә: «Мин «Кызыл таң» һәм «Башкирия» газеталарында язганнарымны гына кабатлый алам», – дигәч, бертавыштан: «Беләбез», – диделәр. Банкир Фәрит Әхнәф улы сөйләгәч, аңа һәм миңа карап, озак кул чаптылар.

Концерттан соң җирле үзидарә оештырган банкетка алып бардылар. Башкорт язучыларыннан ике әдип бар иде. Алар да чыгышлары белән Бүләковлардан икән.

Минем өчен, Бүләковлардан да бигрәк, бульдозер-трактор һәм КамАЗ машиналарын бирергә тиешле хуҗалар белән күзгә-күз сөйләшү кирәк иде. Молодец Тәлгать, барысын да тиешенчә оештырган.

Бик кыстасалар да, минем белән килгән артистлар авылда кунмадылар, тегермән төзелеп ачылганда тагын килүне вәгъдә итеп, район үзәгенә, кунакханәгә киттеләр. Тагы ялгызым калдым.

Тәлгать авылда кунак йорты вазыйфаларын үтәүче Газизә-Газдә коттеджында кунарга өнди, ә мин энекәшемнең үпкәсеннән шүрлим.

Тәлгать: «Үзем сөйләшеп, гафу үтенермен», – дигәч, Газизәдә кунарга ризалаштым.

«Кунарга» сүзе монда артык булыр. Кояш инде кеше биеклегендә иде. Үзидарәнең «буханка» УАЗигында Газизәгә бик тиз киленсә дә, тиз генә өенә үтеп булмады. Капкасы әллә нинди хикмәтле йозак-келәләр белән бикле булуы өстенә, электр кыңгыравы өзелгәнлектән, шалтырату нәтиҗәсез иде.

Икәүләп калай капканы кага башладык. Озак көттерми, Газизәнең тавышы ишетелде:

– Какма кеше капкасын – үз капкаңны кагарлар...

– Газдә, ачуланмасаң, без килгән идек. Тәлгать абзаң булам.

– Ачулансам, кире китәрсезме?

– Кунак алдында кыен хәлдә калдырасың, ач тизрәк.

– Артист бабай кунак түгел, үзе хуҗа авылдаш ул. Әйдә, керегез, кергәч кунак булырсыз.

– Артист дигәнеңне кабул итсәм дә, бабай дигәнең артык, Газизә. Бабай урынына исемемне әйтә аласың: Әдип Гаязович яисә Әдип абый, – дидем мин, урынлымы-урынсызмы сүзгә катышуымны чамаламыйча.

– Бабай дип без Президентыбызга да әйтәбез. Яратып әйтелгән сүздән баш тарту артистны да, әдипне дә бизәми.

– Әдип минем исемем бит, Газизә.

– Исем җисеменә муафыйк булырга тиеш. Монда чишенмәгез, икенче катка күтәрелегез.

– Мәдрәсә бүлмәсенәмени? – диде Тәлгать.

– Мәдрәсәдә кыш җиткәнче каникуллар. Беренче каттагы буш бүлмәне төрек кешесенә дип әзерләдем.

– Нинди төрек кешесенә? – дидем мин.

– Тәлгать абый әйтсен, мин каршы идем. Хатынлы, бала-чагасы күп кеше, дигәч, ризалаштым.

– Яшь хәзрәт Каһирәдән укуын бетереп кайтуга, йорт өлгертеп тормакчы идек. Яшь булса да башлы булган хәзрәтебез дә Киров өлкәсе мөселманнарының Диния нәзарәтенә мөфти булып киткән. Ул кайтмаса, башкасы килер, дип, йортны төзеп куярга булдык. Акчасын мәчет түли, безнең аша.

– Урыны минеке икәнен белә торып, кем рөхсәте белән төзелә ул йорт?

«

– Бабай дип без Президентыбызга да әйтәбез. Яратып әйтелгән сүздән баш тарту артистны да, әдипне дә бизәми.

– Ничә ел буе җир налогы түләнмәгәч, ул урын хуҗасызлар исемлегендә иде, абзый, аңла.

– Хәзер инде хуҗасы булганнар исемлегенә кертелерме?

– Гариза язарсыз, комиссия хәл итәр. Проблема булмас, ягъни мәчеткә шартнамәдә күрсәтелгән хакны бирәсез дә, вәссәлам, эшең бетте, кодагый.

– Бүләковлар кода-кодагыйлыкны онытмасалар да, кеше хакына кермәделәр. Йорт минеке булырга тиеш. Төзүчеләрне дә мин үзем ялларга тиеш.

– Безнең төрек остасы белән шартнамә төзелгән, аванс бирелгән. Ул бүген-иртәгә килергә тиеш. Күрше районның яңа мәчетенә ай гына куясы калган иде. Куйганнардыр да инде. Сабыр итик. Хәзер төзүче табу җиңел түгел, Әдип Гаязович. Әнә, Газдә әйтсен төзелешнең ни икәнен, күпмегә төшкәнен шушы йортны эшләткәндә ул яхшы аңлады.

– Бурычымны әле һаман түләп бетерә алмыйм. Төрек белән эшләр барып чыкса, бурычларымнан котылырмын дип өметләнәм.

– Нинди эш чыкса?

– Аларда күннән теккән кием-салым, аяк киемнәре бик арзан бәяле, диләр…

– «Агыйделнең аръягында бер алтынга биш бозау», – дигәнгә ышанасың, Газизә. Күпме бурычың бар? – дидем мин, егетлек күрсәтмәкче булып.

– Күпме булса да үземнеке.

– Уртаклыйсың килмимени?

– Бурыч уртак була алмый, бабай, әй-лә, Әдип Гаязович, әтәчләнмә. Әнә, «әтәч»ең кычкыра, җавап бир. Җәүһәрия әби булмасын!

Ул булса шатланыр идем, ләкин телефонда оператор Камил иде. Юлга чыгуларын, кайтып баруларын хәбәр итте. Абруеңа тап төшермәс өчен, район хакимнәренә концертлар өзелүгә сәбәпләрне үзең аңлату кирәк булыр, ди. Исәнлектә күрешик. Хуш.

Телефонымны кесәгә салуга, Тәлгать:

– Җәүһәрия җиңги киләм, дисә, машина җибәрербез, – диде.

– Йорт төзелеп кулга ачкычы кермичә, аның килү ихтималы юк.

– Монда сиңа бирелгән бүлмә Җәүһәрия җиңгине дә сыйдырырлык. Штатка алынып эшли башлагач, хатынсыз булмас, абзый, тартынып торма, әйт хаҗәтләреңне.

– Әйтеп булмый торган хаҗәтләрне кемгә, ничек белдерергә?

– Ашау-эчү мәсьәләләрен чишү безнең өстә кала. Детсад Фирая белән сөйләшербез, аның кухаркасы бик елгыр кыз, иртә-кич ризыксыз калдырмас.

– Әйе шул, детсад боткасын көтеп яттылар, ди! Итен-маен китерсәгез, үзем әзерлим, – диде Газизә.

– Син эштә булганда кем? – диде Тәлгать.

– Минем эшем савап өчен генә бит. Мәчеткә дә, зиратка да аерым сәгатьләрдә генә бару шартын куярмын. Хәзрәтебез каршы булмас.

– Газизә, Тәлгать әйтеп бетермәде, миңа, экология эксперты вазыйфалары белән бергә, Татлысудан һәркөн иртә-кич анализлар өчен пробиркага сулар алып, аларны район үзәгендәге лабораториягә җибәреп барырга тиеш булу эше дә йөкләнә. Бу эштә, әлбәттә, лаборанткасыз, ягъни синсез булмый. Эш хакы күпме каралганын Тәлгать абыең әйтер.

– Медсестраларныкы белән тигез.

– Андый эш хакы алыр өчен авыл хатыннары көрәшмәс, дисезме? Куегыз. Мин көрәштән куркам.

– Көрәшсә дә, алар синең белән түгел, Әдип Гаязович белән көрәшергә тиеш була. Әдип агай безгә таяна.

– Бәхет капкасының шулай кинәт ачылуына ышанасы килсә дә, куркам шул, – диде Газизә, йомшарып.

– Һәр эш куркулы җиңүдән башлана, – дидем мин һәм шуннан башланды да.

Ахыры киләсе санда ■

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

Сеул. Корея. XX гасыр башы

Сеул [Кейҗу]

Кореяның башкаласы – Сеул шәһәре. Тик Сеул дигәнне Кореяның үз халкы аңламый, шулай ук кытайлар да, японнар да (гади халык турында сүз бара) аңламыйлар. Алар бу шәһәрне Кейҗу дип атыйлар. Мин менә шул Кейҗуга аяк бастым.

Әйе, Сеул – пайтәхет. Як-ягы биек ныгытма белән әйләндереп алынган. Моннан тыш, император сарае урнашкан кальга да бар. Шулардан башка «менә бу» дип әйтерлек берни дә юк. Ягъни корея халкының байлыгы, мөлкәте дип атарлык башка нәрсә юк. Өйләр, кибетләр бар да бер катлы. Шулкадәр гади өйләр ки, безнең Русиядә, хәтта авылларда да, болар белән чагыштырганда күпкә төзегрәк йортлар бар. Бу башкала булса да, ике катлы ник бер өй булсын?! Моңа гаҗәпләнмәү мөмкин түгел. Бер катлы өйләр арасында да, һичьюгы бераз бизәлгән, буялган өйләр булса да ярар иде – ул да юк. Бары тик шул бөек кешеләренең өйләре генә, аерып, коймалар белән әйләндереп алынган. Болай эшләү изелгән милләт алдында үзләрен һәйбәт итеп күрсәтер өчен кирәктер инде, мөгаен.

Мин иртәгәсе көнне эчке эшләр министры белән күрештем. Бу кеше белән Япониядә күрешеп танышкан идем, шул вакыт визит карточкасын биргән, Кореяны да килеп күрергә киңәш итеп, үз янына да чакырган иде.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

Министр әфәнде мине үз өендә искиткеч яхшы каршы алып кунак итте. Тик вакыт аз булганга, бер-ике көн калу мөмкин булмады, югыйсә министр җәнаплары үз өендә кунак булып калырга да чакырган иде. Мин, бер утырып чәй эчкәннән соң, китәргә рөхсәт сорадым, риза булмады.

Корея эчке эшләр министрының исеме – Кейлин, бик яхшы кеше. Бераз алдарак аяк киенгән булсалар, мәгърифәткә ирешә аласылар икән, ләкин булдыра алмаганнар, шуңа бик үкенеп, халыкның мескен хәленә бик кайгырып сөйләште. Ләкин ни чара, мәмләкәт инде кулдан ычкынган.

Министр җәнапларының сөйләве буенча, король, ягъни Эй Хинг үзе һавалы кеше икән, мәмләкәт бетте, японнарның кулына күчә бара, фәлән дип уйлап та карамый икән. Хәтта кайчакларда: «Милләт безнең кулыбызда булуга караганда, японнар идарәсендә булсын, тагын да тынычрак, рәхәтрәк булыр үзләренә», – ди икән.

Тик тәхет варисы бик елый, мәмләкәт инде бөтенләй китте дип уйлый икән, хатыннары да елый, ди.

Никадәр генә авыр сорау булса да, сорамыйча кала алмадым:

– Кореяның аерым хокуклы һәм автономияле идарә рәвешендә калуы мөмкин түгелме?

– Идарә дип әйтерлек берни калмады. Бүгенге көндә мәмләкәтнең өчтән ике өлешен японнар таләп итә. Японнар килгән көннән башлап милләт үзен иректә итеп хис итте. Әйе, японнар дошманлык күрсәтәчәкләр, золым кылачаклар. Шуны белә торып, милләт японнарга тартылачак, чөнки японнар яшәү шартларын җиңеләйтте: юллар төзелде, төрле пароходлар бар, аннары шәһәрләр төзекләндерелде, арурандырылды, электр уты белән яктыртылды. Боларның барысын да японнар эшләде. Боларны күргәннән соң, милләт, әлбәттә, аларны безнең идарәбездән өстен тотачак. Без исә, телибезме-теләмибезме, бу хәлне кабул итәчәкбез, инде аңа да күп калмады. Безнең өчен, әлбәттә, кытайларга караганда японнар яхшырак, японнар басып алмаса, барыбер кытайлар басып алачак.

«Шулай булгач, инде кайгырудан файда юк», – дип әйтергә тели, әмма йөрәгенең телем-телем телгәләнүе дә бик ачык сизелә иде. Тик инде ни генә әйтсә дә, файдасыз, чөнки мәмләкәт алар кулында түгел.

Шулай итеп, мин дә, министр җәнапларын борчудан бер файда да булмаячагын аңлаганнан соң, тизрәк китеп бару ягын карадым. Саубуллашыр өчен урыннарыбыздан торып баскач, бичара министр, кулымны кысып, болай диде:

– Безнең мәмләкәтебезгә, ихтимал, Сездән элек тә татарлар килгәндер. Тик мин үз өемдә беренче тапкыр татар кешесенә хөрмәт күрсәтә алуыма бик шат. Безнең Кореяга, белмим, никтер, исламны танытыр өчен килүчеләр булмаган. Тарихыбызда бары тик кайчандыр гарәпләрнең килүе генә билгеле.

– Кайчан, кайсы гасырларда килгәннәр икән?

– Безнең үз ел исәбебез белән билгеле, ләкин мин Сезгә милади исәпкә әйләндереп әйтә алмаячакмын. Шулай да, якынча мең еллар элек икәнен әйтә алам.

– Кемнәр, нинди кешеләр килгән? Болар билгеле микән соң?

– Бик мәгълүм түгел, ихтимал, диннәрен тарату максаты белән килгәннәрдер.

Шуннан соң инде хушлаштык та, мин китеп бардым.

Бичара корея халкы үлгән, тиздән җеназасын укыячаклар. Инде бөтен мәмләкәт идарәсе японнар кулында. Түрәләр арасында корея кешеләре дә бар-барын, ләкин боларның түрәлекләре дә шул бирелгән вазыйфаларын җиренә җиткереп үтәүдән гыйбарәт. Төп эш башында торган бер япон идарәче боларның барысын да эшләтә, күзәтә.

Кореяда мәктәпләр

Японнар Кореяда 1200гә якын башлангыч мәктәп ачканнар. Каядыр бер дистә тирәсе лицей да бар. Корея халкына да японнардагы кебек гомуми белем бирү мәҗбүри булачагы турында сүзләр йөри.

Югары белем алыр өчен, Корея яшьләре, күбесенчә, Япониягә җибәрелә икән. Корея мәктәпләре тулысынча үз милли телләрендә белем бирә, ләкин укытучыларның күпчелеге – япон кешеләре. Авылларда йөргәндә берничә мәктәпкә кердем, карадым, күрдем: укытучы әфәнделәрнең барысы да японнар иде. Әмма Сеул мәктәпләрендәге укытучыларның күпчелеге корея кешеләре икән.

Кореяның кайбер авылларында иске ысул белән укыту да дәвам итә. Балалар барысы да идәнгә җәелгән чыпта яисә салам өстенә утырганнар, парталар да юк, кара такта дигән нәрсә дә юк. Бәлки, алар тыеладыр, белмим. Шул рәвешле иске ысул белән дәрес укыту да бар. Болар – корея кешеләренең үз мәктәпләре. Әмма японнар тарафыннан ачылган мәктәпләре бик төзек, бик алдынгы.

Корея хатын-кызлары

Хатын-кыз арасында башы ачык килеш йөргәннәр дә юк түгел, ләкин күпчелек өстенә баштан каплану өчен кулланыла торган «чапан» кигән булса да, йөзләре барыбер ачык кала. Шактый гына хатын-кыз хиҗап эчендә йөри, бу хиҗап өчен кигән киемнәре исә Бохарада, Төркестанда һәм бездә дә мөселман хатыннары кия торган «чапан» дип аталган киемгә бик охшаш, ир-ат кия торган җөббәгә дә охшап тора. Корея хатын-кызлары ап-ак җәймә кебек нәрсә белән дә уранып йөриләр.

Шул ук вакытта, хатын-кыз ир-ат белән бервакытта да бергә йөрми. Хәтта чәче-башы ачык килеш йөргәннәре дә, япон хатын-кызлары кебек үк, ир-атлардан мөмкин булган кадәр читтәрәк торырга тырыша.

Бу хиҗап турында бер корея рухани кешесе белән арабызда шундый сөйләшү булды. Мин болай дип сорадым:

– Корея хатыннары ник чәч-башларын каплап, уранып йөриләр? Сезнең динегез шулай өйрәтәме? Әллә бу бер милли гадәтме?

– Хатын-кызларыбызның чәч-башын каплап, уранып йөрүе табигый хәл. Моннан йөз еллар элек безнең Кореяда хатын-кызларыбыз барысы да хиҗап эчендә йөргәннәр, тик хәзер азайды.

– Ничек инде табигый хәл? Мин моны бик аңламадым...

– Көчсезләр көчлеләрдән һәрвакыт яшеренергә тиеш, чөнки көчсезләр һәрвакыт золымга дучар була. Кем генә булса да, нинди генә милләттән булса да, ир-ат һәрвакыт залим, аяусыз. Хатын-кыз, әгәр яшеренмәсә, уранмаса, гел аларның золымына, аяусызлыгына мәрәй (мишень) булачак.

– Тәрбия булса, беркем беркемнең хакына кул сузмый.

– Сезнең Аурупа халкы бик тәрбияле. Тик менә Шәрыкка килделәрме, иң беренче эзләнгән нәрсәләре – хатын-кызларыбызга кул салу. Бичара хатын бераз сакланырга теләсә, илчеләренә кадәр ярдәм итүдән тартынып тормый. Бүген инде бөтен милләтебезнең намусын таптадылар. Көчсез калдык, үзебезне үзебез саклый, яклый алмыйбыз, бездә намус та калмады, гыйффәт тә калмады. Шулай, ләкин хиҗап эчендә намус бар, менә шул сәбәпле ябынып-төренеп йөрү бик табигый.

– Кайбер Аурупа кешеләреннән зарланырга мөмкин, әйе. Ләкин бөтен Аурупа халыкларын намуссыз дип атавыгыз бераз артык кебек тоелды. (Әңгәмәдәшем, никтер, ярсып китте.)

– Юк, мин – бу җир кешесе, яшем дә 60ның теге ягында. Бик күп Аурупа кешеләрен күрдем. Дини тәрбия бирү өчен килгәннәре дә бик күп монда. Диннәре буенча үзләренә өйләнү тыелса да, барыбер безнең хатыннарыбызга кул сузалар. Ул син күргән чәче-башы ачык йөрүче хатын-кызларыбыз бар да шундыйлар. Христианлыкны кабул итү белән үк намуссызлыкны сайлыйлар. Дин дигән булып, милләтнең әхлагын бозып бетерделәр.

Бу кешене мин бик ошаттым. Тәрҗемәчем бер япон кешесе иде, шуның ярдәме белән сөйләшәбез. Бераз икеләнеп торганнан соң, Корея мәмләкәтенең һәм милләтенең киләчәге турындагы фикерләрен сорадым. Әңгәмәдәшебезнең исеме Конси Йама икән.

Конси Йама җәнаплары болай дип сөйләп китте:

– Мәмләкәтебез бүген Япония өлкәсе булып бара. Тик алар да эшләрен бераз соңга калып башладылар, милләтебезнең әхлагы инде бозылып беткәннән соң килделәр. Милләтебезнең рухын үтерүчеләр – нигездә, христиан миссионерлары. Бүгенге көндә корея халкында инде миллият-фәлән калмады. Калса да, тормыш мәсьәләсе генә калды. Бүген һәрбер корея кешесе бары тик үз яшәвен генә уйлый ала. Халыкта башка төрле уй-фикернең барлыгын күз алдына да китереп булмый. Инде безнең киләчәгебезне дә болар уйласын. Японнар безне үзләренеке итә алырлармы икән? Әллә Кореяны тагын да ал каннарга буярлармы? Моннан соң инде мәмләкәт киләчәгенең җаваплылыгы боларда.

– Бәлки, үзегезне бераз кулга алырсыз, милли хокукыгызны да беркадәр саклауга ирешерсез. Хаким милләт бервакытта да буйсындырылган халыкның миллиятен саклау белән шөгыльләнми. Һәр милләт, әгәр үзен сакласа, хәтта буйсынган булса да, миллиятен саклый ала. Мин – Русия хөкүмәте идарәсе астында яшәүче бер милләт вәкиле, татар мин. Без инде 400 елга якын буйсындырылган халык булсак та, үз тамырларыбызны саклап киләбез. Киләчәктә хокукларыбызны да кире алырбыз дип өмет итәбез.

Конси Йама бик аптырады, кабатлап: «400 ел?» – дип сорады. Мин дә: «Әйе, 400 ел», – дидем.

Шулай итеп корея халкы турында бераз мәгълүмат алдым. Ләкин ничек кенә булса да, корея милләтеннән өмет итәрлек берни калмаган кебек, үзләре дә инде берни дә өмет итмиләр икән.

Кореяда миссионерлар

Бу һич бетереп булмый торган нәрсәләр кайда гына юк, тик дөньяда боларның иң иректе, иң җанлы эш алып барган җирләре, һичшиксез, Корея мәмләкәте булырга тиеш.

Миссионерлар Кореяда башка илләрдәгегә караганда да күбрәк тырышлык куйганнар, чөнки эшләрен бары акча көченә таянып кына түгел, башкарма көченә һәм мәҗбүриләү көченә дә мөрәҗәгать итү юлы белән алып барганнар. Мәсәлән, бер җинаятьче христианлыкны кабул итсә, болар үз консуллыкларының ярдәме белән эшкә катышып, аны яклау астына алганнар. Шул рәвешле Кореяда христианнарның саны миллионнарга җиткән.

«

Эчкән шәрабының Гайсәнең каны булуына ышаначак, шәраб икәнен белсә дә, хис һәм зиһен көчен ялганлап: «Бу – Гайсәнең каны һәм мин Гайсәнең канын эчәм», – дип, үзен ышандырачак.

Корея халкының ач булуы болай да бар нәрсәне кабул иттергән. Бу соңгы елларда Корея бик күп афәтләр кичергән. Алдарак, 164 нче биттә[1], болар хакында да бераз сөйләп үткән идем.

Корея җире – чагыштырмача бик яхшы, уңдырышлы җир. Японнардагы кебек аз да түгел, һәр квадрат километрга бары тик 45 кеше генә туры килә. Тик соңгы елларда Кореяга бик күп япон кешесе күчеп килгән һәм бу әле дә дәвам итә. Шуңа күрә Корея җире 4-5 ел эчендә килгән япон белән тулачак һәм, нәтиҗәдә, бу кадәр халыкны туендыра алмаячак. Ул көннәр Корея халкы өчен тагын да начаррак һәм куркынычрак булачак.

Табигать таләбедер, мөгаен, кайда гына булса да, әгәр бер мәмләкәттә күчеп килгәннәр артык күбәеп китсә, төп җирле халык үлемгә дучар була, элекке җирле халык күчеп килгән халыкка каршы тора алмый.

Бүгенге статистик күрсәткечләргә карасак, шул аңлашыла: кайда гына булса да шулай – күчеп утырганнарның кысрыклавы сәбәпле, җирлеләр юкка чыккан. Мәсәлән, Мәдинәдә, хиҗрәттән соң, Әнсар бик тиз яшәүдән туктаган. Бүгенге көндә Мәдинә-и Мөнәүвәрәдә бөтенләй диярлек гарәп калмаган, һиҗрәт иле булганга, бар халкы гарәпләшкән милләтләрдән гыйбарәт, тик гарәп үзе юк.

Бүгенге көндә җирле татарлар да тоташ юкка чыгу алдында тора. Табигать кануны аларны юкка чыгарга хөкем иткән.

Төркестанда рус халкы күчерелеп утыртыла башлаган көннән алып җирле халык юкка чыгуга йөз тоткан.

Кайсы җиргә караган статистик мәгълүматлар күздән кичерелсә дә, бу хәлнең табигать кануны булуы ачык күренә. Америкада җирле индеецлар расасы соңгы кешесенә кадәр юкка чыгу алдында тора.

Шулай булгач, Япониядән күп санда халык күчеп килеп урнашса һәм алар бу җирләрдә яши алсалар, һичшиксез, җирле корея халкы бер гасыр эчендә тәмам юкка чыгачак. Инде бүгенге көндә дә үлгән кеше санының туган бала санынннан артыграк булуы турында сөйлиләр. Гомумән, корея халкының исерткеч эчемлек эчүгә хирыс булуы да моңа ярдәм итәчәк. Бүгенге көндә Кореяда исерткеч эчемлек куллану шулкадәр арткан һәм таралган ки, урамнарда исереп егылып яткан кешеләр гел очрый. Монда христианлыкның да шактый «ярдәме» тияр дип уйлыйм. Гомумән, Шәрыкта миссионерларның еш куллана торган кораллары – исерткеч эчемлек.

Хәтта гомерендә бер тапкыр да исерткеч эчемлек эчмәсә дә, христианлыкны кабул итүгә, елга бер генә тапкыр булса да, Хәзрәте Гайсәнең каны дигән булып эчәчәк, дин таләбе буенча эчәргә мәҗбүр калачак. Эчкән шәрабының Гайсәнең каны булуына ышаначак, шәраб икәнен белсә дә, хис һәм зиһен көчен ялганлап: «Бу – Гайсәнең каны һәм мин Гайсәнең канын эчәм», – дип, үзен ышандырачак.

Менә, христиан дин галимнәренең милләтләр әхлагын ничек тәрбия кылулары турында бары тик бу ышануга карап кына фикер йөртсәләр дә, инсаф әһеленең аңлавы өчен бу кадәре дә бик җитәрлек дип уйлыйм.

---

[1] Бу – китапның госманлы-төрек телендә чыккан басмасындагы бит саны (тәрҗ. иск.).

Кореяда борынгы әсәрләр

Кореяда борынгы әсәр дип әлеге дә баягы шул ныгытманы-кальганы күрсәтергә була. Шәһәр төзелеше дигән нәрсә элек-электән үк һич булмагандыр дип уйлыйм. Булса да, аның кытай ысулы төзелеш сәнгате булганлыгы сизелә. Кореяның үзенә хас берәр төзелеш өслүбе яки фән-белем нәтиҗәсе дип әйтерлек башка берәр төрле әсәре дә юк дәрәҗәсендә дип уйлыйм. Мин бик күп йөри алмадым, тик Сеул – үзәк, башкала. Хәер, күзгә ташланырлык берәр нәрсә булса, башкала да булыр иде, әмма биредә дә берни юк.

Кореяның бик борынгы порты булып саналган Кузан[2] портына да бардым. Тик анда да берни күрмәдем. Үтә гади, үтә төссез биналар. Игътибарымны җәлеп иткән бары бер нәрсә бар иде – урамнарның киңлеге. Кореяда, гомумән, авылларның да күбесендә шулай: урамнар бик киң һәм туп-туры, буталышып бетмәгән, билгеле бер дәрәҗәдә тәртип бар.

Биналар исә бөтен Кореяда бертөрле. Башкала булган Сеул биналары да нәкъ Кузандагы кебек. Аермалы буларак, бары шул сарай һәм кальга капкаларын гына күрсәтергә була.

Сарай капкасының ике ягында ике хайван рәсеме бар. Борынгы дип әйтерлек менә шулар гына. Үзләренең әйтүенә караганда, болар бик борынгы әсәрләр.

> **Корея халкының йөзе Урал башкортларына искиткеч дәрәҗәдә охшаган. Тик тел ягыннан бернинди охшашлык, бәйләнеш юк.**

Моннан тыш, шул хайван рәсемнәре астында яткан ташның аскы ягында гарәп язуына охшаган бер язу бар. Кайбер шәрык белгечләре аны – «гарәп язуы», кайберләре исә «монгол язуы» диләр икән.

Мин дә күп тапкырлар бардым, сәгатьләр буе укырга маташтым, бер хәреф тә таный алмадым, хәтта берәр язуга да охшата алмадым. Язу шактый кыршылган, укырга бик мөмкин дә түгел.

Моннан тыш, кальганың берничә капкасы бар. Корылыш ысулы кытай ысулы белән бер.

Йөз-кыяфәтләренә килсәк, корея халкының йөзе Урал башкортларына искиткеч дәрәҗәдә охшаган. Тик тел ягыннан бернинди охшашлык, бәйләнеш юк. Бик күп кулланыла торган нәрсәләрне сорадым, бәйләнеш күрә алмадым. Йөз охшашлыкларына килсәк, бу хакта Ядринцев[3] та Фишер фамилияле бер генеалогия белгеченең сүзләрен китереп үткән.

Король һәм аның ханымының йөзләре дә нәкъ башкорт, төгәлрәк итеп әйтсәм, гайнә башкортлары йөзенә охшаган.

Кем генә күрсә дә, шунда ук «башкорт» дип әйтәчәк: киемнәре һәм бигрәк тә аяк киемнәре нәкъ башкорт чарыгы.

Бичара король бүген Токиога кунакка киткән.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

---

[2] Текстта Кузан дип язылган булса да, мөгаен, Сеулдан 200 км тирәсе ераклыкта урнашкан, бүгенге көндә халыкара сәүдә портына әйләнгән Кунсан шәһәре турында сүз барадыр (тәрҗ. иск.).

[3] Ядринцев Николай Михайлович (1842-1894) – Себерне һәм Үзәк Азияне өйрәнгән, Орхон елгасы үзәнендәге борынгы төрки язулы ташларны һәм борынгы шәһәрләрне ачкан белгеч (тәрҗ. иск.).

Мәңгелеккә юнәлеш

Индус Таһиров

Финляндиядәге татар мәчете

Бүгенге телебезгә, гомумән, үзебезгә карата куркыныч гамәлләр кылына торган көннәрдә татар бердәмлегенең беренче урынга чыгуы зарур. Күп шәһәрләрдә якшәмбе мәктәпләре эшли башлады, туган телгә тартылу артты. Халкыбызга милли рух һәм горурлык хисләре кайтты. Ул үзендә башкаларны таң калдырырдай искиткеч яшәү көче таба алды.

СССРдан читтә яшәгән милләттәшләребез дә татар рухын, татар яшәешен саклап килә. Кытайдамы, Америкадамы, Финляндиядәме – татар кешесе туган теленә, гореф-гадәтләренә тугрылыклы.

Әгәр дә узган гасырның 30-40 нчы елларында Сеул шәһәрендә яшәгән 26 татар гаиләсе, мәктәп ачып, уку китаплары бастырып, мәчет салып, милли тормыш булдыра алган икән, бу юкка гына түгел. Шушы мәктәптә белем алган Сәгыйт Сәлахның АКШка килеп, ике югары белем алуын, докторлык диссертациясе яклап, атом тикшеренүләре өлкәсендәге күренекле галимгә әверелүен, Америка энциклопедияләренә кертелүен дә очраклы хәл дип әйтеп булмый. Чөнки халкыбызның мондый шәхесләре бер ул гына түгел. Аның Надир Дәүләт, Шамил Юлай, Айшә Рорлих, Рифат Таби, Әдиб Акчурин кебек илдән читтә җитлегеп тә, татар рухына, татар яшәешенә тугрылыклы булып калган зур галимнәре бар. Ул, сигез баласын ияртеп, Кытайдан Төркия аша Америкага килгән, шул балаларны үстереп, аларга белем биреп, зур юлга чыгара

Ахыры. Башы журналның 1 нче (2021) санында.

алган, искиткеч зур яшәү көченә ия булган Нәфисә апа Алмакайдай ил аналары биргән. Бу гүзәл апабызның нәселе бүген 46 кешедән тора. Төпле һәм уңдырышлы тамыр ул!

Оркыя апа Сафалы да – шундый ук юлны үткән гүзәл ханым. Ул – үз балаларына гына түгел, башка яшь татарларга да милли оеткы салган изге зат. Оркыя апа – 1954 елны Нью-Йорк татар яшьләрен оештырып, Галиәсгар Камалның «Беренче театр»ын, аннары «Хаҗи әфәнде өйләнә»сен сәхнәгә куйган шәхес. Сан-Франциско шәһәрендә дә милли тормыш гөрләп торган, андагы татарлар да, театр труппалары төзеп, Галиәсгар Камал әсәрләрен сәхнәләштергәннәр. Әгәр дә бүген Америкада Рөстәм Яхин, Салих Сәйдәшев әсәрләре һәм халык җырлары яңгырап тора икән, димәк, милли тормыш дәвам итә.

Финляндиядәге саннары беркайчан да меңнән артмаган татарларның үз милли мәгариф системасын булдыра алулары, милли җыр-моң белән сугарылып яшәүләре, аларның җәмгыятьтә лаеклы урын биләүләре – шулай ук милләтебезнең яшәү көчен раслый торган мисал. Мондый фактларны күпләп китереп булыр иде. Алар барысы да халкыбызның бөеклеген раслыйлар.

Татар уянды һәм горур адымнар белән халыкара мәйданга юл тотты. Ул яшәгән бөтен җирдә, яңгырдан соң калкып чыккан гөмбәләр кебек, төрле исемдәге милли оешмалар барлыкка килде. Казан университеты доценты Марат Мөлеков җитәкчелегендә Татар иҗтимагый үзәгенең тууы үзе генә дә ни тора. Аның татар яшәешен тәэмин итүче күп мәсьәләләр арасындагы төп бурычы Татарстанның статусын күтәрү, аны союздаш республикага әверелдерү булды. Марат Мөлеков, ни кызганыч, инде арабызда юк. Ләкин аның изге эшләре тарихыбыз битләренә ныклап уелып калды.

Шул елларны Фәүзия Бәйрәмова җитәкчелегендәге Милли мәҗлес халкыбызны туплау, аңа көч-куәт һәм дәрт биреп тору гамәлләрен җәелдереп җибәрде.

Шушы дулкында ук Бөтендөнья татар конгрессы барлыкка килде. Бу киң җәмәгатьчелек һәм Татарстан хакимиятенең, республика Президенты Минтимер Шәймиевнең уртак инициативасы иде. Озак та үтмәде, Конгресс, кайнап торган татар дөньясының әзер җирлегенә таянып, үзенең эшен җайга салып эшләп китте. Аның Башкарма комитетына милләтебезнең күренекле шәхесләре сайланды. Рәис урынбасарлары буларак, күренекле шагыйрь, Дәүләт Советы депутаты Разил Вәлиев, «Азатлык» радиостанциясенең Казандагы бүлегенең җитәкчесе, җәмәгать эшлеклесе Римзил Вәлиев, «Сөембикә» журналының баш редакторы, «Ак калфак» татар хатын-кызлар җәмгыятен барлыкка китергән Роза ханым Туфитуллова сайланды. Башкарма комитетка, алардан башка, Татарстан Фәннәр академиясе президенты Мансур Хәсәнов, мәгариф һәм мәдәният министрлары Фарис Харисов һәм Марсель Таишев, Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры Мирфатыйх Зәкиев тә керде. Бу кешеләрнең һәрберсе Конгрессны аякка бастыруга, аның эшчәнлеген җәелдерүгә зур өлеш кертте. Нәтиҗәдә, тиз арада Конгрессның җирле оешмалары барлыкка килде.

Россия татарларының Милли-мәдәни мохтарияты оешты һәм аның җирле оешмалары эшли башлады.

Самарада Шамил Баһаветдинов һәм Равил Хәйруллин тирәсендә дистәләгән татар зыялылары тупланды. Шамил, сәләтле журналист буларак, «Азатлык» радиосы аша татар дөньясындагы яңалыкларны пропагандалауга зур өлеш кертте. Ул бүген дә шушы эшне дәвам итә. Инде мәрхүм Равил абый Ягудин милли мәгариф эшләрен җиренә җиткереп башкара иде. Самарадагы гына түгел, өлкәнең һәрбер авылындагы мәгариф эшләре аның игътибар үзәгендә булды. Шушы милләтпәрвәр ничәмә-ничә

мәктәпне ябылудан коткарып калды. Ул, кирәк булса, теләсә кайсы чиновникка, хәтта губернаторга да кереп, милли мәгарифебезгә караган теләсә нинди мәсьәләне хәл итеп чыга торган иде.

Милли хәрәкәт киң җәелгән үзәкләрнең берсе – Саратов. Монда Зөфәр Хәкимов, Митәсим Сөләйманов, Фрид Рәшитов, мөфти Мөкатдәс Бибарсов һәм дистәләгән милләтпәрвәр шәхесләр бүгенге көнгә кадәр милләтебез өчен зур эшләр башкаралар. Әлбәттә, төп мәсьәлә – туган телне, милли мәгарифне, мәдәният һәм гореф-гадәтләребезне саклау. Аларның эшчәнлеге нәтиҗәсендә, шәһәр уртасында мисали татар гимназиясе барлыкка килде.

Иваново шәһәренең Фәрит Ляпин җитәкчелегендәге милли-мәдәни автономиясе инде күптән милли эшләрне оештыручы төп көчкә әверелде. Монда якшәмбе мәктәбе эшләп килә, Сабан туйларын үткәрү традициягә кереп китте.

Төмән өлкәсендәге Ханты-Манси автономияле округындагы автономияне, ни кызганыч, инде мәрхүм уңган-булган Чистай мишәре Фәнис Рафаил улы Гатауллин җитәкли иде. Мондагы мәһабәт милли автономия бинасының түбәсендә Татарстан байрагы җилферди. Өлкәнең күп шәһәрләрендә әлеге автономиянең бүлекчәләре бар. Берничә мәктәптә, шул исәптән Сургут һәм Нижневартовск шәһәрләрендә татар төркемнәре барлыкка килде. Гомумән, монда милли мәгарифкә һәм мәдәнияткә зур игътибар бирелә.

Омск өлкә автономиясен күп еллар буе тәҗрибәле юрист Хәким Садыйков җитәкләде. Аның белән иңне-иңгә куеп абыйсы, тәҗрибәле педагог Хәлил Садыйков барды. Бу автономия дә, зур авырлыкларны җиңеп, барлык милли оешмаларны берләштерә алды. Өлкә автономиясенең 37 җирле бүлеге бар. Ул татар теле укытучылары белән махсус эш алып бара, татар балаларына телебезне өйрәтүгә, якшәмбе мәктәпләре булдыруга зур игътибар бирә. Өлкәнең үзешчән коллективлары, Омск татарларына гына түгел, хәтта күрше өлкәләргә дә хезмәт күрсәтәләр. Автономия кысаларында, Сания Мирхалиева һәм Рузалия Сайганова татарча радиотапшыру алып бару эшләрен җайга салды.

Мордовия милли-мәдәни автономиясен Шамил Закәр улы Бикмаев оештырды. Ул – күп еллар буе губернатор киңәшчесе һәм республика парламенты депутаты булып торган тәҗрибәле кеше. Шамил әфәнде, булдыклы эшмәкәр буларак, милли эшләргә күп чыгымнар сарыф итте. Аның һәм дәвамчыларының тырышлыгы белән республикада татар телен өйрәнүгә, мәктәпләр эшен җанландыруга, бигрәк тә яшьләр, балалар белән эшләүгә зур игътибар бирелә.

Түбән Новгородта да шуңа охшаш процесслар барлыкка килде. Мондагы «Туган як» җәмгыятенең төп эшләре районнарда, бигрәк тә Краснооктябрьск һәм Сергач районнарында алып барыла. Сергачта «Туган як» газетасы чыгып килә. Монда шулай ук татар китаплары да нәшер ителә. Редакция тирәсенә әдәби көчләр туплана. Татарлар күпчелекне тәшкил иткән Краснооктябрьск районында милли тормыш кайный. Иң зур һәм матур Сабан туйлары да шунда үтә.

Әмма милли эшләрнең идеологик үзәге – Түбән Новгород (Нижгар). Анда милли яшәешкә фәнни төсмер бирү эшен Алимҗан Орлов, Мансур Хафизов, «Туган як» җитәкчесе Марат Юнисов башлап җибәрде.

Мондый милләткә җаннары-тәннәре белән бирелеп эшләгән дистәләрчә шәхесләребезнең исемнәрен булса да әйтеп китү урынлы булыр: Ульяновск өлкәсендә – Азат Курчаков, Әстерханда – Әнвәр Алмаев һәм Наилә Патеева, Төмәндә – Хәнисә Алишина, Ригада – Атанас Асанавичюс, Зөфәр Зәйнуллин, Илдус Сабитов һ.б.

Әгәр дә Ижау шәһәрендә зур колачлы эш җәелдереп җибәргән Мәсгуть абый Гаратуевны искә алмасам, һич кенә дә дөрес булмас иде. Ул – Удмуртиянең атказанган укытучысы, тирән белемле, зирәк акыллы, милләтебезгә тулысы белән бирелгән шәхес. Милли эшләрнең башында торып, ул республикадагы татар мәгарифен җайга салган, үз тирәсенә дистәләгән активист туплап, максатчан һәм нәтиҗәле эшли торган оешма булдыра алган кеше. Ижауда татар газетасы «Яңарыш»ның чыга башлавында да аның роле бик зур. Ул үзе инде бакыйлыкка күчте, ләкин кылган изге гамәлләре дәвамлы, алар яши һәм ныгый.

Узган гасыр ахырында һәм бу гасыр башында туган телебезгә, гореф-гадәтләребезгә кайту, милләтебезне саклап калу, аның бөтенлеген тәэмин итү беренче урында булды. Бу эшкә «Ак калфак» оешмасы, аның башлап җибәрүчесе, инде исеме аталган Роза ханым Туфитуллова зур өлеш кертте. Оешма татар гаиләсе проблемасын бөтен тулылыгы белән колачлый алды. Аның урыннарда кыска гына вакыт эчендә 30дан артык бүлекчәсе барлыкка килде. Алар бүгенге милли яшәешебезгә, телебезгә куркыныч янаган шартларда эшләрен тагын да активлаштырдылар.

Максатларыбызның берсе татарлар яшәгән төбәкләрдәге хакимиятләрне татар проблематикасына якынайту, җирле татар оешмалары белән аңлашуны булдыру иде. Шуңа ирешү өчен, төбәкләрдә Конгресс Башкарма комитетының күчмә утырышларын үткәрү иң уңышлы чараларның берсе булды. Конгрессның беренче ун еллык чорында алар Екатеринбург, Төмән, Омск, Ульяновск, Казакъстанның Шымкент, Кыргызстанның башкаласы Бишкәк шәһәрләрендә, Самара өлкәсенең Камышлы районында бик уңышлы үтте. Күчмә утырышлар җирле хакимият җитәкчеләре һәм киң җәмәгатьчелек катнашында узып, бер яктан, бу ике тарафның үзара якынаюына китерсә, икенче яктан, татар яшәешен бөтен тулылыгы белән күзаллауга юл ачты. Аларда кабул ителгән карарлар татар проблемасын хәл итүгә мөмкинлекләр булдыра килде.

Кайбер мөһим мәсьәләләр Конгресс җитәкчелегенең Петербург, Киев, Минск, Уфа, Әстерхан, Иваново, Нижневартовск, Чиләбе һәм Пермь шәһәрләрендәге очрашу-аңлашулары нәтиҗәсендә хәл ителә торган иде. Бу очрашуларның һәрберсен Конгресс Башкарма комитетының дипломатик эшчәнлеге дип карарга була. Нәкъ менә шуның аркасында әлеге һәм башка чараларның күбесендә җирле хакимият җитәкчеләре, губернаторлар үзләре катнашып килде. Милли эшләребезгә Екатеринбургта – Э.Россель, Саратовта – Д.Аяцков, Омскида – Л.Полежаев, Петербургта В.Яковлев зур кызыксынучанлык күрсәттеләр. Урынбасарларының Конгресс Башкарма комитетының күчмә утырышларында татарлар өчен кылган гамәлләре хакында чыгыш ясаулары, шуннан соң эчтәлекле фикер алышу үткәрү һәм тиешле карарлар кабул итү гадәткә кергән иде.

Шушы күчмә утырышлар кысаларында Татарстан мәгариф һәм мәдәният министрларының җирле коллегалары белән килешүләр төзүе гадәткә әйләнде, җирле хакимият җитәкчеләре белән очрашып, аларны татар проблемаларын хәл итүгә җәлеп итү җайга салынды. Екатеринбургта өлкә губернаторы Россельнең безнең эшләребездә катнашуы үзе генә дә ни тора. Ул – акыллы һәм хәйләкәр немец. Аның белән берничә мәртәбә очрашу безнең Уралдагы вәкиллегебезне ачуга этәргеч бирде, ике яклы килешү төзүгә сәбәпче булды.

Президентыбыз Минтимер Шәймиев, Дәүләт Совет Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин аның белән дуслашып та киттеләр. Мин үзем дә аның белән бик яхшы мөнәсәбәттә булдым. Россель, безнең мөстәкыйльлек идеясенә ияреп, Урал Республикасын игълан иткән иде. Мин аңа тәбрикләү телеграммасы җибәрдем. Бер очрашу вакытында

Э.Россельдән, аны онытмадыгызмы, дип сорадым. Ул: «Юк, һич тә онытмадым, чөнки тәбрикләүләр икәү генә иде, күпләр курыктылар», – диде. Билгеле ки, Россельне шушы гамәле өчен Ельцин урыныннан алган иде. Тик бу кеше альтернатив сайлаулар нәтиҗәсендә янә үз урынына кайтты. Бервакыт мин аңардан: «Ну как Уральская Республика?» – дип сорадым. Ул исә: «Живет Уральская Республика, мы даже Конституцию сохранили, назвав ее Уставом», – диде. Әгәр дә бүгенге көнне Урал белән эшләр җайланган икән, ә бу, чыннан да, шулай, монда Бөтендөнья татар конгрессының роле зур.

Саратов губернаторы Д.Аяцков шулай ук татар мәсьәләләре белән ныклап кызыксына, татарларга ярдәм кулын суза тора иде. Шәһәр уртасындагы гөрләп эшләп торган татар гимназиясе аның ярдәме белән аякка басты. Анда укырга керергә теләүчеләрнең саны артканнан-арта барды. Беренче класска керү өчен конкурста бер урынга алты кеше иде. Саратов татарлары аны, яратып, Дамир Фатыйхович дип кенә йөртәләр иде. Сабан туйларын оештырып җибәрүдә дә аның өлеше зур булды.

Татар конгрессы үзенең беренче ун еллык чорында Берләшкән Милләтләр Оешмасының Мәгълүмати үзәгендә теркәлде. Ул үткәргән чаралар турындагы мәгълүматның шактый өлеше шушы Үзәккә җибәрелүе дә гадәткә керде.

Башкарма комитет Бәйсез Дәүләтләр Парламентара Ассамблеясына да күзәтүче рәвешендә кабул ителде. Аның фән, мәгариф, культура эшләре буенча комиссиясенең эшендә актив катнашты. Боларны гамәлгә ашыруда Татарстанның Санкт-Петербургтагы ул вакыттагы даими вәкиле Шамил Әхмәтшинның өлеше зур булды.

Уйларым мине киләчәккә, дәүләтебезнең аякка басачак чорына илтә. Әйе, басачак, дим. Чөнки аның шулай булачагына җаным-тәнем белән ышанам.

Дөрес, моны гамәлгә ашыру җиңел булмас. Заманалар үзгәрә тора. Бер буын урынына икенчеләре килә. Аларның дөньяга карашларына да үзгәрешләр керә. Тик үзгәрешләрнең барысын да позитив дип әйтеп булмас иде. Бүген инде Ельцин да юк. Горбачев шәүләсе дә күптән күләгәдә югалды. Ил башында – В.Путин. Демократия, суверенитет сүзләре белән уйнау бетте.

Россия Президенты тирәсенә оялаган, татарга каршы хисләр белән янучы Кириенко, Бабич кебекләр аның колагына берсеннән-берсе мәкерлерәк планнарын пышылдый торалар. Югыйсә ул, ил башлыгы буларак, андыйларның үгетләүләренә бирешмәскә тиеш тә бит. Ләкин, нишлисең, бирешә. Теләп, рәхәтләнеп бирешкәнлеге сизелеп тора. Яңа срокка сайлангач, ул Россия Конституциясенә тугрылыклы булачагына ант итте. Тик менә чынында башкачарак. Аның иярченнәре өчен Конституция түгел, аның әмерләре закон.

Россия үзәге белән шартнамәле рәвештә яшәүгә нокта куелды. Аңа кадәр уку стандартларыннан милли кушымтаны алып аттылар, БДИ имтиханын милли телләрдә бирү хокукыннан ваз кичтерделәр. Һәм инде шушы гамәлләрнең соңгысы мәктәпләрдә телебезне укытуның атнага тик ике сәгатькә генә калдырылуы булды. Анысы да әле ихтыяри рәвештә генә!..

Бу – өстән төшкән әмер һәм ул, ни кызганыч, берсүзсез кабул ителде.

Димәк, халыкны, аның телен, гореф-гадәтләрен, ә нигездә исә, үзен руслаштырып юкка чыгарудан саклардай рәсми көч калмады. Бу – факт һәм моның белән санашмау мөмкин түгел.

Нишләргә кирәк? Исән-имин калуыбызның, инкыйразга дучар булмавыбызның нинди мөмкинлекләре бар? Алар, гомумән, бармы икән әле, әллә юкмы? Төп таянычыбыз нәрсә һәм нинди булырга тиеш? Җавап: алар – ата-бабаларыбыз калдырган мирас, динебез, гореф-гадәтләребез. Шуларга таяну беренче урында

булырга тиеш. Тик боларны хәрәкәткә китерергә генә кирәк. Аларның беренчесе – төшенкелеккә бирешмәү, икенчесе – бер җандай булып, бердәмлегебезне ныгыту, бербөтен милләт икәнлегебезне тою хисләрен уяту.

Дөрес, бу улкадәр үк җиңел түгел. Миллилегебезне саклау, аның нигезен ныгыту татар кешесеннән зур тырышлык сорый.

Авыр булуының иң беренче сәбәбе – гасырдан-гасырга күчеп килгән милли яшәешебезнең соңгы елларда саега баруы. Беренче урында – әлбәттә, татар гаиләсенең бүгенге халәте. Аның эчтәлеге бермә-бер саега бара. Һәм моңа күз йомып карарга ярамый.

Шактый күп гаиләләрдә, бигрәк тә шәһәрләрдә рус теле өстенлек итә. Үз телләренә битараф буыннар өлгерә тора. Халкыбызның: «Оясында ни күрсә, очканында шул булыр», – дигән әйтеме акрынлап онытыла бара. Ә бит бала телсез күкедәй булып дөньяга чыкса, шулай телсез рәвештә, милләтенә битараф булып гомер итәчәк. Алай гына да түгел, үзе кебек балалар үстереп, катнаш никахларга юл ачачак. Ә бу исә – руслашуга йөз тоту, милләтеңә хыянәт итү дигән сүз.

Шунлыктан, бүгенге шартларда гаилә проблемасының махсус рәвештә куелуы зарур. Бөтендөнья Татар конгрессы, Милли Шура, Милли-мәдәни мохтарият бу эштән читтә калмасыннар иде. Аларның моның өчен мөмкинлекләре җитәрлек.

Ана телебезне гаиләгә кайтаруда хатын-кызларыбызның роле беренче урында булырга тиеш. Күп җирләрдә «Гаилә» җәмгыятьләре, «Ак калфак»ның җирле оешмалары, милләтебезгә тугрылыклы мәктәп укытучыларыбыз, йөзләгән үзешчән сәнгать коллективлары бар. Аларга рухи көч һәм матди ярдәм биреп тору кирәк. Бу өлешенчә эшләнә дә инде. Ләкин бу гына җитәрлек түгел.

Әйтеп үтелгәнчә, ислам динебез тарихыбызның иң авыр чорларында да халкыбызны юкка чыгудан саклап калды, аңа яшәү көче өсти торды.

Ул бүген дә шундый факторга әверелеп бара. Чаллының «Ак мәчет»енең имам-хатыйбы Шәехвәли хәзрәтнең «Мәдәни җомга»дагы мәкаләсе юкка гына «Динебезгә таянып, телебезне саклыйк!» дип аталмаган. Ул анда Аллаһы Тәгаләнең дин белән телебезнең бергә иңдергән булуын ассызыклый.

Мөфтиебез Камил хәзрәт Сәмигуллин моны бик яхшы аңлап эш итә. Хәзрәт мәчетләрдәге вәгазьләрне бары тик татар телендә генә алып бару таләбен юкка гына куймаган. Бу изге гамәл телебезне, миллилегебезне саклап калуга юнәлтелгән. Казанда узган елдан башлап кыз балалар өчен бары тик татар телендә генә белем биргән «Мозаффария» мәдрәсәсе эшли башлады. Ир балалар өчен дә шундый ук мәдрәсә ачу күз алдында тотыла. Мәчетләр каршында дин һәм татар телен өйрәнү курсларын ачу да планлаштырыла. Укытучылар өчен «Минем халкым, минем динем» исемендәге конкурс игълан ителүе, Казанда татар телен өйрәнү өчен 3 айлык курслар эшли башлавы кебек чаралар артканнан-арта бара.

Ульяновскиның «Нур» мәчете каршында да балалар һәм өлкәннәр өчен аерым татар теле һәм дин өйрәнү курслары эшли. Ижау, Сарытау, Урал һәм кайбер Себер шәһәрләрендә дә шундый ук хәл. Аларның барсын да бер юнәлештәге программалар һәм китаплар белән тәэмин итүне, координаторлык вазыйфаларын һәм кайбер финанс мәсьәләләрен чишүне хөрмәтле мөфти хәзрәтләребез Тәлгать хәзрәт Таҗетдин һәм Равил хәзрәт Гайнетдин үз өсләренә алсалар, милләтебезнең бер җан һәм бер тән рәвешендә яшәвенә юл ачылыр иде.

Татарлар – тарихта ныклап чарланган, теләсә нинди авырлыкларны да җиңәрдәй, үлмәс халык. Шикләнми әйтергә була, аның юнәлеше – мәңгелек. ■

Безнең мирас №2 февраль 2021

Мөхәммәд (с.г.в.) сөннәте һәм татар галимнәре

Раил Фәйзрахманов*

Сөннәт – Мөхәммәднең (с.г.в.) әйткән сүзләре һәм гамәлләре, ягъни хәдисләре. Ул шәригатьтә Коръәннән соң икенче урында тора. Сөннәтнең икенче төрле мәгънәсе – мәҗбүри булмаган, ләкин хупланылган гамәл.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) сөннәте үзенең әһәмиятен халыкларга җиткерелгән көннән алып бүгенгәчә саклап калды. Аллаһы Тәгалә: *«Пәйгамбәр сезгә ни бирсә, шуны алыгыз, ә нәрсә алуны тыя, аны алмагыз»,* – ди (Коръән, 59:7). Әлеге аять, Коръәннең башка аятьләре белән беррәттән, Мөхәммәднең (с.г.в.) бөтен тормышы (карарлары, фикерләре һәм әмерләре) һич шөбһәсез авторитет икәнлегенә аерым бер әһәмият бирә. Сөннәт, мөһимлеге буенча, Изге Коръәннән соң икенче урында торучы ислам кануннары чыганагы булып тора.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) үзенең сәхабәләренә сөннәтне сакларга һәм башка кешеләргә ирештерергә өндәде. Аның: *«Миңа белә торып ялган яккан кеше җәһәннәм утында үз урынын алырга әзерләнсен»,* – дигән сүзләре һәркем өчен кисәтү булып тора.

Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәр сүзләрне анык итеп әйткән, ашыкмыйча, аңлаешлы тел белән сөйләгән. Кайвакыт ул үзенең фикерен өч тапкыр кабатлаган. Гадәттә, пәйгамбәребез (с.г.в.) тыныч тавыш белән сөйләгән, әмма кирәк вакытта, вәгазьләре кеше күңеленә тагын да үтемлерәк булсын өчен, тавышын күтәрә төшкән. Ул: *«Минем сүзләремне ишеткән, хәтерендә калдырган һәм үзләштергән, аннан соң башкаларга җиткергән кешене Аллаһ сөендерсен!»* – дигән. Кайчакта болай дип тә әйтә торган булган: *«Бездән нәрсә дә булса ишеткән һәм ул сүзләрне ишеткән рәвешендә башкаларга җиткергән кешене Аллаһ сөендерсен! Чөнки бу сүзләрне ишетүче аларны җиткерүчегә караганда яхшырак үзләштерергә мөмкин».*

Һиҗрәттән соң беренче гасырда мөселман галимнәре хәдисләрнең фундаменталь җыентыгын туплау белән шөгыльләнмәгән. Күбрәк игътибар Коръәнне өйрәнүгә һәм өйрәтүгә юнәлтелгән. Олылар да, балалар да, ирләр һәм хатын-кызлар да, хакимлек итүчеләр дә, хакимияткә буйсынган кешеләр дә Коръәнне тулаем яки аның күбрәк өлешен яттан өйрәнергә омтылган. Бу максатка ирешелгәч, галимнәр алдына башка бурыч – Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) изге мирасын саклап калу бурычы куела. Сәхабәләрнең һәм аларның шәкертләренең вафаты, шулай ук хәдисләрне бозып күрсәтергә теләүчеләрнең әледән-әле омтылыш ясаулары хәдисләрне кодификацияләү кирәклеген күрсәтә. Бу мәсьәләне хәл итү карары Омейяд хәлифәсе **Гомәр ибн Габделгазиз** (717-720) тарафыннан кабул ителә.

* Раил Рафәгать улы Фәйзрахманов – Мамадыш мәдрәсәсе мөгаллиме, Россия ислам институты студенты.

Ул чорда барлыкка килгән күпчелек җыентыклар бер системага салыналар һәм төрле темаларга багышланган бүлекләрдән торалар. Аларга иман нигезләренә, төрле йолаларны башкаруга, кешеләр арасындагы мөнәсәбәткә кагылышлы, Мөхәммәд (с.г.в.) һәм аңа кадәр килгән пәйгамбәрләрнең тормышы, сәхабәләрнең яхшы сыйфатлары тасвирланган хәдисләр кертелгән. **Имам Мәлик**нең (712-796) «Мувәтта»сы, **Гаде-әр-Раззак ибн Хәммәмә әс-Сәнгәни**нең (744-827) «Мусәннәф»е, **Әбү-Бәкер ибн Әби-Шәйбә**нең (776-849) «Мусәннәф»е ул чорның иң билгеле җыентыкларыннан булганнар. Имам Мәликнең җыентыгы исә – безнең көннәргәчә килеп җиткән иң «яшь» җыентыкларның берсе. Анда Мөхәммәд пәйгамбәргә (с.г.в.) барып тоташкан 1700дән артык хәдис тупланган. **Имам әл-Бохарый** (810-870), **имам әл-Мөслими** (821-875), **әт-Тирмизи**ларның (824-892) хәдис җыентыклары да сөнниләр арасында иң мәшһүрләрдән санала.

***

Ризаэддин Фәхреддин, Галимҗан Баруди, Муса Бигиев, Габденасыйр Курсави кебек татар галимнәре дә сөннәтне тарату эшеннән читтә калмыйлар. Алар үз хезмәтләрендә сөннәтнең әһәмияте хакында язалар, пәйгамбәрнең (с.г.в) хәдисләрен шәрехлиләр, хәдисләр турындагы фәнне мәдрәсәләрдә укыталар.

Зур әһәмияткә ия булуына карамастан, Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в) хәдисләре, ислам тәгълиматы нигезе буларак, Урта Азия укыту үзәкләрендә һәм мәдрәсәләрендә билгеле бер сәбәпләр аркасында бөтенләй диярлек укытылмый. Курсави һәм башка дин белгечләре әлеге фәнне шәкертләргә укыту буенча әледән-әле кыюсыз омтылышлар ясап караганнар, әмма бу дәресләр шәкертләр арасында популярлык казанмаган. Бары тик XIX-XX гасырлар чигендә генә хәдисләр җыентыклары басыла, аларга киң, төпле шәрехләр языла, ә хәдис турындагы фән күпчелек мәдрәсәләрнең укыту планына кертелә башлый.

« Курсави һәм башка дин белгечләре әлеге фәнне шәкертләргә укыту буенча әледән-әле кыюсыз омтылышлар ясап караганнар, әмма бу дәресләр шәкертләр арасында популярлык казанмаган.

Галимҗан Баруди

Хәдисләр турындагы фәнне популярлаштыру буенча күп хезмәт куйган белгечләрнең берсе – мөфти, җәмәгать эшлеклесе, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә нигез салучы һәм «Әд-дин вә әл-әдәб» журналының баш мөхәррире Галимҗан Баруди. Р.Фәхреддин, аның хезмәтләрен бәялəп, болай дип яза: *«Безнең мәгълүматларга караганда, дәүләтебездә хәдисләр турындагы фәнгә хезмәт итүчеләрнең иң өлкәне хөрмәтле Галимҗан Барудидыр. Ул укыту программасына «Җәми әс-сахих» китабын кертте. Чынлыкта, ул һәрдаим*

бу фәнне укыта иде, үзе дә аны башыннан алып ахырынача берничә мәртәбә өйрәнеп чыкты һәм әлеге өлкәдә искиткеч шәкертләр әзерләде». Галимҗан Баруди үзенең «Әд-дин вә әл-әдәб» журналының һәрбер санында Коръән тәфсирен һәм хәдисләрне бастырган, хәдисләргә үзенең шәрехләрен биреп барган.

Әкренләп, хәдис дәресләре мәдрәсәләрнең укыту планына кертелә. Инде 1913 елга хәдисләр турындагы фән Казан мәдрәсәләренең күпчелегендә укытыла башлый. Г.Барудиның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә 1913/14 нче уку елында хәдисләр фәне дәресләре, башлангыч (ибтидаи) бүлекнең өченче сыйныфыннан башланып, атнасына ике сәгать укытыла. Шуннан соң ул урта (сәнәви) бүлекнең беренчедән алып дүртенче сыйныфына кадәр – атнасына бер сәгать, бишенче сыйныфта – ике, ә алтынчы сыйныфта өч сәгать укытыла торган була. Укыту Р.Фәхреддиннең «Әл-Китаб әс-салис», «Җәвәмигъ әл-кәлим», имам Тирмизиның «Китаб шәмәил», имам Мәликнең «Мувәтта» китаплары буенча алып барыла. Атнага бер сәгать хәдисләр турындагы фәннең нигезләрен өйрәнү өчен бирелә. Югары (галия) бүлектә бу фәнгә атнасына биш-алты сәгать вакыт бүленә. Бу бүлектә әл-Бохариның «Сахих»ыннан шәрехләре белән хәдисләр өйрәнелә торган булган.

Ризаэддин Фәхреддин

Хәдис фәнен популярлаштырган дин белгечләренең берсе Р.Фәхреддин була. 1908 елда Оренбург шәһәрендә аның «Җәвәмигъ әл-кәлим» исемле хәдисләр җыентыгы басыла. Әлеге җыентыкка әс-Суйутиның «әл-Җәмигъ әс-сагир фи хәдис әл-бәширән-нәзир» исемле хезмәтеннән сайлап алынган 345 хәдис тупланган. Бу китапны төзүнең максатын ул: *«Шәкертләргә гарәп телен өйрәнүдә һәм аларның әхлакый сыйфатларын камилләштерүдә ярдәм»,* – дип белдерә. Соңрак, 1916 елда галим әлеге җыентыкны хәдисләргә карата үзенең киңәйтелгән шәрехләре белән тулыландыра һәм «Җәвәмигъ әл-кәлим шәрхе» исемле китабын чыгара. Бу китап бүген дә актуальлеген югалтмый, чөнки әлегә кадәр татар дин белгечләре тарафыннан Р.Фәхреддиннең әлеге әсәренә тиңләшә алырдай хезмәт язылмаган. Галимнең «Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр» (1914 ел) исемле мәшһүр әсәрендә дә хәдис фәненә багышланган бүлек бар.

Р.Фәхреддин иҗатында «Көтебе ситтә» китабы аерым урынны алып тора. Башка хезмәтләре кебек үк, галимнең хәдис фәненә багышланган әлеге китабы, беренче чиратта, мәдрәсә шәкертләренә адресланган. Ул үзенең эчтәлеге буенча заманча укыту ярдәмлекләреннән дә өстенрәк. Күтәрелгән мәсьәләләрнең киңлеге, кулланылган күптөрле чыганаклар, аңлатмаларның үзенчәлеге «Көтебе ситтә»нең хәдис фәне өлкәсендәге бәйсез һәм төпле фәнни хезмәт булуын раслый. XX гасыр башына кадәр Идел буе мөселманнарының хәдисләр турындагы фән белән кызыксынулары зәгыйфь булуын исәпкә алсак, әлеге хезмәтнең безнең төбәктә, Казан ханлыгы чорыннан соң, хәдис фәненең гомуми мәсьәләләренә кагылышлы беренче хезмәт булуын расларга тулы нигез бар.

Муса Бигиев

Сөннәтне өйрәнүгә үзеннән зур өлеш керткән күренекле дин белгечләренең берсе булган Муса Бигиевнең дә бу темага берничә саллы хезмәте бар:

1. Ифәдәт әл-кирам шәрх әхәдис булуг әл-мирам [гарәп тел.]. Ибн Хәҗәр әл-Әскаләнинең хәдисләргә багышланган «Булуг әл-Мәрәм мин әдилләт әл-әхкәм» хезмәтенә аңлатма. Хезмәтнең эчтәлегенә болар кергән:

а) ике меңнән артык хокукый хәдис;

б) һәрбер хәдисне үзенең мәгънәсе буенча раслаучы аятьләр;

в) һәр хәдистән чыгарылган хокукый кануннар;

г) галимнәрнең һәр хәдистә булган дини тәгълимат мәсьәләләренә кагылышлы хезмәтләреннән өзекләр;

д) ислам шәригатенә кагылышлы мөселман хокуклары фәлсәфәсе;

е) нәтиҗәләрне дәлилләү методологиясе.

2. «Китәб әс-Сунна» («Сөннәт китабы») [гарәп тел.]. Сөннәтнең үзенчәлекле мәгънәсен бәян итүче бу китап 1945 елда Бхопалда басыла. Ул Һиндстанда барлыкка килгән «Әхл әл-Коръән» сектасына кире кагу буларак язылган һәм ислам динендә сөннәтнең урынын тикшерүгә багышланган.

3. «Әл-Мувәтта» – Имам Мәлик тарафыннан хәдисләр буенча язылган беренче китап – М.Бигиев тарафыннан 1909 елда бастырыла.

***

Һичшиксез, **Шиһабетдин Мәрҗани** кебек дин белгечләре дә үз хезмәтләрендә хәдис фәне мәсьәләләренең аерым бер аспектларына кагылмый кала алмаганнар, әмма бу эшне алар очраклы һәм сирәк рәвештә башкарганнар. Алда искә алынган авторлар танылган китаплардан алынган хәдисләргә шәрехләр язганнар, аны татар халкына, укымышлы муллаларга аңлату, төшендерү белән шөгыльләнгәннәр. Ә Р.Фәхреддиннең «Көтебе ситтә» китабы хәдис фәне буенча иң күренекле хезмәтләренең берсе булып тора.

Файдаланылган әдәбият:

1. Фәхреддин Р. Көтебе ситтә вә мөәллифләре: Гыйльме хәдистән / китапны басмага әзерләүче – А.Гайнетдинов. – Казан: РИИ, 2016.

2. Фәхреддин Р. Җәвәмигъуль кәлим шәрхе / китапны басмага әзерләүчеләр – М.Рәхимкулова һәм Р. Үтәбай-Кәрими. – Казан: «Иман» нәшрияты, 1995.

3. Шагавиев Д.А. Основы исламского источниковедения / – Казань: Изд-во РИИ, 2007.

4. Гилазиев З.З. Хадисоведение. – Казань: ДУМ РТ, 2009.

5. Гермез М. Муса Джаруллах Бигиев. – Казань: ДУМ РТ, 2009. ■

Безнең өчен мәңге изге йорт…

Гүзәл Төхвәтова, Ләйсән Медведева

Казан шәһәрендә сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның (1886-1913) тормышы һәм иҗаты белән бәйле истәлекле урыннар аз түгел. Аларның күбесе берничә гасыр дәвамында Казан татарларының шәһәр мәдәниятен саклаган, аның социаль-икътисади, сәяси һәм мәдәни тормышы кайнаган Иске Татар бистәсе биләмәсендә урнашкан.

Казанның бүгенге Мәскәү урамының чиреген (Галиәсгар Камал урамыннан Татарстан урамына кадәрле араны) алып торган җирдә үз вакытында Печән базары гөрләгән. Ул XVIII гасыр ахыры-1930 нчы еллар башында Иске Татар бистәсенең сәүдә, иҗтимагый һәм мәдәни үзәкләреннән саналган. Аның тирәсендә табыш йортлары, кунакханәләр, сәүдә лавкалары һәм мунчалар урнашкан булган.

Иртә берлән кайнамакта бу базар,
Кайда баксаң, анда тулган сәүдәгәр.

Кайсысы сатмактадыр, кайсы ала,
Берсе алдый, шунда берсе алдана.

(Габдулла Тукай «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш», 1908)

Шуларның берсе – мәгълүм «Болгар» номерлары.

Мәскәү (элеккеге Киров) һәм Евангелистлар (хәзерге Татарстан) урамнары чатында урнашкан «Болгар» кунакханәсе бинасы 1866 елда архитектор Петр Романов проекты буенча эклектика стилендә мануфактура белән сату итүче

беренче гильдия сәүдәгәр Ибраһим Апаков (1821-1885) акчасына табыш йорты буларак 1866 елда салына. Бинаның почмагындагы манара XIX гасыр ахырында төзелә. Казан шәһәренең империя чорындагы гербы – канатлы елан кыяфәтендәге флюгер шул вакытта куела. 1897 елның октябрендә И.Апаковның варисы, кызы Бибимәрьямбану Шамил йортын Оренбургтан Казанга күчеп килгән беренче гильдия сәүдәгәр, иганәче Әхмәт Хөсәеновка (1837-1906) сатып җибәрә. 1907 елда әлеге бинаны Казанның танылган сәүдәгәре, иганәче Мөхәммәтшакир Казаков (1848-1917) сатып ала.

XX гасыр башында бинаның икенче-өченче катларында кунакханә номерлары оештырыла. Беренче катында сәүдә лавкалары һәм төрле оешмалар урнаша. Шагыйрь Габдулла Тукай, журналист, большевик Хөсәен Ямашев (1882-1912), драматург Галиәсгар Камал (1879-1933) һәм татар халкының күп кенә зыялылары исемнәре белән бәйле «Мәгариф» (1901) нәшрияты да шунда эшли.

1906-1916 нчы елларда биредә күренекле педагог, журналист Әхмәтһади Максуди (1868-1941) нәширлегендә һәм мөхәррирлегендә иҗтимагый-сәяси һәм әдәби «Йолдыз» (1906-1918) газетасы нәшер ителә. Милли-демократик «Әл-ислах» (1907-1909) яшьләр газетасы идарәсе 1907 елның ахырыннан 1908 елның маена кадәр «Болгар» кунакханәсенең 12 нче бүлмәсендә урнашкан була. «Азат халык» (1906) иҗтимагый-сәяси, әдәби газетасы, «Ак юл» (1913-1916) – әдәби, «Тәрбия» педагогик журналлары да биредә басыла. Шул ук елларда «Болгар»да иң алдынгы татар зыялыларын берләштергән иҗтимагый «Шәрык клубы» (1907-1917) һәм педагог, журналист Әхмәтһади Максуди (1868-1941) нигез салган беренче милли татар китапханәсе – «Көтепханәи Исламия» (1906) эшли башлый.

2008 елда «Болгар» номерлары сүтелә.

* * *

Үз-үземә урын тапмаганда,
Авырайгач каләм кулларда,
Казан буйлап йөрим-йөрим дә мин,
Тукай торган йортка — «Болгар»га
Килеп чыгам искәрмәстән чаттан,
Вәгъдәләшкән кеше шикелле
Карыйм озак, көтәм... Чат, иске йорт
Минем өчен мәңге сихерле,
Минем өчен мәңге изге бу йорт,
Бүлмәсендә, күрәм, бар уты...

(Сибгат Хәким «Кырыгынчы бүлмә», 1973)

Болгар» номерларында 1907 елның көзеннән 1912 елның декабрь аена кадәр Габдулла Тукай яшәгән. Бу – аның иң озак яшәгән урыны. Кунакханәнең 40 нчы бүлмәсе шагыйрьнең Казандагы тормышын һәм иҗатын чагылдыручы символ булып тора.

Истәлекләрдән күренгәнчә, шагыйрь, 1907 елның көзендә Җаек шәһәреннән Казанга кайткач, әлеге бүлмәгә урнаша һәм, кыска вакытлы күченеп йөрүләрен санамаганда, биредә 1912 елның декабрь аена кадәр яши. Мәсәлән, педагог һәм журналист Вафа Бәхтияров (1881-1960) Габдулла Тукайның «Болгар» кунакханәсенә урнашуын болай сурәтли: *«Менә шул ук елның (1907) октябренең 10ында иртә үк «Әл-ислах» идарәсендә берничә кеше белән сөйләшеп утырганда, ишектән бер кеше килеп керде. Ул өстенә пальто сыман бернәрсә кигән. Бу кеше,*

шул көн генә чыккан «Әл-ислах»ның икенче номерын алып, утыргычка килеп утырды. Берничә минут укып утырды да: «Бу номер газетны мин алып чыгам, мин «Болгар»ның 40 нчы номерында торам. Укыгач та төшерермен, мин Казанда озак торам әле», – дип чыгып китте»[1].

Татарстанның Милли музее фондында *«Тукай яшәгән бүлмә»* тарихи һәйкәле паспорты» дип исемләнгән документ саклана. Аны заманында музей фондларының баш саклаучысы Фәрт Гасыйм улы Гасыймов тутырган булган, документларга музей директоры В.М.Дьяконов кул куйган. Анда бүлмә болай сурәтләнә: *«40 нчы бүлмә кунакханә бинасының көньяк-көнчыгыш өлешендә, төньяк почмактан икенче була. Бүлмәнең зурлыгы – 2х3,28 м, биеклеге – 2,95 м. Агач җиңел ишек, ишектән югары тәрәзә уелган. Тәрәзә пыяласы ватык булганга, такта белән кадакланган. Бүлмә диварлары зәңгәрсу төстәге майлы буяуга буялган, идәне – сары төскә»*[2]. Кабан күленә карап торган бер тәрәзәле әлеге бүлмәдә бер урынлы тимер ятак, бер өстәл, ике урындык һәм шәхси әйберләр тупланган кәрҗин булган. Шагыйрь Җаектан Казанга әлеге кәрҗин белән килгән һәм сәяхәт вакытында һәрвакыт аны алып йөргән. Хәзерге вакытта әлеге кәрҗин Тукай музеенда саклана.

Әдип 40 нчы номерда яшәү чорында үзенең мәшһүр әсәрләрен иҗат итә: *«Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» сатирик поэмасы (1908), «Туган җиремә» (1907), «Бер татар шагыйренең сүзләре» (1907), «Васыятем» (1909) һ.б. шигырьләре, «Исемдә калганнар» автобиографик повесте (1909).* Биредә язылган әсәрләр Габдулла Тукайны хәзерге татар әдәби теленә һәм татар шигърияте нигез салучыларның берсе дип атарга җирлек бирә.

* * *

2015-2016 нчы елларда Татарстан Республикасы Милли музее тарафыннан элеккеге «Болгар» номерлары бинасында, «Татнефть» берләшмәсенең ярдәме белән, Габдулла Тукайга багышланган экспозиция төзелде. Ул халык шагыйре Сибгат Хәкимнең «Кырыгынчы бүлмә» поэмасыннан алынган *«Безнең өчен мәңге изге йорт...»* шигъри юллары белән аталды. Бүгенге көндә Габдулла Тукай әдәби музее карамагында эшли.

Экспозиция бинаның Мәскәү һәм Татарстан урамнары кисешкән почмагында, беренче катта урнашкан. Аның гомуми мәйданы 34,4 $м^2$ алып тора, ә экспозиция 26,9 $м^2$ мәйданны тәшкил итә. Бу – Татарстанда тәүлек буе эшли торган бердәнбер экспозиция-витрина.

«Безнең өчен мәңге изге йорт...» экспозициясендә Габдулла Тукайның Казан чоры тормышы һәм иҗаты яктыртыла. Төп урынны «Болгар» номерларындагы 40 нчы бүлмә һәм «Редакциядә» шартлы интерьер фрагментлары алып тора.

«Болгар» номерларындагы 40 нчы бүлмәнең шартлы интерьерында XX гасыр башы предметлары урын алган: өстәл, урындык, ятак, кара савыты, шәмдәл, кәрҗин һәм китаплар. Биредә Габдулла Тукай үзенең остазлары итеп санаган күренекле урыс язучысы, публицист, философ Лев Толстой (1828-1910) һәм этнограф галим, мәгърифәтче Каюм Насыйри (1825-1902) китаплары күрсәтелгән.

«Редакциядә» шартлы интерьерында 20 нче йөз башы предметларыннан этажерка, урындык, керосин лампасы, кара савыты, шәмдәлләр бирелгән.

[1] Тукай – ядкярләрдә: 2 томда / Төзүчеләр: Р.Ф.Исламов, Җ.С.Миңнуллин. – Казан: Җыен, 2015. – 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. – 375 б.
[2] «Тукай яшәгән бүлмә» тарихи һәйкәле паспорты» // Татарстан Республикасы Милли музее. – НМ РТ КППи-114167.

Этажеркага XIX гасыр ахыры-XX гасыр башында Казанда, Мәскәүдә, Санкт-Петербургта нәшер ителгән Коръән, дини китаплар, дәреслекләр һәм халык арасында киң таралган татар, төрек, казакъ язучыларының әсәрләре куелган. Тукай нәкъ шундый редакциядә үзенең якын дуслары, хезмәттәшләре Вафа Бәхтияров, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Ибраһим Әмирханов, Әхмәтгәрәй Хәсәни һәм башка күренекле язучылар, наширләр, журналистлар белән эшләгән һәм аралашкан.

Экспозициядә шулай ук Габдулла Тукайның сәяхәтләре һәм Казанда шагыйрь белән бәйле урыннарга багышланган ике стенд та урнаштырылган. Анда ул сәяхәт иткән шәһәрләрнең, Казанда шагыйрьгә бәйле истәлекле урыннарның фотосурәтләре һәм алар турында кыскача мәгълүмат бирелгән.

Тамашачы игътибарына тәкъдим ителгән электрон презентацияләр Тукай тормышына һәм иҗатына багышланган музейлар, ул иҗат иткән әкиятләр белән таныштыра. Презентациядә Ф.А.Әминов, Р.М.Хибатуллин, Х.И.Казаков, Р.Л.Эйдинов һәм башка рәссамнарның Милли музей фондларында саклана торган иллюстрацияләре кулланылган.

Халкыбызның сөекле шагыйре Габдулла Тукай хакындагы тулырак мәгълүматны экспозиция янындагы электрон терминалдан да табарга мөмкин. Биредә шагыйрьнең Казан чорына зур игътибар бирелә, элеккеге «Болгар» номерларының тарихына күзәтү ясала, шагыйрь фотосурәтләренә аңлатмалар урнаштырыла.

> «Безнең өчен мәңге изге йорт...» экспозициясендә Габдулла Тукайның Казан чоры тормышы һәм иҗаты яктыртыла. Төп урынны «Болгар» номерларындагы 40 нчы бүлмә һәм «Редакциядә» шартлы интерьер фрагментлары алып тора.

«Безнең өчен мәңге изге йорт...» экспозициясе шагыйрьнең Җаектан Казанга кайтуына 110 ел тулу уңаеннан ачылды. Экспозиция Тукайга багышланган җәяүле экскурсияләр маршрутына кертелде, ул Казанга килгән күпсанлы кунакларга әдип турында мәгълүмат бирәчәк. Бу экспозиция һәркемгә «Болгар» номерларының бөек Габдулла Тукайны һәм, гомумән, бик күп күренекле шәхесләрне сыендырган бина булуын искәртеп торачак.

Кулланылган әдәбият:

1. Тукай – ядкярләрдә: 2 томда / Төзүчеләр: Р.Ф.Исламов, Җ.С.Миңнуллин. – Казан: Җыен, 2015. – 1 т.: Истәлекләр, мәкаләләр, тәгъзияләр, телеграммалар. – 968 б.

2. «Тукай яшәгән бүлмә» тарихи һәйкәле паспорты» // Татарстан Республикасы Милли музее. – НМ РТ КППи-114167.

3. Ядкярләрдә – Тукай рухы: Татарстан Республикасы Милли музее җыелмасында татар халык шагыйре Габдулла Тукайның мемориаль тупланмасы каталогы. Казан: Заман-Татар.кит.нәшр., 2012. – 144 б. ■

Мөһаҗирлектәге татар китабы

Садрый Хәмид (1905-1987) шигырьләре

Хаким (Шигъри роман)[1]

[Тәүге өлеше] (3-4 б.)

Бондан ерак бер авыл,
Тормыш анда бик авыр:
Тирән таулык ташлыкда
Үсәр усал ашлык да.
Өйләр тагын тар, карсак.
Куркырсың, барып баксаң.
Салам, сары балчыкдан
Тышы урамга чыккан.
Диярсең бар да курганлар,
Үсми бер дә урманлар.
Такта, кадакка кытлык,
Үссә үсәр чыбыклык.
Чыбыклар да бик нәзек,
Әйтерсең, бер беләзек.
Булмый түшәп идәнгә,
Яраса ярар читәнгә.
Булсын арыш-борайлар,
Җыела һава бер айлар.
Көзен корырлар өшеп,
Салкын кыраулар төшеп.

* * *

Шунлыкдан юк анда бай,
Шул ук авылда бер бабай
Гомер иткән бөркүдә,
Иске карсак бер үдә.
Кеше анда өй тулы:
Хатыны да дүрт улы.
Кыз баласы артык юк,
Үлә барган яшь чакдук...

[Китапның ахыргы өлеше] (122-124 б.: Хакимнең тәхеткә утыру тантанасы)

...Хаким куелган шатлыкка,
Сайлана бүген шаһлыкка;
Йөзләп туплар атылгач,
Зур капкалар ачылгач,
Тотынды халык туларга,
Бөтен шәһәр уларга.
Якдан багып ис китәр,
Ничек бар да кереп бетәр.
Һич санаусыз кеше,
Әйтерсең, мәхшәр эше...
...Шундый халык булыб да,
Сарай эче тулыб да,
Барсына урын җитте,
Күреб исләре китте.
Шулкадәр өстәл сарайда,
Санаб бетмәс бер айда.
Нигъмәт тулган һәр нидән, –
Кутәрә ничек идән?!
Төрле татлы ашлардан,
Симез итле казлардан,
Тагын хөрмә, инҗирләр
Авызга капкач эриләр.
Түндәкләрдә *(утыргычларда. – **Х.М.**)* бер буйлап,
Гакыл китәрлек уйлап.
Саф көмешдән чашкалар,
Алтындан кашык, башкалар.

[1] Садрый Хәмид. Хаким. – Оулу, 1947. – 124 б. – Гарәп язуында.



«Хаким» китабының тышлыгы

Садрый Хәмид

Хаким тәхеттә

Хакимнең әти-әниләре, туганнары күченә

Япмалар да ефәкдән, –
Көлешә халык эрәтдән...
Йөзләрендә нур уйнап,
Хакимне уйлап-уйлап.
Кем дә күреп шатланыр
Музик йөрәкне ярыр.
Уйный гармун, барабан,
Пиано *(пианино. –* ***Х.М.****)*
ишетелә арадан.
Тагын – шигырь, җырлаулар, –
Сарай эчләре шаулар.
Әйтеп тә түгел бетәрлек,
Ун ел сөйләргә җитәрлек.
Бабай да *(ягъни Хакимнең әтисе. –*
Х.М.*)* шул арада,
Бәйләп карават ягана *(ягына. –* ***Х.М.****)*.
Утырган менеп зур йиргә.
Куйган тәхет менгезеб,
Алтын, мәрҗәнләр тезеб.
Як-яклар да саф энҗе,
Язылган. (Хаким беренче).
Корыб өсте дә япкан,
Яшел хәтфәләр яккан.
Утырды Хаким соң менеб,
Төрле медальләр элеб.
Йөз мең кеше каршында
Кидерделәр таҗын да.
Халык күреб кинәнде,
Селкетделәр идәнне.
Кычкырыб та баш иеб:
«Озак яшәсен!» – диеб.
Шулай хаким булды шаһ,
Йир йөзенә тулды шад.

1947

[«Үткән елның хәбәрләре» китабыннан][2]

(өзек)

(Тәүге өлеше. 102 б.: «Татарларның арасында тырышмаган кеше юк»)

Үткән елгы хәбәрләрдән бераз ният язарга,
Кемне булса шунда хурлап түгел ният азарга.
Кешеләр хурлау бик зур гаеб, беләм аны үзем дә,
Шуның өчен һичкемнәргә тимәс каты сүзем дә.
Күренсә дә бик кыска, булып китәр күп эшләр,
Шулай итеп гомер узар, белми аны күп кешеләр.
Шуны гына белер анлар: ай артындан ай булыр.
Кайсылары ярлыланып, кайсылары бай булыр.
Киләчәкдә кемләр бар: белми аны һич кеше.
Теләгәнгә хут бай итсен – ул Алланың үз эше.
Сүзем тагын озайганчы– хәбәрләргә тотыныйм,
Тиз-тиз генә язып алып, шул китаптан котылыйм.
Тотынган эш бүленеп калса, авыр безнең кебеккә,
Иң курыкканым бит шулардан, калганы бар элек тә.
Үткән сәнә бәндәләргә күрсәтмәде агырлык,
Шуның өчен булды ул ел мактап телгә алырлык.
Булмады орыш, булмады сугыш безгә якын илләрдә.
Үз арада тордылар дуст падишаһ булган җирләр дә.
...Дөнья булгач, һәммәбезгә иң кирәкле ашымыз,
Берничә көн аш капмасак, хараб безнең башымыз.
Төрле-төрле маллар белән тулды киштә-кибетләр,
Тулды тагын йомырка, богдай белән ярма һәм итләр.
Татарларның арасында тырышмаган кеше юк,
Иренеб, ятыб торганларның бу китапта эше юк...

[2] Садрый Хәмид. Үткән елның хәбәрләре. – Оулу, 1950. – 32 б. – Гарәп язуында.

«Ак юл» журналында басылган аерым шигырьләре

Әйтәм Ходайга

Әйтәм Ходайга башым күтәреп: күргәнең мине бармы?
Күргәнең булса, үзең беләсең уйларым нинди барын.
Әйтәм Ходайга башым күтәреп: гөнаһларым, шәт, бардыр:
Йөз кылуны сөйләмим дә, мең кылу да, шәт, бардыр.
Әйтәм Ходайга башым күтәреп: гыйбадәтен дә кылганым бар,
Рамазанда руза тотып, ач та торганым бар.
Әйтәм Ходайга башым күтәреп: ишетәсеңме сүзләремне?
Җомганы да укыганым бар, кыйблага терәп күзләремне.
Әйтәм Ходайга башым күтәреп: еракмы ике арамыз?
Их итмәсдән үлеп китсәм, бер-беребезне күрми калабыз.

Куркак

Җилле төнләр йоклый алмыйм, тәрәзләрне җил кыйный,
Әллә ничек күз йомалмыйм, белсәм дә бит кыйный.
Җил булса да, торам тыңлап курыккан кебек,
Җан алучы фәрештәләр тәрәзәмне суккан кебек.
Бер генә кат түгел анлар, һич туктамый кыйныйлар,
Пыялалар шак-шок итеб уалыб коелмыйлар.
Әйтерсең лә, хәзер, кереб, җанымны тартып алалар,
Тәүбә дә кылып өлгерәлмим, бигрәк якын аралар.
Якын миңа булсалар да, тырышам тәүбә итәргә,
Гафулар сорап бер Ходайдан, гөнаһсыз гына китәргә.
Озак вакыт шулай торгач, уйлый башлыйм,
Фәрештәләрдән куркып торгач, уйны башлыйм.
Димен үземә: куркып торасың бик әзләрдән,
Фәрештәләр йөремиләр бит тәрәзәләрдән.
Алар килсә килми, имеш, тавышсыз,
Шулай итеп йокыга китәмен хәүфсез.

(«Ак юл». – Оулу, 1973. – №50. – 2 б.)

Шигырьләрне басмага филология фәннәре докторы,
*профессор **Хатыйп Миңнегулов** әзерләде.* ■

Безнең мирас №2 февраль 2021

Хәсән Туфан ядкяре



2020 елның декабрь аенда татар халкының олуг шагыйре, гомере, иҗтиһаты үзе бер дастанга торырдай Хәсән Туфанның 120 еллыгы билгеләп үтелде. Таҗ вирус зәхмәте аркасында зур-зур залларда халык тамашасы рәвешендә түгел, ә бәлки, газета-журналларда аның тормышын, гаять әтрафлы иҗатын тагын бер мәртәбә барлау, шуңа мөкиббән төстә баш ию рәвешендә.

Шагыйрь Хәсән Туфан – серле-сихерле бер дөнья. Какшамас рух, сүнмәс-сүрелмәс моң эстәп, ул – халыкка, халык аңа таянды. Таяныр шагыйре булган халык – үзе үк мәшһүр ул. Ә таяныр халкы булмаган шагыйрь беркем түгел.

Хәсән Туфан шигырьләре – әхлагыбыз сафлыгының, каныбыз чисталыгының, киләчәгебез мәңгелегенең үрнәкләре һәм шаһитлары ул. Үз иткәнем, яратканым «Безнең мирас» журналына һәм укучыларына Хәсән абыебызның кәгазьләрем арасында кадерле ядкяр төсендә сакланып тотылган, үз кулы белән язылган истәлекле – үземә атап язылган хатын һәм аның җыентыкларына керми калган, халык шагыйре Наҗар Нәҗмигә багышланган бер шигъри үрнәген тәкъдим итәм.

(Алар нәкъ аныңча: хаты – кызыл каралы, шигыре яшел каралы каләм белән язылган. Шул тикле дә вак-вак хәрефләр белән кәләпүш өстендәге сәйлән бөртекләредәй тезеп-тезеп язылган ки, аларны бик үткер күзлеләр генә укый алырдыр, шөт. Аның үз күзе үтә үткер булган инде ул!)

Форсаттан файдаланып, укучыларыбыз игътибарына Хәсән агабызга атап язган үз шигыремне дә тәкъдим итсәм, бәлки, артык санамассыздыр.

(Чыннан да, көз иде. Мин туган авылыбыз Олы Әшнәктәге төп нигезебез йортының салкын болдырында, безнең Бирге тугаебыздан үз җылы якларына очып китә алмаган тургайны кызганып, япа-ялгызым утырам. Язып янәсе. Кайсы ел икәнен төгәл хәтерләмим. 1978 ел бугай.)

Әхәт Гаффар





Кадерле энебез Әхәт!

Нажарның Казанга килү уңае белән, безнең тугандаш поэзиябез турындагы уйларымны, бүгенгебез һәм бу гасырның ахыргы чирегенә кергәндәге хәлләребезне кайгыртуга юнәлтелгән карашларымны язган-язган идем дә... Ул шундый зураеп киткән ки, аларны бербөтен хәленә китерергә мөмкинлегем юклыгын искә алмаганымны төшендем бүген.

Акка күчерергә керешкән идем... бер генә куллы икәнемне дә искә алмаганмын икән ич!..

Сине озак көттердем. Ләкин, күрәсең, әлегә үти алмадым булып чыкты.

Үзем яраткан бу язма-сызмаларны исәнлегем рәтләнү белән Сиңа алып барырмындыр.

Минем менә шул хәлдә булуымны кичер, бәхиллә инде син, Әхәт.

Имза
28.II.–77.



Хәсән Туфан



Нажар Нәҗми

Хәсән Туфан

Нажарга



Әдәбият

Хәсән Туфан

Нажарга

Тик сәлам бу – бездән Казаннан,
Көчле, дәртле, моңлы жаныңа,
Йолдыз кебек янып яшәүнең
Тукайчысы булуларыңа.

Жаның – ачык, рухың – яланбаш! –
Канасаң да көбә[x] кимисең.
Ораны син – шигырь бәгъренең:
Гамьсезлеккә тынгы бирмисең.

Битарафлык түгел әле дә,
Фидакярне сәламли заман.
Арка куеп түгел давылга,
Күкрәп керү хәерле һаман.

Егылса да – тора да баса,
Турая да чәчкә ата бит,
Лев Толстой агабызны да
Сокландырган чая татарник!

Х.Туфан

х) Көбә – (көбә күлмәк) кольчуга, панцирь.
хх) Татарник – Л.Толстойның «Хаҗимурат» романында чаялык, чыдамлык мисалы итеп алынган үсемлек.

Тик сәлам бу бездән, Казаннан,
Көчле, дәртле, моңлы жаныңа;
Йолдыз кебек янып яшәүнең
Тукайчысы булуларыңа.

Жаның ачык, рухың яланбаш! –
Канасаң да, көбә[1] кимисең.
Ораны син шигырь бәгъренең:
Гамьсезлеккә тынгы бирмисең.

Битарафлык түгел әле дә,
Фидакярне сәламли заман.
Арка куеп түгел давылга,
Күкрәп керү хәерле һаман.

Егылса да, тора да баса,
Турая да чәчкә ата бит
Лев Толстой агабызны да
Сокландырган чая татарник[2]!

[1] Көбә – көбә күлмәк (кольчуга, панцирь).
[2] Татарник – Л.Толстойның «Хаҗиморат» романында чаялык, чыдамлык мисалы итеп алынган үсемлек.

Әхәт Гаффар

Көзге тургай

Хәсән Туфанга

Көзге җиһан – көйсез бала,
Юатыр чара кайда?
Ватык уенчыктай өнсез
Тургай оча һавада.
Канатымы яраланган,
Чуалганмы хәтере?
Югалган баласын эзли
Микән дөнья бетереп?
Кардәшләре күптән инде
Ят җирләр җимен ашый.
Чит икмәккә ил сөюен
Алмашмаган бу гашыйк.
Оча тургай!
Җим эзләми –
Тамагы тук хәсрәткә.
Нинди жырның моңы бар соң
Болындагы сурәттә?
Кем шигырьгә орлык эзли
Түрендә бу тугайның?
Кайткан мәллә сагынып илен
Күңел кошы Тукайның?
«Очты дөнья читлегеннән
Тарсынып күңлем кошы», –
Дип жырламас иде шагыйрь,
Күрсә бу көз балкышын.
Ялкынлы сөю каршында
Көчсез ел фасыллары:
Кышын жырлый тугаенда
Кошларның асыллары.
Көзнең Туфаны бу тургай –
Яшәми тугай ансыз.
Шигырь тугайлары нишләр,
Булса әгәр Туфансыз?
Көзге жиһанда – сүзсез жыр,
Аңлашыла болай да!
Жил актарган китап сыман,
Тургай оча тугайда.

1978 ■

Үткәннән шигырь

Салих Баттал

Тукай һәйкәле янында

(Шигырь бәйрәме көнендә)

Салих Баттал

Мәрхүмнәрне җиңел мактавы –
һәйкәл тирәләрен таптавы.

Һәр тапталган сүзләр – стандарт:
«Буылган ул… Аны кысканнар…»

Тик фәрештә түгел, кеше без –
үз чорыбыз һәм үз эшебез.

Уфтансак та синең турында –
«Эх, ник юк ул Совет чорында…»

Ник юк? – Чөнки яулап бу көнне,
бетергәнсең биреп гомреңне.

– Шигырем! Син яшә, чыда! – дип,
шагыйрь үзе юкка чыга бит.

Ябышалар аңа ютәлләр,
яла ягучылар, бүтәннәр…

«Бүтәннәр»гә кирә аз гына:
Моабитлар, палачлар гына.

Ә шигырьләр һаман ут сибә:
шигырьләрдә – революция.

Димәк, хәзер Совет илендә
шигырең җиңеп чыкты синең дә?!

Ләкин без дә күпне үткәрдек –
һәм үз йөгебезне күтәрдек.

Без беләбез, син дә беләсең
Казанны һәм Плөтән төрмәсен.

Бер әйтем бар ләкин, бер исем –
без беләбез, ә син белмисең.

Син җырлаган идең: «Татар, – дип, –
кемнәр сиңа иман таккан?» – дип.

Сатираңнан синең котылып,
иман әверелде культ булып.

Һичкем аны безгә такмады,
Үзе тагылып йөри башлады.

Ә син үтсәң еллар арасын,
кая илтер иде пар атың? –

Сазың тынар иде кулыңда
көпә-көндез, Совет чорында.

Димәк, дөрес, яхшы иткәнсең –
үз чорыңда яшьнәп үткәнсең.

Синнән үрнәк алып, язларын –
чистартабыз Авгей абзарын.

Синең үрнәк чакыра тартышка –
патша булыр өчен язмышка…

26 апрель, 1972 ел

(Әлеге шигырь язылган кәгазь артында мондый сүзләр бар (Равил Фәйзуллинга адресланган): «Бүләк-китабыңны алдым, рәхмәт. Бу шигырьне үз вакытында укып булмады. Хотя бы син укып чыгарсың. 30 апрель, 1972 ел. Салих Баттал».)

Үткәннән хат

Шагыйрь Равил Фәйзуллинга

«Литературная Россия»да татар теле турында язган шигырең тәрҗемәче тарафыннан канатлары сыдырылган, биртелгән килеш басылуы уңае белән кайгымны белдерәм.

Редколлегия тарафыннан аның шулай биртелүе, әйтелмәве, укучы күңелендә шигырьнең авторы шул килеш тудыргандыр дигән уй туачагы – икеләтә кайгы. Әгәр дә ул тәрҗемәне укып та, аны шул килеш басарга ризалык биреп, «капитуляция» ясаган булсагыз, бу – өчләтә кайгы.

С.Баттал. 25 март, 1972 ел». ■

Безнең мирас №2 февраль 2021

Сыкрау

Роза Туфитуллова

Алгы рәттә (сулдан) – Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев; икенче рәттә (сулдан) – Мөдәррис Әгъләмов, Роза Туфитуллова, Харрас Әюпов (уңнан беренче); өченче рәттә (сулдан) – Рәшит Ягъфәров, Флүс Латыйфи (сулдан икенче)

1964 елның август башы. Без, бер төркем абитуриентлар, тарихтан имтихан тотып йөрибез. Имтихан өчен билгеләр куелган булса да, таралышмаска дигән әмер булганга, кемнеңдер килүен көтәбез. Аннан безне университетның баш бинасына алып китәләр. Кысыла-кысыла кереп, чал колонналар арасыннан аяк төртерлек урын эзлибез. Ул арада:

– Әнә, әнә Хрущев! Әнә… – дигән тавышлар ишетелде.

Ачык машинада баскан килеш кул болгап килүче кеше, чынлап та, Н.С.Хрущев үзе иде. Дәүләт җитәкчесенең Казан университетына тукталуы көтелсә дә, машина выжлап, безнең ур-ра тавышлары астында Ленин урамы буйлап Кремльгә китеп барды.

– Ай күрде, кояш алды, – диде татарча минем арттагыларның берсе.

Ирексездән тавыш килгән якка борылам. Түгәрәк йөзле, янып торган кара күзле, уртача гәүдәле татар егете иде ул.

– Әйдә, безнең белән, – диде ул миңа әллә кайчангы танышына эндәшкән сыман. – Син дә татар бүлегенә тапшырасың бугай бит имтиханнарны?! Генсек белән очрашу хөрмәтенә ашханәгә кереп чыгыйк булмаса.

Мин берсүзсез риза булдым. Егет янәшәсендәге кызлар белән:

– Минем классташларым – Фәнүзә, Әнисә, – дип таныштырды. Ә үзен: – Рәшит, – диде. Аннары ул эчкерсез бер елмаю белән: – Без Бардадан, – дип өстәде.

Ни гаҗәп, университет ашханәсендә безне тагын бер бөек шәхес көткән булып чыкты. Н.Хрущевны сәламләргә чыгучыларның бик күбесе без кергәндә ашханәдә иде инде. Буш урыннар бөтенләй күренми. Подносларыбызны тотып, кыюсыз гына кино төшерүчеләргә дип махсус бүлеп куелган өстәл янына киләбез. Ә анда Володя Ульяновны уйнаучы актер егет император университеты студенты киеменнән борчак ашы ашап утыра. (Нәкъ шул көннәрдә биредә «Мосфильм» Володя Ульяновның студент чагын сурәтләүче «Первая высота» дигән фильмны төшереп ята иде.)

«Тынлыкны Рәшит бозды: – Нигә кирәкме? Сезнең кебекләргә татарлыгыбызны аңлату өчен, – диде ул, үзен көчкә кулга алып.

– Утырыгыз, утырыгыз, – диде ул безгә, дустанә елмаеп.

– Без әле генә Хрущевны күрдек, – дидем мин, каушавыбызны сиздермәскә тырышып.

– Ә монда Ильичның үзе белән бер өстәлдә утырасыз...

Без рәхәтләнеп көлешеп алдык. Яңа танышыбыз кызыксынучан булып чыкты. Казан турында бер-бер артлы сораулар яудырды. Дүртебезнең дә университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укырга җыенуын белгәч, гаҗәпләнүен яшермичә:

– Нәрсә, университетта татарча да укыталармыни?! Монысы нигә кирәк? – диде.

Аның бу соравыннан бер мизгелгә тынсыз калгандай булдык. Тынлыкны Рәшит бозды:

– Нигә кирәкме? Сезнең кебекләргә татарлыгыбызны аңлату өчен, – диде ул, үзен көчкә кулга алып. Актер егет, сөйләшүнең ни белән бетәсен чамалап, тиз генә урыныннан торып, безнең яннан ашыгып китеп барды.

– Нишләвең бу, Рәшит? Кермәс борын университеттан кудырасың бит! Җитмәсә, кайда укырга җыенуыбызны да әйтеп ташладык, – дип, классташ кызлары Рәшитне шелтәләргә тотындылар.

– Курыкмагыз, кызлар, – диде Рәшит, тынычлана төшеп. – Сабагыбызны укытырга теләүчеләр тагын да табылыр әле. Казан татар шәһәре дип тормаслар.

Урал ягыннан килгән егетнең кыюлыгы мине чын-чынлап хәйран иткән иде. Карап торышка юаш кына авыл егете югыйсә! Ул чакта бу егет халкыбызның зур мирасы булган тел байлыгын туплаучы, яклаучы, саклаучы булып китәр дигән уй кемнең башына килсен?! Әлеге көннәрдә бары тик дөньяны кочарга торган егетләр, кызлар гына идек. Баксаң, Рәшит ул чакта, актер егет белән алышып, үзенең беренче биеклеген яулаган булган икән бит.

Әйе, 1964 елның җәе безнең өчен онытылмас вакыт булды. Без данлыклы Казан университетының студентлары булып киттек. Хыялларыбызның җанга сыймый торган чагы. Арабызда берсеннән-берсе сәләтлерәк шагыйрьләр. Рәшитнең дә шигърият белән мавыгуын беләбез. Тик ул, нигәдер, шигырьләрен башка яшь шагыйрьләр кебек сәхнәләргә чыгып укырга ашыкмый. Бәлки, моңа янәшәсендә Рәшит Әхмәтҗанов, Клара Булатова кебек коеп куйган шагыйрьләрнең булуы сәбәпче булгандыр? Бәлки, Рәшиткә үтә дә тыйнаклыгы комачаулагандыр. Кистереп кенә әйтүе кыен. Ә минә өченче курста чакта ул безгә чын-чынлап «яшьнәп-күкрәп» күрсәтте. Татарның бәгърен кузгатучы, чормаларда рәнҗеп-елап

Язучылар Р.Ягъфәров (уңнан икенче), Р.Сәгъди, Л.Лерон, ..., Р.Вәлиева, Ә.Рәшит Барда районы хакимиятендә

яткан гармуннар турындагы бердәнбер шигыре белән Рәшит үзенең зур шагыйрь икәнен игълан итте. Аңа Башкортстанның танылган шагыйре Наҗар Нәҗмидән килгән котлау телеграммасын миңа тапшырырга туры килгән иде. Рәшитнең сабыйларча куанычы әле дә күз алдымда. Соңрак бу шигырь зур сәхнәләрдән, радиодан да яңгырый башлады.

Әлеге хәлләрдән соң озак та үтмәде, сабакташыбызның тагын бер сәләте ачылды. Рәшит Казан театр училищесында Кәшифә Тумашева оештырган режиссерлар әзерләү бүлегендә укый башлады. Берьюлы ике уку йортында белем алу, кичләрен вагон бушатырга йөрүләр җиңел булмагандыр, билгеле. Әмма аның беркайчан да, бернидән дә зарланганы булмады. Рәшит иҗади бер очышта иде. Театр тылсымы, шигърияттәге уңышлары аңа чын-чынлап канатлар куйды.

1966 елның көзендә без Рәшит белән тагын бер сабакташыбыз – Нәрим Ихсановны Вильнюска озатып җибәрдек. Литвада җәлилчеләр хакында «Моабит дәфтәре» дигән фильм төшерә башлаганнар иде. Әлеге фильмның массовкаларында безнең егетләр дә катнашты. Дошман оясыннан үзебезнең якка чыгарга әзерләнеп ятучы татар легионерлары арасында эчкерсез елмаю белән әллә каян балкып торучы Рәшитне экраннарда күргәч, без аңа артист язмышы юраган идек. Әгәр ул үзенә шул юлны сайласа, һичшиксез, халкыбызның сөекле артисты булыр иде. Рәшит башка юлдан китте.

Төгәл утыз елдан соң, узган гасырның 90 нчы елларында, язмышмы, вакытмы, дигәндәй, безне янә бер җиргә җыйды. Ул инде танылган фольклорчы галим, фән кандидаты, шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе. Матур гаилә корган кеше. Уен-көлке һәвәслеге калса да, Рәшиткә инде хәзер яшьлек елларындагыча, шаяртып, Карахмәт, дип эндәшеп булмый. Миндә дә үзгәрешләр байтак: ул чакта татар матбугатында иң популяр басмаларның берсе булган «Азат хатын» журналын җитәклим. Журналны заман рельсларына күчереп, «Сөембикә» атлы итеп үзгәртергә җыенып йөрим. 1992 елның июнь аенда Бөтендөнья татар

Р.Ягъфәров Казандагы 2 нче гимназияне ачу тантанасында чыгыш ясый. 2 сентябрь, 1991 ел

конгрессының I корылтаенда мине Конгресс рәисенең урынбасары итеп сайлап куйдылар. Татарның яңа оешып килгән халыкара оешмасына киң җәмәгатьчелек белән эшләү өчен иҗтимагый хәрәкәттә тәҗрибә туплаган кешеләр кирәк иде. Конгресска баш референт итеп, беренчеләрдән булып Рәшит Ягъфәровны чакырдылар. Тарихка халкыбызның рухи күтәрелеш еллары булып кереп калган ул елларны искә төшерү күңелдә зур горурлык хисләре уята. Ирексездән: «Бар иде заманалар», – дип куясың. Ул елларда Рәшит белән бергә күп юллар узарга, Россиянең күп төбәкләрендә булырга, халкыбызга карата төрле мөнәсәбәтләрне күрергә туры килде. Гадәттә, мондый сәяхәтләрдән без берсеннән-берсе катлаулырак мәсьәләләр, үтенеч-мөрәҗәгать белән кайта торган идек. Ни хикмәт, кая гына барып чыксак та, Рәшитне шул төбәк кешесе итеп кабул итәләр. Татар җанын газаплаучы сорауларны күбрәк аңа яудыралар. Мөгаен, ихлас күңелле, риясыз бу кешенең йөрәгендә нинди сыкрау ятуын сизеп тартылганнардыр аңа. Татарның нык бүлгәләнеп, үз тарихына, үз мирасына битараф булып яшәве Рәшитне чиктән тыш рәнҗетә иде. Соңгы елларда аның рухи яктан шактый таланып калган Татар иҗтимагый үзәген җитәкләргә алынуын башкача ничек аңлатасың?!.

– Татарны мин бердәм халык итеп бары ике тапкыр гына күрдем. Берсе – Сөембикә манарасына ай куйганда. Икенчесе – Хәйдәр Бигичевны мәңгелеккә озатканда, – дигән иде ул бер күрешеп-сөйләшеп утырганда.

Аның бу сүзләре мине бүгенгәчә уйландыра. Ни өчен ике тапкыр гына? Нигә болай диде соң ул? Бертуктаусыз халык ташкыны уртасында кайнады бит югыйсә! Ни кызганыч, инде әңгәмәбезне дәвам иттерү мөмкин түгел. Күңеле яшәүне сөеп туя алмаган, саф йөрәкле бу кешенең үлеме белән бер генә дә килешәсе килми. Әмма йөрәк ничаклы гына өзгәләнсә дә, безгә, исәннәргә, хатирәләрне генә яңарту кала.

Менә без Екатеринбургтан Казаныбызга кайтып барабыз. 1995 елның салкын гыйнвар ае. Әңгер-меңгер төшеп килгән чак. Поезд ниндидер кечерәк бер станциягә килеп туктый. Рәшит тыныч кына сөйләшеп утырган җиреннән сикереп торды да:

– Кызлар, бу минем станция икән бит. Абайламаганмын. Бардага шуннан йөрибез без. Гафу итәрсез, әти-әни ягыннан узып китә алмыйм, – дип, күлмәкчән генә килеш, поезддан сикереп төшеп калды. Без, юлдашым Тәэминә Биктимирова белән, бәрелә-сугыла, аның юл сумкасы белән өс киемнәрен тәрәзәдән көчкә ташларга өлгердек. Сабакташымны искә төшергәндә, нигәдер, шушы Черемушки станциясе күз алдыма килеп баса. Станциянең перронында, елмаеп: «Йә, туганнар, ни хәлләрдә?» – дигәндәй, Рәшит басып торадыр кебек. ■

Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең туууна 115 ел

Горурлык хисе

Эльмира Шәрифуллина. 1964 ел

Муса Җәлил

1932 елда Татарстан Республикасының Минзәлә шәһәрендә, башлангыч класс укытучылары хәзерләү максатыннан, педагогия училищесы ачыла. Бөек Ватан сугышы елларында әлеге бинага Курск өлкәсенең Марьино хәрби-сәяси училищесы килеп урнаша. 1941 елда анда, төгәлрәк итеп әйтсәк, 1941 елның 8 ноябреннән 1942 елның 1 гыйнварына кадәр шагыйрь Муса Җәлил дә укый. Шушы вакыйга нигезендә, педучилищеда 1970 елда герой-шагыйрьгә багышланган музей эшли башлый. Ә 2010 елда училищега (хәзер көллият) Муса Җәлил исеме бирелә.

1962-1966 нчы елларда мин әнә шул тарихи бинада укыдым. Бинасы гына түгел, мөгаллимнәребезнең дә кайберләре Муса Җәлилне күреп белгән, аралашкан кешеләр иде. Мәсәлән, татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мөхәммәт Гарифуллин бу хакта еш кына искә алды.

Эльмира Шәрифуллина

Ул Минзәләне ярата иде

Дәрескә ни өчен вакытында кермәүләренең сәбәбен сорыйм. Аларның берсе:

– Шәһәр почтасында Муса Җәлилне күрдек. Аны күзәтеп йөри торгач, соңга калдык, – диде.

Мин дә, кызыксынып, элемтә бүлегенә юл тоттым. Муса почтага Казан белән сөйләшергә кергән булып чыкты. Кул биреп күрешкәннән соң, аның хәлләрен сораштым, аннан соң шактый озак сөйләшеп утырдык. Ул безнең педучилищега килергә сүз бирде. Озак та үтмәде, шагыйрь белән очрашу кичәсе уздырдык. Без аның белән якын танышлар булып киттек.

Муса Җәлилнең Минзәләдәге вакыты бик эшлекле узды. Ул хәрби-политик училищеда отличнога укый. Шәһәрдәге күп кенә оешмаларда, авылларда халыкара һәм фронт хәлләре турында докладлар ясый, очрашу кичәләре дә уздыра. Хәрби өйрәнүләр вакытында һәм җәмәгать эшләрендә үзен иң актив кеше итеп таныта. Шул ук вакытта Муса әдәби әсәрләр дә яза. Ул иҗат иткән «Бүләк», «Иншәр сеңлемә», «Чыршы җыры», «Суык бабай», «Нәрсә эшләдең?», «Мактанчыкка сабак», «Минзәлә истәлеге» һ.б. шигырьләр Минзәләдә чыга торган «Ленин байрагы» газетасында басылалар.

«

Минзәләдә яшәгән чорда Муса Җәлил барлыгы 35ләп шигырь яза һәм аларны «Каска» дигән исем белән кечкенә җыентыкка әзерли. «Суык бабай» һәм башка шигырьләре балаларга, яшүсмерләргә атап язылган.

Минзәләдә яшәгән чорда Муса Җәлил барлыгы 35ләп шигырь яза һәм аларны «Каска» дигән исем белән кечкенә җыентыкка әзерли. «Суык бабай» һәм башка шигырьләре балаларга, яшүсмерләргә атап язылган. Минзәләдә иҗат ителгән бу шигырьләр ил өстенә килгән дәһшәтле көннәрдә һәркемне изге көрәшкә чакыра.

Муса Җәлил, иксез-чиксез Ватаныбызны бирелеп сөйгән кебек үк, аның бер кисәге булган Минзәләне дә ихлас күңелдән яратты. Бездән киткәндә, шәһәр театрында уздырылган әдәби кичәдә ул:

«Хуш, Минзәлә,
Синдә кунак булдым
Бик аз гына, үтеп барышлый!..» –

дип хушлашты, көрәштә җиңеп кайтып, кабат күрешү хисе белән янды.

Безнең яшьләребез Муса Җәлил шигырьләрен, аның тормышына, иҗатына багышланган әсәрләрне яратып укыйлар. Мусаны сөяләр, хөрмәт итәләр. Минзәлә педучилищесының 4 курс укучысы Эльмира Шәрифуллина «Онытылмассың» шигырендә:

«Якты истәлегең үсә генә,
Училищем белән бәйләнеп.
Онытылмассың, герой-шагыйрь Муса,
Кайтмасаң да үзең әйләнеп...» –

дип яза.

Муса Җәлил Минзәләдә вакытында ялкынлы пропагандист булды.

«Тик бер бурыч хәзер ил алдында:
Тар-мар итү дошман көчләрен;

Илдән куу...
Иптәш, ә син бүген
Фронт өчен нәрсә эшләдең?» –

кебек юлларда, мәсәлән, сугыш вакыты сораулары бик урынлы яңгырый.

Минзәлә театры бинасында соңгы очрашу-саубуллашу кичәсендә ул берничә шигырен укыды да:

«Сау булыгыз, Ватан сугышында
Җиңеп кайтып, исән күрешик», –

дип хушлашты. Гаҗәп җылы, өметле, көрәшләргә дәрт бирүче хушлашу булды бу.

Шагыйрь, фронтка барышлый, Минзәлә райбашкарма комитеты председателе иптәш Мөхәммәтшинга болай дип язды:

«Минзәлә партия-совет җитәкчеләренең һәм Минзәлә халкының бу җанлы, кайгыртучан мөнәсәбәте минем күңелдә онытылмаслык матур эз калдырды. Мин моны данлы Кызыл Армиябезгә, һәм совет язучыларына күрсәтелгән игътибар һәм кадер дип карыйм. Сезнең бу кадер-хөрмәтегезне, фронтта булсын, әдәбиятта булсын, чын эш белән акларга сүз бирәм».

Әйе, шагыйрь Муса Җәлил безгә ул вакытта да кадерле, хөрмәтле иде. Герой-шагыйрь бүген бигрәк тә кадерле. Без шагыйрьнең иҗатын, аның героик хезмәтләрен өйрәнеп кенә калмыйбыз, Ватаныбыз һәм Коммунистлар партиясе алдында кадерле шагыйребез Муса Җәлил кебек булырга сүз бирәбез.

Мөхәммәт Гарифуллин.
«Коммунизм таңы», 1965 ел, 17 декабрь

«1942 ел. Гыйнвар. Каты салкын көннәр. Муса, Минзәләдәге хәрби-политик курсларны тәмамлап, берничә көнгә Казанга – гаиләсе, иптәшләре янына кунакка кайтты. Бераз ябыккан... йөзе дә салкын җилләр белән киселгән, янган...», – дип искә ала язучы Афзал Шамов үзенең «Ике очрашу» дигән хатирәсендә. Димәк, Мөхәммәт Гарифуллин «Муса Җәлилнең Минзәләдәге көннәренең бик эшлекле узуын... Тыгыз программалы хәрби өйрәнүләр вакытында һәм җәмәгать эшләрендә үзен иң актив кеше итеп танытуын» дөрес тотып алган.

Минзәләлеләр Муса Җәлил шәхесенә, аның иҗатына бүген дә бик игътибарлы. Төрле кызыклы чаралар, бәйгеләр, тантаналар үткәреп, видеоязмалар эшләп, матбугатка чыгарып торалар. Герой-шагыйрьгә булган мәхәббәт һәм горурлык хисләрен суытмыйлар.

Училище, техникумнарда укыган еллар ул – ундүрт-унсигез яшьлек үсмернең иң хисле, күңелләрнең иң ихлас һәм садә, күргән-ишеткәнне иң сеңдереп саклый торган вакытыдыр, мөгаен. Шуңа күрә мәгариф өлкәсенең язылмаган ташламасында педагогика училищелары, көллиятләре әзерләгән кадрлар югарырак бәяләнә. Методика, психология, педагогика, музыка кебек фәннәрнең җентекләп укытылуы һәм гамәли эш белән ныгытылып баруы булачак һөнәргә карата мәхәббәт тәрбияли. Балаларны, кешеләрне яратырга, Туган илеңне, шәхесләрне олылый белергә, киләчәк буынны алар үрнәгендә тәрбияләргә өйрәтә. Әйе, училище, тамырларымда аккан горурлана белү хисен минем күңелемә дә мулдан сеңдерде, тирәнәйтте, дип, икеләнмичә әйтә алам. Бу тойгылар, ягъни укытучы күңеленнән укучысы күңеленә күчкән горурлану ялкыны үсмер чак иҗатымда һәм газетада басылган мәкаләмдә яхшы чагыла.



Минзәлә педучилищесы бинасы. 1962 ел, октябрь

Ил онытмас!

Менә данлы датаны эченә алган 15 февраль дә җитте. Бу көн минзәләлеләр өчен бигрәк тә кадерле. Чөнки халкыбызның сөекле улы, Советлар Союзы Герое Муса Җәлил Минзәләдә укыган һәм 1941 елда сугышка да бездән киткән бит!

Шагыйрьнең туган көненә багышлап, аны якыннан белгән, тормышның кайгысын да, шатлыгын да бергә кичергән иптәшләр белән очрашу булды. Укытучыларыбыз Мөхәммәт Гарифуллин, Наилә Чурмантаевалар геройның якын дуслары, киңәшчеләре булганнар. Мәрьям апа Мусаның еш кына китапханәдә булуы, китап укучылар белән кызыксынуы, яшьләр арасында агитация-масса эшләрен җәелдерүе турында сөйли. Муса Җәлил шигырь багышлаган Иншәр Әлкәрәмова шагыйрьне һәрчак шат күңелле, бер генә минутын да бушка уздырмавы, гаять тыйнак, ягымлы булуы белән искә ала. Иншәрнең әнисе Мәхмүзә апа Казанда укыганда Мусаның класстагы була. Шуңа күрә Минзәләдә Муса Җәлил аларга еш килә.

Бу очрашуда шулай ук Муса белән бергә көрәштә булган, аның белән бергә фашистлар тырнагында газапланган элеккеге авыл укытучысы (хәзер уку йорты мөдире), коммунист Фәйзелхак абый Мингалин катнашты. Ул болай хәтерли:

«Муса Җәлилне элек мин күреп белми идем. 1943 елда тоткыннар янына тәбәнәк буйлы, көләч йөзле, яланбаш, костюм өстеннән күлмәк якасын чыгарып салган, культуралы, укымышлы кеше икәне әллә каян күренеп торган бер иптәш килде. Ул үзен Гумеров дип таныштырды. Бу – без күптән көткән Муса Җәлил үзе иде...

Зинданга ябылганнан соң, мин Мусаны тагын ике тапкыр прогулкада күрдем. Беренче күрүемдә хәтта танымый торам, күзләргә ышанасы килми. Ул шундый үзгәргән, бары тик батып калган күзләре генә элекке кебек ягымлы карыйлар иде. Киемнәре тузган, кан таплары белән чуарланган...

– Синең белән нәрсә булды? – дип сорагач, миңа күрсәтеп:

– Ә синең белән? – дип сорады.

Икенче күрүемдә ул миңа тешләре коелып беткән чәч тарагы бирде. Анда ике адрес – Казан һәм Мәскәү адреслары бар иде.

Миңа, ялгышлык белән генә булса да, ирекккә ыргытылу насыйп булды. Безне тоттырган сатлыкҗан яшерен оешмадагы 10 кешенең исемлеген биргән, ә мине

бер иптәш белән (онытыпмы) язмаган. Безне тик шаһитлар формасында гына йөрттеләр. Андагы батырлыклар онытылмый һәм онытылмас!» – дип төгәлли Фәйзелхак абый үзенең сүзен.

Әйе, хаклык өчен, туган Ватаныбыз өчен гомерен дә биргән геройларны ил онытмас!

Э.Шәрифуллина,
Минзәлә педагогия училищесы студенткасы.
«Татарстан яшьләре», 1965

Билгеле, мондый очрашып сөйләшүләр, герой-шагыйрьне күреп белгән тере шаһитлар белән аралашулар, «Кичер, илем!», «Кошчык», «Җырларым», «Ышанма!», «Кыз үлеме», «Кызыл ромашка», «Ана бәйрәме» кебек тетрәндергеч шигырьләрен сәхнәдән сөйләп, тамашачы белән бергә күз яшенә коенулар эзсез югалмый. Без, Мөхәммәт абыйның шәкертләре, аныңча итеп әйтсәк, «әдәбият сөюче гөлкәйләре» кадерле шагыйребезгә бер-бер артлы шигырьләр багышлыйбыз.



Безнең Муса—
безнең Данкобыз

Кара төндә, салкын буранларда
Окопларда туган шигырьләр...
Алар бар да халык батырлыгын,
Муса батырлыгын сөйлиләр.

Кара көчләргә ул
Каны белән
нәфрәт язган изге көрәштә.
Дошман өнендә дә, Данко кебек,
Дәрт кабызган һәрбер йөрәктә.

Үзе калды...
Шигырьләре кайтты
Ватанына—Туган иленә.
Бу шигырьләр әверелде хәзер
Халкыбызның шиңмәс гөленә.

Бәйрәм итә илем Җиңү көнен
Майның матур алсу таңында.
Көрәш үткән Кызыл байракларда
Бар Мусаның изге каны да...

Сагына аны, сагына Минзәләбез,
Ул укыган йорт та сагына...
Киткән кебек әле бүген генә
Мәшһүр Муса давыл ягына.

Горурлыгым көчле—
Тоям аның
Көчле ташкын булып агуын.
Бөек герой эзе калган йортта
Нинди бәхет белем алуы!

Э. ШӘРИФУЛЛИНА,
педучилище укучысы.

Безнең Муса – безнең Данкобыз

Кара төндә, салкын бураннарда
Окопларда туган шигырьләр...
Алар бар да халык батырлыгын,
Муса батырлыгын сөйлиләр.
Кара көчләргә ул каны белән
Нәфрәт язган изге көрәштә.
Дошман өнендә дә, Данко кебек,
Дәрт кабызган һәрбер йөрәктә.
Үзе калды...
Шигырьләре кайтты
Ватанына – Туган иленә,
Бу шигырьләр әверелде хәзер
Халкыбызның шиңмәс гөленә.
Бәйрәм итә илем Җиңү көнен
Майның матур алсу таңында,
Көрәш үткән Кызыл байракларда
Бар Мусаның кайнар каны да.

Сагына аны, сагына Минзәләбез,
Ул укыган йорт та сагына.
Киткән сыман әле бүген генә
Мәшһүр Муса давыл ягына.
Горурлыгым көчле –
тоям аның
Дәртле ташкын булып агуын.
Бөек герой эзе калган йортта
Нинди бәхет белем алуы!

«Коммунизм таңы», 1964

«Малыш» нәшрияты. 1986 ел

Онытылмассың

Герой-шагыйрь Муса Җәлилгә

Хуш, Минзәлә, синдә кунак булдым
Бик аз гына, үтеп барышлый...
Муса Җәлил

Белмим, Муса, кунак булдың микән,
Вакыты бит туры килмәгән.
Сугыш кырларыннан Туган илең
Сине чакырып кулын изәгән.
Алып киткән канлы ут эченә
Курку белмәс батыр йөрәгең.
Дошманнарны илдән себереп түгү,
Изеп ташлау булган теләгең.
Алман илләрендә дуслар тапкан,
Юл күрсәткән үлмәс җырларың.
Минзәләдә кайнар эзең саклый
Биек бина, йөргән юлларың.
Тезгә җиткән урам пычраклары
Кәефеңне, бәлки, бозгандыр.
Бик ихтимал, әле кызлары да
Читтән генә карап узгандыр.

Һай, юк, Муса, үпкәләмә тагы,
Уйнап кына мисал китердем.
«Бер лейтенант күрсә,
акылыннан шашкан
Барышняны»* искә төшердем.
Ә син хәзер кайтып килсәң иде,
Белсәң иде безнең шатлыкны!
Күрсәң иде ничек үзгәргәнен
Үзең укып киткән таш йортның.
Якты истәлегең үсә генә,
Училищем белән бәйләнеп.
Онытылмассың, герой-шагыйрь Муса,
Кайтмасаң да үзең әйләнеп.

***Эльмира Шәрифуллина**,*
«Коммунизм таңы»,
1965 ел, 21 ноябрь ■

---

* Муса Җәлилнең «Минзәлә истәлеге» шигыреннән.

Безнең мирас №2 февраль 2021

Мөгаллим язмалары

Фатих Садыйков

Шәмсебанат һәм Фатих Садыйковлар

Сабыйлык чорым

Мин Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостендагы Югары Курса авылында 1898 елның 14 гыйнварында ярлы семьяда туганмын. Әтием – шул ук Югары Курсаның Вахит малае Садыйк. Әнием Казиле авылыннан Мөхәммәт кызы, анасының исеме – Гөлестан. Аларның торган урыннары Югары Курсаның Нәзир тавы буендагы бер кыекта булган.

Мин 3 яшьтә вакытта әти үлгән. Без, 2 малай һәм 2 кыз, әни тәрбиясендә калганбыз. Әтидән калган бөтен байлык – бер иске йорт һәм бер ат. Әти тегүче булган. Ул ел саен, чуен машинасын кечкенә чанага салып, кышның көнендә Чистай ягына барып, тегү эше белән шөгыльләнгән. Шуннан иген игү өчен ат алып кайта торган булган.

Әти үлгәч, безнең тормыш тагы да начарланды. Әни, муллада һәм башка авыл байларында эшләп, кешегә җеп эрләп, безне туендыра торган иде. Абый 15 яшенә җиткәндә суык тиеп, шешенеп үлде. Бу кайгы Сабан туе көнне булды. Без өй саен күкәй һәм перәннек җыярга чыкканда, аны күмеп кайталар иде.

Өебез җимерелеп төшәрлек булгач, өй хәсрәте килеп туды. Бабайдан калган ул иске өй бик зур иде. Әтидән калган атны әнинең абзасы Әхмәтҗан, йорт салып бирермен, дип алып китте.

Мәдрәсәдән тыш вакытларым

Укудан кайткач, агач аяк белән шуарга чыгып китәм. Ял көннәрендә эт белән куян куарга йөрдем. Минем яраткан дустым эт иде.

Кич белән мин, сукыр лампа яки чыра яндырып, дәрес хәзерли идем. Дини китапларны баштанаяк ятлаталар. Шуларны ятларга бик кыен иде. Язлар җитеп, кояш карый башлагач, култык астыма китап тыгып, аулак урынга барып китап ятлый идем.

Җәй көннәре минем төп эшем балык тоту булды.

Уку-язу әйберләренә акча әзерләү өчен, көтүгә ялланып чыга идем. Ул вакытта бала башына 1 сум «кисү» акчасы җыялар иде. Шуның өчен мин каз бәбкәләре арасыннан бер бәбкәне тәрбияли идем. Шул 1 сумны укытучыларга илтеп бирә идем. Укучы малайлар, бу хәерче малай каян ала соң акча, дип аптырыйлар иде.

Хезмәткә таба бер адым

Курса мәдрәсәсен тәмамлагач, 1912 елны 4 малай Арчага рус училищесына укырга киттек. Училищеда 30лап бала белем алдык. Анда татар балалары өчен аерым класс булды. Укытучы Ибраһим абзый Якупов көнгә 4 сәгать укытты. Рус теле алфавитын өйрәнү, Русия тарихы, география фәннәре керде. Мондагы укучылар бар да аталы, таза тормышлы кеше балалары. Минем ярлы тормыштан килгәнемне белгәч, Ибраһим абзый хөкүмәттән стипендия дәгъвалап алды. Мин ай саен 12 сум стипендия алып укыдым. Шул акча фатирга да, туенырга да, әз-мәз өс-башка да җитә иде.

1913 елда рус классын тәмамлап чыктык. Ибраһим абзый училищеда укуны дәвам иттертергә теләсә дә, авылга кайтып укуны дәвам иттерергә киңәш сорагач, аркылы төштеләр. Балалар укытырсың, диделәр…

Җәйге хезмәтем

1914 елның көзеннән 1915 елның язына кадәр Кырлайда укытып кайткач, җәй көне тик ятарга туры килмәде. Безнең басуда Казан белән Урал арасына чуен юл салынды, шул чуен юлда эшләргә туры килде. Анда вагонга ком тутыру һәм күперләр өчен таш ваткалау шикелле эшләр башкардык. Монда олы ирләр дә, хатын-кызлар да эшләде. Шул хатын-кызлар арасыннан кечерәк кенә буйлы Шәмсебанат исемле бер чибәр кыз, Фатих абый, дип, мине якын күреп йөрде. Ул вакытта аңа – 15 яшь, миңа 17 яшь иде.

Шул елны акча туплаштыргалап кечерәк кенә бер ат алдык һәм сбруй да әмәлләп, иген эшен үз атыбыз белән эшли башладым.

1915 елның көзендә мине Сарай Чокырчага укытучы итеп билгеләделәр. Анда 30-40 бала: 4 класс. Көне буе балалар укытырга туры килде. Жалование бик кечкенә иде. Атна саен балалардан килгән икмәк һәм акча белән яшәргә туры килде. 1916 елның язында, укучыларга имтихан оештырып, укуны тәмамлап кайттым. 1916 елның җәендә дә чуен юлда эшләргә туры килде. Быел тагын ат алып, иген өчен үз атыбыз белән эшләдем.

1916 елның көзендә мине Кешкәк башы мулласы балалар укытырга алып китте. Анда да укулар җиңел булмады. 70-80 баланы берүзем 4 класска аерып укыта башладым. Кешкәк башы авылы бик бай иде. Хезмәт хакы да арурак булды.

Күп еллардан бирле укымый яткан балалар белемне бик тиз үзләштерделәр. 1917 елның язында, бик яхшылап имтихан ясап, балаларга шәһадәтнамәләр биреп тараттык. Имтиханга төрле авылдан муллалар һәм укытучылар килде.

...1918 елның җәендә тынычрак тормыш башланды. Мин шул җәйне йорт өчен кайгырта башладым. Өй бурасы сатып алып яңадан өй эшләттем.

1918 елның көзендә тагын армиягә чакырдылар һәм мине яраклы дип таптылар. Шуннан соң мин Мәгариф халык комиссариатына кереп киңәш сорадым. Алар мине укытучы булып калырга өндәделәр һәм Яңа Кенәргә укытучы итеп билгеләделәр. Мин анда барып эшли башладым. Яңа Кенәр авылы зур, бай авыл иде. Анда иптәш Мамлиев җитәкчелегендә эшли башладык.

1918 елны дин укытмый башладык. Хатын-кыз укытучылар белән ир укытучылар бергә җыелганда, хатын-кызлар битләрен каплап утыралар. Фәкать Камалов Зөфәрнең Мәрхабә исемле хатыны гына ачык йөз белән утыра иде.

1919 елның язында мәктәп бакчасында эшләдек. Шул ук җәйне урмандагы алпавыт утарын сакларга җибәрделәр. Анда Сәлихов Гариф белән җәй буе яттык.

1919 елның җәендә укытучыларга кыска вакытлы курслар ачылды. Без Казанда Сәйдәшев йортында Госман һәм Гомәр Бакировлар белән бергә укыдык. Бу укытучылар өчен беренче курс иде. Курс тәмамлаганнан соң, авылга иген эшенә булышырга кайттым. Ул вакытта ат юк, җәяү йөри идек. Түбән Курса аркылы уракка йөргәндә бергә чуен юлда эшләгән Шәмсебанат исемле кыз: «Фатих абый, безгә кер!» – дип кычкырып кала иде.

1919 елның көзендә Каратай авылына билгеләделәр. Анда сеңлем Сара белән бергә укыттык. Бу Гражданнар сугышы еллары иде. Шуның өстенә, һавада корылык сизелә башлады. Халык бик ярлы. Аклар армиясе Малмыж шәһәренә килеп җиткән, Казанга якынлашалар. Каратай авылында сугыштан качып йөрүчеләр бик күп иде. Шул ук елны тиф авыруы башланды. Иң элек Сара тиф белән авырды. Сараны авылга кайтарып куеп килгәч, үзем тиф белән авырый башладым. Бернәрсә белештермичә авырдым. Яланөс килеш урамнарга чыгып кар ерып йөргәнмен. Тифтан терелгәч, икәүләп кабат укыта башладык.

Ул вакытта ук хезмәт дәресе керә иде, хезмәт дәресендә саламнан эшләпә үрдерә идек.

Уку елы тәмамлангач, авылга (Курсага) кайтып, Арчада ачылган кыска курсларда укыдык. Тормыш бик начар булды. Укытучыларны бер генә мәртәбә ашаталар иде.

1920-21 нче елларны бик каты корылык башланды. Курсаның яртысы ут чыгып янды. Корылык аркасында бертөрле дә ашлык җыеп ала алмадык. Халык имән чикләвеге, салам оны, бака, эт, мәче итләре ашап яшәде. Бик күп кеше кырылды.

«Бу Гражданнар сугышы еллары иде. Шуның өстенә, һавада корылык сизелә башлады. Халык бик ярлы. Аклар армиясе Малмыж шәһәренә килеп җиткән, Казанга якынлашалар. Каратай авылында сугыштан качып йөрүчеләр бик күп иде. Шул ук елны тиф авыруы башланды.

Сулдан уңга: Фатих, Шәмсебанат, Алия, Алсу, Бәнәнә Садыйковалар. (Алия, Алсу – Бәнәнә апаның кызлары)

1920-21 нче елның көзендә мине, Сараны, Сафин Гарифулланы Мәмсә волостеның Сөрде авылына җибәрделәр. Көз көне анда барып эшли башладык, ләкин ачлыктан балаларда мәктәпкә йөрү кайгысы юк. Балаларны Америка тарафыннан бирелгән бодай оны, дөге, какао һәм май белән тәэмин итә идек. Шулай итеп ярты кыш эшләгәч, Сараны икенче мәктәпкә – Үгез елгасы дигән авылга җибәрделәр. Ә Сафин Гарифны чыгардылар. Мин бары үзем генә калдым. Шул вакытта бер хатын: «Кечкенә кызым югалган иде, күршебезгә кереп елап утырганда, бер чүлмәктә балалар бармагы күрдем. Карасам, минем кызымның кулы иде. Шулай итеп минем кызымны суеп ашаганнар», – дип акырып урамда йөри иде.

Үзем генә бераз эшләгәч, авылдан әниләрдән хат килде. Анда: «Ачыктык, салам ашый башладык», – дип язылган. Мин, бер бот ат ите һәм он сатып алып, авылга кайтып киттем. Шулай итеп, гаиләмне үлемнән коткардым.

Сөрдегә барышлый Казанбаш волостена кергән идем, анда Зөфәр Камалов очрап: «Фатих, нишләп йөрисең, әйдә, безгә укытучылар кирәк», – дип, мине Сөрдегә җибәрмәде. Шул ук вакытта мине Корайван авылына куды. Ул авылныкылар бик ач иде. Укырлык хәлле балалар юк. Анда да балаларны столовайда ашатып яттым. Ул вакытта Корайванда Шәмсетдинов Минһаҗ авыл советы председателе иде. Ашлыклар җиткәнче, шунда балаларны туйдырып яттым. Әмма бу ел да ашлык булмады. Бары тары гына булды.

1921 елның көзендә мине Түбән Курсага укытучы итеп куйдылар. Быел да балаларның укымышы әйбәт түгел, бик сирәк йөриләр. Түбән Курса авылында мәктәп бик кечкенә һәм иске иде.

1922 елның язында балаларга столовай ачтык. Монда авыл советы председателе Гыйльметдинов Фәсхетдин иде. Шуның белән Казанбаштан балалар өчен продукция алып кайттык. Аны ул мин белмәгән кешенең келәтенә куйдырды.

Бәнәнә апа ире Гариф белән

Менә шушы йортта пешерергә мөмкин, карап чыгарсың, диде. Карарга кергән идем, анда ике кыз шәл бәйләп утыра. Озын ак күлмәк кигәне минем белән тимер юлда эшләгән Шәмсебанат булып чыкты. Өйләре столовайга яраклы. Мин карап чыгып киткәч, Шәмсебанатның энесе язу чыгарып бирде. Анда ул: «Үзем пешекче булырмын», – дип язган иде. Шулай итеп, столовайга пешекче булды. Укулар тәмамланганчы, балаларны ашау белән тәэмин иттек. Шул ук вакытта Шәмсебанат белән сөйләшеп, гомерлек бергә булырга сүз куештык. Аны 1922 елның язында ат белән төнлә алып мендек. Анда кучер булып Рәдиф Нәзиров төшкән иде. Шулай итеп, Банат гомерлек юлдаш булды.

Тормышка беренче адым

Егетлек һәм кызлык гомерләре узды: беребез – ир, беребез хатын булдык. Хәзер безгә кеше арасында кешеләрчә яшәү, кешеләрчә көн итү генә калды.

1930 елны Югары Симеткә укытучы булдым. Анда да, укыту белән бергә, колхоз оештырдым. Бик азаплык белән колхоз төзедек. 1931 елны Корайван авылына юнәлттеләр. Анда шулай ук балалар укыттым, колхоз оештырдык.

1932 елны Курса тулаем колхоз булды. Мине Курсага җибәрделәр. Гаилә белән шунда күчеп укытырга туры килде. Хатыным балалар бакчасында эшләде.

1933-1940 нчы елларны Түбән Курсада эшләдек. Өйләгә кадәр балаларны укытып, өйләдән соң наданнарны укый-язарга өйрәтеп, кич белән егетләрне һәм кызларны рус алфавитына өйрәтә идем.

1939 елны «Атказанган укытучы» исеме бирделәр. 1940 елны бик каты авырдым. Ул вакытта Бәнәнә кызым Арчада укый иде.

1941 елны сугыш башланды. Ул елны мине Югары Курсага укытырга тәгаен кылдылар. Шул елның көзендә, авыру сәбәпле, 10 көнгә бюллетень бирделәр. Шушы елны Бәнәнәне Дөбьязга укытырга җибәрделәр. Мин бюллетень белән ял итеп ятканда, авыл советы председателе килеп: «10 гына көн булса да колхоз председателе булып эшләп тор», – диде һәм Җамалиев Хаҗи урынына председатель итеп калдырды. 10 көннән соң да миннән колхоз председателен алмадылар. Соңрак Бәнәнәне Дөбьяздан чакыртып алып, ул Курсага укытучы булып тәгаен кылынды. Кызым Сөмбелә белән улым Турис колхозда эшләде.

«24 баш атны, аякта басып тора алмагач, асып куйганнар. Хәтта атларга арыш саламы да юк. Шунда 2-3 көн торганнан соң, басуга чыгып киттем. Очлы тимер таяк белән арыш эскерте эзли башладым. Байтак йөргәннән соң, яртылаш алынган эскерт таптым.

1941-42 нче елларны Аланда колхоз председателе булып эшләдем. 1943-44 нче елларны – Сарай Чокырчада председатель. Сугыш чорында колхозда эшләү бик авыр булды. «Алан» колхозы үзен алып бара алды. Читтән кеше яллатып булса да, эшне эшләтеп бетерә бардык. Хатын-кызлар һәм 10 яшьлек балалар сука сукалап, тырма тырмаладылар. Колхозчылар ачлы-туклы яшәделәр.

Бакчасарай колхозын Шаһниев Габделхактан кабул иткән вакытта анда акылга сыймаслык хәерчелек иде. 24 баш атны, аякта басып тора алмагач, асып куйганнар. Хәтта атларга арыш саламы да юк. Шунда 2-3 көн торганнан соң, басуга чыгып киттем. Очлы тимер таяк белән арыш эскерте эзли башладым. Байтак йөргәннән соң, яртылаш алынган эскерт таптым. Аны казытып, йөри алган атлар белән ташыттым. Коры арыш саламын парлап ашата башладым. Шуннан соң атлар бераз тернәкләнде.

Язгы чәчү җитәрәк, басуга чыгып, калган иске печән кауданнарын карый башладым. Чуен юл буендагы печәнле урыннарга барып җир сөрә башладык. Бераз сөргәч, атка каудан ашатабыз. Шулай итеп, төрле газаплар белән язгы чәчүне тәмамладык. Шул елны язучы Кави Нәҗми килеп, безне мактап, «Татарстан»га язды. 2 ел дәвамында Чокырчаның бурычларын түләп бетердем.

1945 елны армиядән халык кайткач, гариза биреп, председательлекне тапшырдым. Аннан кайтып, «Алан» авылында укытучы булдым. Анда 5 елдан соң укытучылыкны тапшырдым. 1950 елдан 1958 елга кадәр колхозда завсклад булып эшләдем, 1958 елдан соң озак сроклы ялга чыктым.

1976 елның 14 гыйнварыннан үзем 79га чыгам, карчыгым Шәмсебанат 77гә чыга. Ун балабыз туды. Кызганыч, өчесе бала вакытта вафат булды.

Балаларның иң олысы Бәнәнә югары белемле, сигезьеллык мәктәптә укыта. Сөмбелә авылда агитатор һәм авыл хуҗалыгы эше алып бара. Зур малаем Турис колхозның бал кортларын карый. Кече кызым Клара Үзбәкстанда совхозда эшли. Ким исемле улым Үзбәкстанда шофер. Эрнст улым шофер иде, авариядә вафат булды. Кече улым Илгиз шәһәрне газ белән җылыту эшендә эшли.

Үзебезнең хәзер 36 оныгыбыз бар. Оныклар бабай белән әбиләрен онытмыйлар.

*Оныгы **Нурсәнә Садыйкова** язып алды. 1975 ел* ■

Безнең мирас №2 февраль 2021

КАРА ТӘКЪДИР

(Ачы язмышлы шәхесләр)

БИКТАҺИРОВА ХӘРИРӘ

Финансчы. Язучы Гомәр Галинең хатыны.

Ирен зинданга япканнан соң, Хәрирәне дә кулга алалар. Кыз балаларын икесен ике якка – ятимнәр йортына алып китәләр. Озак еллар зинданда газап чиккәннән соң, гарипләнгән Хәрирә ирекка чыга. Шуннан соң ул балаларын эзләп китә, иренең атып үтерелгәнлеге турында ишетә.

БОРЫНДЫКОВ МИКЪДӘТ (1896-1965)

Мөгаллим, сәясәтче. Сарытау губернасының Кузнай өязендәге Домавыл авылында татар гаиләсендә туган.

1930 елда кулга алына һәм биш елдан соң гына иреккә чыгарыла.

1938 елда тагын алып китеп, бу юлы 8 елга утыртып куялар.

Микъдәт Борындыков 1956 елда гына азат ителә. Үзбәкстанда укытучы булып эшли. Сәмаркандта җирләнгән.

БӨДӘЙЛИ МӘХМҮТ (1895-1975)

Татар язучысы, дин галиме. Хәзерге Балык Бистәсе районына кергән Ямаш авылында туган.

Мәхмүт Бөдәйли һич гаепсезгә «халык дошманы» дип игълан ителә һәм, кулга алынып, 26 ел зинданда интегә. 80 яшендә Казанда вафат була.

БОРХАН МАНСУР (1889-1942)

ТатЦИК рәисе. 1921 елның 25 июнендә «Татар телен гамәлгә кертү декреты»на кул куйган шәхес. Сарытау губернасының Хвалын өязендәге Иске Яшел авылында мулла гаиләсендә туган.

Большевиклар тарафыннан «кара исемлек»кә кертелгән кеше. Ул Мәскәү өлкәсенең Ведогуща саласына урман кисү эшләренә сөрелә һәм шунда салкын тидереп вафат була. Каберенең кайдалыгы билгесез.

Дәвамы. Башы журналның 10 нчы (2020) санында.

ВААП БЕКИР (1915-1944)

Кырымтатар шагыйре. Бакчасарай төбәгенең Бөек Каралез авылында туган.

Советлар илен фашист баскынчыларыннан саклаганда, Литваның Гайтурлевка авылы янында батырларча һәлак була. Ә советлар хөкүмәте шушы батыр сугышчының гаиләсен Кырымнан Урта Азиягә – ач үлемгә сөрә.

ВАХИТ КАСЫЙМ (1916-1942)

Татар шагыйре. Физика-математика укытучысы. Башкортстанның Әлшәй төбәгендәге Нигъмәтулла авылында урта хәлле крәстиян гаиләсендә туган.

Институт тәмамлауга, Ватан сугышы башлана, Касыйм үзе теләп сугышка китә, алгы сызыкта хезмәт итә. Сталинград өчен барган канкойгыч сугышларда катнаша һәм батырларча һәлак була. Шелемка исемле авыл янындагы туганнар каберлегенә җирләнә.

ВАХИТОВ МУЛЛАНУР (1885-1918)

Революционер, иҗтимагыйсәяси эшлекле. Казанда сәүдәгәр гаиләсендә туган.

Казан каласын ак чехлардан саклау эшләрен оештыручы.

Мулланур Вахитов ак чехлар тарафыннан кулга алына һәм атып үтерелә. Каберенең кайдалыгы билгесез.

ВӘЛИДИ ҖАМАЛ (1887-1932)

Тел галиме. Казан губернасының Тәтеш өязендәге Апас авылында мулла гаиләсендә туган.

Аны гаепсезгә төрмәгә утырталар, бик каты җәзалыйлар, сорау алудан кайтканда ул, сакчылар кулыннан ычкынып, өченче каттан аска томырыла. Бәлки, аны сакчылар үзләре төртеп төшергәндер?.. Икенче көнне ул төрмә хастаханәсендә җан бирә. Туганнары аның гәүдәсен төрмәдән алып чыгып җирләргә тели, ләкин моңа рөхсәт бирмиләр. Вәлидинең җәсәден медицина институтында укучы шәкертләргә ярып өйрәнү өчен тапшыралар.

ВӘДҮТ МИФТАХ (1915-1942)

Татар шагыйре. Татарстанның Сарман төбәгендәге Яхшы Каран авылында ярлы игенче гаиләсендә туган.

Ул Тула шәһәре өчен барган каты сугышта һәлак була. Тула өлкәсенең Рыдань авылы янындагы туганнар каберлегенә җирләнгән.

*Текстны басмага **Рабит Батулла** әзерләде.* ■

Безнең мирас №2 февраль 2021

Истә, һаман да истә!

Шагыйрь Мөхәррәм Каюмовның туууына 80 ел



Шагыйрь, 1997 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Мөхәррәм Әхмәтнур улы Каюмов 1941 елның 3 февралендә Башкортстанның Борай районындагы Бустанай авылында туган.

М.Каюмов, урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Бөре педагогия институтында белем ала. Казанга килеп, газета-журнал редакцияләрендә төрле вазыйфалар башкара.

Төп басма китабы – «Торналар чылбыры» (1998, кереш сүз авторы – Г.Садә). Шагыйрь һәм аның иҗаты турында Р.Гаташ, Г.Гыйльманов һәм Ә.Мәхмүдов мәкаләләре дөнья күрде.

М.Каюмов 2003 елның 14 декабрендә вафат булды.

Галим Рәшит Ягъфәровның тууына 75 ел

Фольклорчы галим һәм шагыйрь, 1996 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Рәшит Фәйзерахман улы Ягъфәров 1946 елның 6 февралендә Пермь өлкәсенең Барда районындагы Күчтәнтибаш авылында туган.

1962-1963 нче елларда ул Пермь өлкәсенең Усы педагогия училищесында белем ала. Беренче шигырьләре Барда район газетасы «Таң»да басыла.

Р.Ягъфәров 1973 елда гаиләсе белән Казанга күченә.

Төп басма китаплары: «Шигърият чишмәләре» (балалар фольклоры, 1985), «Тол буйлары, тугайлары» (1993), «Тулпарларым» (1996), «Генерал әтәч» (2002), «Моңнар туа күңелдә» (2002), «Тулпар моңы» (2006).

Р.Ягъфәров 2008 елның 26 августында вафат булды. Мәрхүмнең җәсәде туган авылы зиратында җирләнде.

Җырчы Вафирә Гыйззәтуллинаның тууына 75 ел

Җырчы, Татарстанның халык артисты (1981), Каракалпакстанның халык һәм РСФСРның атказанган артисты (1988) Вафирә Мөхәммәтдин кызы Гыйззәтуллина 1946 елның 13 февралендә ТАССРның Менделеевск районындагы Камай авылында туган.

1965 елда ул – Казан музыка училищесын, 1974 елда исә Казан дәүләт консерваториясен тәмамлый.

1974-1975 нче елларда – М.Җәлил исемендәге опера һәм балет академия театрында, 1975-1994 нче елларда Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшли. Ул башкарган кайбер җырлар: «Туй җыры» (С.Сөләйманова сүзләре, Ш.Кашапов көе), «Кыр казлары киткәндә» (Р.Гәрәй, Ә.Бакиров), «Юатма» (Р.Харис, Р.Әхиярова), «Аккошлар» (Р.Фәйзуллин, Ф.Әхмәтов) һ.б.

В.Гыйззәтуллина 2001 елның 17 сентябрендә юл һәлакәтендә вафат булды.

Безнен мирас №2 февраль 2021

Тел галиме
Гыймад Нугайбәкнең
тууына 140 ел



Тел галиме һәм журналист Гыймадетдин Шәрифҗан улы Нугайбәк 1881 елның 13 февралендә Сарытау губернасының Кузнәй өязендәге Черкели авылында туган.

1893 елда ул Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә, анда Галимҗан Барудиның яраткан шәкерте була. «Мөхәммәдия»не тәмамлагач, Г.Нугайбәк шунда ук укытучы булып кала, бер үк вакытта әдәби тел, алфавит һәм дөрес язу мәсьәләләре буенча гыйльми-тикшеренү эшләре дә алып бара.

1910 елда ул – «Башлангыч», 1911 елда – «Төрлек», 1912 елда «Сагынмалык» исемнәре белән татар телен фәнни юнәлештә ничек тикшерергә һәм өйрәтергә дигән фикерләрен бәян иткән хезмәтләрен яза.

1912 елдан – «Кояш», 1917 елдан «Эшче» газеталары редакцияләрендә эшли.

Г.Нугайбәк 1943 елның 8 февралендә вафат булды.

Режиссер
Эдмас Үтәгәновның
тууына 90 ел



Режиссер, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1992) Эдмас (Идмас – «искусство для масс» сүзләреннән ясалган исем) Хәмит улы Үтәгәнов 1931 елда туган.

Э.Үтәгәновның башта – артист, аннары режиссер булып китүендә туганы – РСФСРның атказанган артисты Камал Сәлахетдиновның (Камал III) роле зур була.

1960-1991 нче елларда ул – Казан телевидениесе, 1979-1991 нче елларда – Казан кинохроника студияләре режиссеры.

Э.Үтәгәнов – «Совет Татарстаны» (1969), «Онытылмас еллар» (1987), «Галимҗан Ибраһимов» (1988), «Мин кем соң?» (1996) фильмнары авторы.

Ул 2012 елның 11 июлендә вафат булды.

Галим
Гыйлем Камайның
тууына 120 ел

Галим, күренекле химик Гыйлем Хәйри улы Камай 1901 елның 23 февралендә Казан губернасының Тәтеш шәһәрендә туган.

1916-1920 нче елларда ул Татар укытучылар мәктәбендә укый. 1920-1922 нче елларда Кызыл Армия сафларында хезмәт итә. 1922-1926 нчы елларда Томск университетында белем ала.

Г.Камай – 400гә якын фәнни хезмәт авторы.

1931 елда ул, татарлардан беренче булып, Казан дәүләт университетының химия профессоры дәрәҗәсен ала. 1935-1937 нче елларда – Казан университеты ректоры, 1930-1931 һәм 1944-1945 нче елларда – Казан химия-технология институты директорының урынбасары, 1945-1952 нче елларда – СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалында гыйльми сәркатип.

Г.Камай 1970 елның 17 мартында вафат булды. ■

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.*

Безнең мирас №2 февраль 2021

Нигез

Раил Садриев

Нигез… Бернинди йорт та, бернинди корылма да, бернинди багана да – бернәрсә дә бу дөньяда нигезсез тора алмый. Бөтен нәрсә нигезгә корылган. Бу тулаем караганда шулай. Адәм баласы өчен иң кирәкле әйберләрнең берсе – нигез. Үзе туып үскән йорт, шул нигездә үткән еллары, шул вакыттагы хатирәләр аны гомер буе озатып барачак. Алар олыгая-олыгая сагындырачаклар һәм шул нигезнең югалуы, булмавы аның бәгырен ашаячак.

Мин үземнең туган нигеземдә яшим. 340 елга якын элек ата-бабамнар, минем бабамның бабасының бабасы чыккан нигездә гомер итәм. Ярты авыл шушы нигездән чыккан. Язмыш минем юлларны шундый итеп чуарлады, бутады ки, тик, ахыр чиктә, барыбер киредән туган нигеземә әйләндереп кайтарды. Бүген инде мин шунда сихәт алып, тулы гармониядә диярлек яшәп ятам. Монда миңа һәр алабута, һәр кычыткан, язын һәм җәен күлдә кычкырган бакалар да, камыш шаулавы да, аның исе дә, агачларның балачактагы шәүләләре дә – барысы да таныш. Гомумән, шул ук урамнар, шул ук күршеләр диярлек, шул ук мин йөргән балалар бакчасының рәшәткәсе – болар барысы да минем хәтерне көн саен диярлек яңартып тора. Яңартып кына калмый, тормышыма ниндидер илаһи бер ямь, тәм өсти, яшәү энергиясе, стимул бирә, чөнки бу – туган нигез,

туган авыл. Медитация ясаганда да иң беренче күз алдына шушы нигездән чыккан бабайларны китерәм. Аларның күбесен мин белмим дә, шәйләмим дә. Ниндирәк кеше булганнар, ничегрәк яшәгәннәр ул нигездә, ниндирәк гамәлләр кылганнар?..

Авылда гамәл кылу нәрсә ул? Иген икәннәр, мал асраганнар, бакчачылык исә әле ул вакытта моның кадәр булмаган. Кыскасы, тормыш йөген тартканнар. Шуннан сугышка киткәннәр, кайтканнар, өйләнешкәннәр, оя корганнар, балалар үстергәннәр, кар көрәгәннәр, бәрәңге утыртканнар һәм алганнар, мичкә якканнар, төтен чыгарганнар, коймак пешергәннәр, түгәрәк өстәл тирәсендә җыелышып гапләшкәннәр, серләшкәннәр, аулак өй оештырганнар, мәҗлес ясаганнар, берсен-берсе юатканнар, кыскасы, шулай тормыш алып барганнар, бер-берсен бакыйлыкка-мәңгелеккә озатканнар. Мин дә шулай озаттым. Башта дәү әни, аннан соң энекәш Барлас китте, аннан әни, күптән түгел әти, шуның өстенә, Мәскәүдән алып кайтып, җеназасы шушы йортта укылган туган-тумачалар да шактый. Гомумән, адәм баласының яшәеше шулай бара. Авыл тормышы, каланыкына караганда, миңа шуның белән якын: тирә күршеләр бер-берсен беләләр, алар, бер дисбе, бер тышау шикелле, бер-берсенә бәйләнгәннәр, алар бер-берсенең эчке кичерешләрен аңлыйлар төсле. Бер урамда, бер мәхәлләдә бер гаилә шикелле яшәп яталар. Тугач та җиңел, яшәгәндә дә җиңел, киткәндә дә җиңел авылда. Шундый сүзтезмә бар: «ут күршеләр». Нәрсә соң ул ут күрше? Моны хәзерге яшьләр аңламыйлардыр да инде. Элек бит газ юк, газ кермәгән, күпчелек очракта шырпы да булмагандыр, шуңа күрә, учакта ут сүнгәч, күршегә йөгереп кергәннәр, чөнки казан асарга, мич ягарга ут кирәк. Һәм якын күршедән чыра белән ут алып чыкканнар. Күршенең якынлыгы шуның белән билгеләнә, син аннан чыгып җиткәнче ут та сүнеп өлгерми, шуңа да «ут күрше» дип атала ул. Авыл менә шундый күршеләре белән кыйммәтле. Авыл тормышының шушы җылылыгы һәм күршеләрнең, туганнарның, дусларның, сабакташларның, танышларның күпчелегенең бер тирәдә булуы – барысы да шушы гармониягә керә.

Бүген бөтен дөньяга йогышлы авыру килде һәм кешенең яшәешен үзгәртте. Үзгәрешләр әле киләчәктә дә шактый булыр. COVID-19 – шуларның берсе. Ул – провокатор. COVID-19 бүген кайбер кешеләр өчен әҗәл ролен үтәсә, шул ук вакытта җәмгыятьтәге аерым законнарга тотрыксызлык та кертә. Шул законнарның берсе – мегаполиста яшәү. Шушы мегаполисларда гомер иткән кешеләргә 2020 елның бусагасы аша килеп кергән COVID-19 тудырган кризис, яшәр һәм исән калыр өчен, күпчелек халыкны үзләренең шәһәр янындагы участокларына яки үзе чыккан авылларга яңадан кире кайтарачак. Авыл, гомумән, адәм баласын яңадан коткарачак, чөнки ул – җир, ул – бакча, ул – үзең үстергән ризык, ул – күп әйберләрдән дәва һәм шул ук вакытта күңел тынычлыгы да.

Ярар, COVID-19 без аңлап бетермәгән нәрсә булса, безнең бит әле адәм баласын 100 елдан артык юк итеп килүче онкология чире дә бар. «Онкология нидән килеп чыга?» – дигән сорауга мин бервакыт үземчә, ничектер, җавап тапкан кебек булдым, чөнки онкология аркасында әнине, дусларны, якыннарны озатырга туры килде. Якын дустым Фәиз Израильдә операция ясатып кайтып, бераз вакыт үткәч, аңа, үзем дә сизмәстән, онкологиянең каян барлыкка килүен аңлатырга тотындым, үзем аңлаганны җиткерергә тырыштым. Фәиз миңа күзләрен тутырып карап тора. Шуннан соң мин сөйләп бетергәнне көтте дә:

«Менә кешенең ата-бабалары яки үзе тарафыннан тудырылган, ныгытылган нигезе булып, ул шуңа таянып эш йөртсә, тормышын көндәлек күзәтүләргә корса, кояшны каршы алып, аны офыкларга озата алса, канәгать булып яшәсә, ул үзе дә балалары, оныклары өчен бер нигезгә әйләнә.

«Ә син боларны каян беләсең?» – ди. «Мин сиңа хәзер нәрсә уйлыйм, шуны әйтә барам, менә шулай була», – дим. Ә ул: «Миңа бу нәрсәләрне Израильдә профессор сөйләде. Эчтәлеге нәкъ синеңчә», – ди. Эчтәлеге, беләсезме, нәрсәдән тора иде аның? Дисгармония дигән сүздән. Ул нәрсәне аңлата соң? Бу халәт кешенең эчке дөньясы белән тышкы дөньясы, эчтәге хисләре белән тыштагы гамәлләре тәңгәл килми башлаудан туа. Алар төрлегә әйләнә, поляр кырларга, полюсларга аерыла һәм бер-берсе белән күзгә күренмәгән көрәш алып бара башлый. Адәм баласы икеләнә, борчыла, эше бармый, эчке дөньясы кайный. Ул эченнән бер нәрсә эшләргә, дөньясын башкачарак итеп үзгәртергә тели, ә тышта бөтенләй бүтәнчә – хәтәр бураннар уйный. Эчке халәте бер нәрсә тели икән, тышкы дөньяда аның киресе килеп чыга. Менә шундый киеренкелек туган җирдә рак күзәнәкләре (Җир шарында яшәүче кешеләрнең 98 процентында бүген рак күзәнәкләре бар) активлаша, бер урынга җыела башлый. Күз алдына китерегез: оешкан җинаятьчел төркем (ОПГ) бик каты хәтәр нәрсә, ә инде кесә карагы ул кадәр куркыныч тудырмый кебек. Менә рак күзәнәкләре дә шулай. Ул үзе генә булганда, алай ук хәтәр түгел, ә инде бергә туплангач, чөнки кешенең көндәлек проблемалары арта бара, алар бер шешкә әйләнә. Һәм шул шеш кешене әкертен генә үтерә башлый. Күпчелек очракта шулай, тик һәрвакыт түгел. Ниндидер ерак утрауда үзенең замогында яшәп ятучы, тормыштан канәгать кеше проблемасыз гомер итә ала, тик күпчелек үзләре дә аңламый торган шушы тормышның көндәлек агымында миңгерәгән сарыклар шикелле яшәүне дәвам итә. Әйе, сарыклар, бу изге китапларда да язылган. Адәм баласына Ходай Тәгалә тарафыннан җибәрелгән пәйгамбәрләре һәрвакытта да шундый сүзләрен яңгыратып килделәр: «Мин – пастырь, сезнең көтүчегез», – дигән формада. Без әле дә аңламыйча яшәвебезне дәвам итәбез: җыябыз, туплыйбыз, тартышабыз, судлашабыз, сугышабыз, эшлибез, арабыз, кайтабыз, ятабыз, торабыз һәм беркөнне кинәт кенә тора алмыйбыз. Китеп барабыз. Бүген кешенең дөньядан китүе беркемгә дә гыйбрәт түгел, ә ул бит гыйбрәт булырга тиеш. Туплады-туплады да бернәрсәсез китеп барды. Балаларына, якыннарына, читтән күзәтеп карап торучыларга гыйбрәт югыйсә: бай да китә, ярлы да китә – барысы да гүр иясе була. Минем хәзер тирән, үлем белән бәйле хатирәгә кереп китәсем килми, яңадан нигезгә әйләнеп кайтам.

Нигез. Нигезнең булуы Архимедның бер законына корылган: «Дайте мне точку опоры, и я переверну весь мир!» Менә кешенең ата-бабалары яки үзе тарафыннан тудырылган, ныгытылган нигезе булып, ул шуңа таянып эш йөртсә, тормышын көндәлек күзәтүләргә корса, кояшны каршы алып, аны офыкларга озата алса, канәгать булып яшәсә, ул үзе дә балалары, оныклары өчен бер нигезгә әйләнә. Шуның өчен элек-электән, нигезеңне югалтма, дигәннәр. Авылда иң зур каргышларның берсе дә: «Капка төбеңә чирәм үссен!»– булган, чөнки капка төбенә чирәм үссә, сукмак юк дигән сүз. Бу сукмактан син чыгып

йөри алмыйсың, димәк, син авыру хәлдә өеңдә, нигезеңдә ятасың. Балаларың чыгып киткән дә, кайтучы юк.

Нигез – бүгенге тотрыксыз җәмгыятьтә иң тотрыклы, кирәкле нәрсәләрнең берсе дип саныйм мин. Нигезләрне барларга йә үзең яшәгән җирдә ныклы нигез булдырырга кирәк. Бер яктан, корган корылмаларың белән булса, төп өлеше – шул нигезне кылган гамәлләрең белән ныгытырга кирәк. Тагын бер кат искәртеп әйтәсем килә, куркытып түгел, ә искәртеп: менә бу Ходай җибәргән авырулар тиктомалдан килеп чыкмый. Һәр авыру – кешелек дөньясының ниндидер бер үсеш юлында аны чистартучы, көйләүче, юнәлеш бирүче нәрсәләрнең берсе. Һәм COVID-19 да шул исәпкә керә. Ул адәм баласын бераз тетрәндереп, аның яшәешенә иман кертүче, тотрыклылык биреп торучы нәрсәләрнең берсе булып тора. Әдип **Фәнис Яруллин**ның шундый шигъри юллары бар:

Хыялларны өеп яктым әле,
Дөнья китте артык суынып.
Якты уйларымның учагында
Хет бер кеше китсен җылынып.
Безгә бит гел шул җылылык җитми,
Җаннар каткан инде бозланып.
Дөньясына утлар төртү кирәк,
Янар өчен әрнеп, сызланып.
Әрнемәгән, сызланмаган җанда
Битарафлык җәя кочагын.
Карый-карый һәркөн яманлыкка,
Күзләр җыя дөнья пычрагын.
Ялган сүзләр сөйләп тел пычрана,
Аңа бәрелеп йөзләр карала.
Йөз карасы бетми юып кына, –
Ул җил белән җиргә тарала.

Менә шушы нәрсәләрдән тетрәнү, чистарыну, аларны барлау кирәк. «Нәрсә булды безгә? Ник алай түгел? Нәрсәдер болай түгел?» – дигән сорауларга җавап табар, хатирәләрне яңартып, киләчәк юлны билгеләр өчен, кешегә бер таяну ноктасы кирәк. Шул урыннарның берсе – адәм баласының нигезе. Аңа кадәр барлыкка килгән нигезме ул, йә булмаса, үзе булдырган нигезме – анысы мөһим түгел.

Адәм баласына бүген таяну ноктасы гына түгел, аңа ниндидер башка терәк тә кирәк. Һәм ул үзе дә кемгәдер терәк булырга тиеш. Авыр заманалар килеп бара, ләкин кешегә беркайчан да җиңел булмаган. Дөрес, җиңел тоелган вакытлары булгандыр, әмма җирдә яшәү беркайчан да ансат бирелмәгән. Һәм шуңа күрә кешенең иң төп бурычы – бу дөньяда кеше булып калыр, кемгәдер таяныч, терәк булыр, дисгармониягә кереп китеп чирләмәс, гармониядә яшәр өчен, үзе өчен таяну ноктасы булган **нигезне булдыру**, аны **саклап калу** кирәк…

Язмамны шигъри юллар (кызганыч, авторын хәтерләмим) белән тәмамлыйсым килә:

Яшәр өчен җанга өмет кирәк,
Учак кирәк нәни булса да.
Таяныр өчен ныклы иңнәр кирәк,
Кайтып егылырга – **бусага.** ■

Безнең мирас №2 февраль 2021

Театр яктысы

Рәдиф Сәгъди

* * *

Драма әсәрләрендә дә тормыш чынбарлыгы чагылдырылырга тиеш. Ләкин аның яшәештәге чынбарлыктан бик күпкә кабартылган, арттырылган булуы мөһим! Шул чакта гына әсәр тамашачы күңеленә барып ирешә, үтеп керә.

* * *

Әгәр дә әсәрдә гел каралык, тискәре күренешләр генә, мәгънәсез сыйфатлар гына өстенлек итә икән, аның бернинди дә әдәби, сәнгати кыйммәте юк. Тамашачы алар белән көндәлек тормышта даими очрашып тора. Ул театрга рухи чистарыну, уңай кичерешләр һәм гыйбрәт-сабак алу, шул ук вакытта күпмедер дәрәҗәдә ял итәр өчен дә килә. Чын әдәби әсәрнең тәрбияви көче ташып торырга һәм тамчылап булса да әдәп тәрбияләргә тиеш.

* * *

Соңгы егерме-утыз ел эчендә кендектән түбән күренешле спектакльләр атыматы белән тозсыз сүзләр сөйләнеп, халыкны затлы әсәрләр караудан мәхрүм иттеләр. Яшь буынның күпчелеге шул тискәре рухта тәрбияләнде. Инде хәзер кеше җитди әсәрләрне аңламас, тоймас дәрәҗәгә җиткерелде.

Өлкән буын белән урта буын тамашачылар, тозсыз күренешләрне карап, көлепхихылдап утырса да, кайтыр юлда әлеге тамашадагы әдәпсезлекне сүгә. «Мондый исерекләрне, зимагурларны без өйдә дә, урамда да көн саен күрәбез», – дип, уенчыларны тирги, тоткан акчасын кызгана башлый.

* * *

Театр залларында тамашачы ни өчен елдан-ел кими бара? Чөнки сәхнәдән җансыз курчаклар уены күрсәтелә. Актерлар, режиссер куйган мизансцена буенча йөреп, буш сүз сөйлиләр. Сәхнәдә яшисе урынга, коры сүз тезмәләре сибәләр. Үзенең йөрәге аша үткәрә алмаган актерның уенын тамашачы ничек кабул итсен… Нишләп шулай соң ул?!. Чөнки күпчелек режиссерларның профессиональ дәрәҗәләре бик түбән. Алар Станиславский системасын белсәләр дә, аңламау сәбәпле, аны спектакль куйганда куллана алмыйлар. Төп максат, үзмаксат иң беренче чиратта таләп ителергә тиеш. Һәр җөмлә, һәр сүзнең тел төбе (подтексты) чарланырга тиеш. Шул чакта мәгънәви басым үзеннән-үзе куела. Бүгенге көн режиссерлары актерларны сүз басымы эзләтеп тинтерәтәләр. Иҗатчы роль уйнаганда үзен чынбарлыкта итеп тояр дәрәҗәгә җиткерелергә тиеш. Шул чакта

гына актерның уены тормыштагы кебек тере, чын булачак. Пьесадагы драматургия, уен көчле, тетрәндергеч булса, тамашачы, радио-телевизорын, компьютерын калдырып, тамаша карарга киләчәк. Яхшы әсәрнең исеме бик тиз тарала! Спортта да шулай, әйтик, «ЦСКА», «Рубин», «Ак барс» командалары яхшы чыгыш ясый икән, тамаша кылучылар белән трибуналар тула. Әгәр шыксыз уен күрсәтсәләр, киресенчә, бушап кала. Театр заллары да нәкъ шулай. Әсәрнең генераторы драматург булса, роторы – режиссер.

* * *

Әгәр дә әсәре анализлый, сүтеп-җыя белә торган талантлы режиссер кулына килеп эләкмәсә, бер генә драматург та үсеш кичерә алмый. Драматург ул вакыйгалы чимал гына бирә. Әйтик, аннан тәмле итеп тә, булдыксыз кулга эләксә, ашамаслык итеп тә төрле спектакль «пешереп» була. Пьесаны куйганда, төп пешерүче, – әлеге дә баягы, – режиссер.

* * *

Драма әсәрендә вакыйга ярылып ятарга тиеш һәм ул, спектакль барышында үсеш кичереп, зур киеренкелек тудырырга, ул киеренкелек, пружина кебек кысыла барып, соңыннан атып бәрергә, чишелешкә китерергә тиеш. Әсәрдәге образларның һәрберсенең үз холкы, сөйләмдә үзенчәлекле һәм кызыклы булуы мөһим. Аның өчен актердан үзе уйнаячак геройның автобиографиясен яздыру, шул ук вакытта урамда да үз героена охшаган шәхесләрне күзәтү, аның гадәтләрен өйрәнү дә сорала. Бөек актерлар нәкъ шулай эшләгәннәр дә. Ни кызганыч, бүгенге көндә татар театр сәнгатендә тамашачыны кызыктырмаган вак вакыйгалар белән тулган әсәрләр, бертөрле сөйләшә торган образлар хөкем сөрә. Бу нәтиҗәсезлеккә китерә. Драматургиясе сыек әсәрне куюы режиссерга бер бәла булса, уйнаган артистларга икенче бәла! Тамашачыга чүп карау бер дә кызык түгел!

* * *

Яхшы спектакль, яхшы уен, ягъни сәхнәдә уйнаган образның тормышы белән яши алу тамашачының күңелен яулый, үзенә бәйли. Әгәр дә караучы буш кайтып китә икән, спектакль барып чыкмады дигән сүз!

* * *

Тинчурин театрында бик озак еллар Роза Хәбибрахманова иҗат итте. Ул үзе профессиональ машина йөртүче иде. Тора-бара, Күчмә театрда уйнарга кеше җитмәгәч, аңа бер роль бирәләр. Һәм ул барысын да шаккатырып уйнап чыга. Роза апа театрда шофер һәм актер булып бик күп еллар эшләде: шул чорларның берсендә ул, бер актриса белән бәхәсләшеп киткәч, үзен зурдан куючы бу ханым: «Роза, син бит Станиславскийның «С» хәрефен дә белмисең!» – дип ярсыган иде. Роза апа да сүз эзләп кеше кесәсенә керми иде. Ул әлеге ханымның авызын: «Син Станиславскийны укудан ни файда!» – дип, бик тиз каплаган иде.

* * *

Станиславский системасын төптән аңлаган режиссер гына актерларын шул системада тәрбияли ала. Анда да аңа айлар гына түгел, еллар кирәк булачак. Әлбәттә, барлык артистлар да моңа төшенә алмаячаклар, чөнки ул табигатьтән бирелмәгән булырга мөмкин! ■

Безнең мирас №2 февраль 2021

Затлы дәвам фестивале

Гөлзада Сафиуллина, Разил Вәлиев һәм Рабит Батулла «Сөембикә варислары» фестивалендә

Төрки-татар балаларының «Сөембикә варислары» халыкара фестивален мин, һич икеләнмичә, җыен дип атар идем. Анда – сәнгать, тарих, милләт язмышы, яшәешебез. Әлбәттә, фестиваль эчендә ярышу-бәйге рухы да бар. (Тормыш ярышсыз булмый.) Әмма төп максаты – үсеп килүче буынга Аллаһы Тәгалә тарафыннан салынган тере күзәнәкләрне барларга, ачарга, сакларга һәм үстерергә булышу. Шуның аша бу дөньядагы үз урыныңны, хәерле юлыңны, асылыңны табарга ярдәм итү. Төрле бәйгеләрдә, чараларда ихтыяр көчен чарлатып, адәм балаларына гына хас уңай сыйфатларны – киң күңеллелек, ярдәмчеллек, кешелеклелек, сабырлык тәрбияләү, мәңгелек кыйммәтләр хакына үз-үзеңне аямаска өйрәтү. Туган җиребезнең, газиз Ватаныбызның кадеренә төшендерү, яратылыш хакында уйландыру; табигатькә, әткәй-әнкәй, әби-бабаларыбызга, гореф-гадәтләребезгә хөрмәт булдыру; шуларның кадерен аңлап, тәртипле, иманлы, әдәпле, гомумкешелек дөньясында үз урынын таба алган, үз халкының мәдәниятен, сәнгатен, тарихын яхшы белгән горур төрки-татар балалары тәрбияләү. Җебегәнлектән, тар күңеллелектән, хөсетлектән азат, әйтәсе фикерен шартлатып әйтеп бирә алган кыю, ачык күңелле, ихлас, креатив дәвам үстерү.

«Сөембикә варислары» фестивале – бабаларыбызның бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән учагын сүндерми саклауның бер юлы, тәрбия мәктәбе ул!

Фестивалебез 1999 елда Кырымда, Ялта каласында башланып китте. Беренчесендә 90га якын бала катнашкан булса, алга таба аларның саны 500гә җитте. Фестиваль ел саен халыкара дәрәҗәдә үткәрелеп килде. Казанда ул дүрт тапкыр уздырылды. Оештыручылары – «Гөлзадә» иҗат студиясе, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы, Кырым Мәдәният министрлыгы булды. Шу-

лай ук Кырымдагы «Идел-Урал», «Акчура» татар җәмгыятьләре, Киевтагы «Туган тел» мәдәният үзәге, «Сөембикә» һәм «Ялкын» журналлары, «Әнием-Мама» иҗтимагый хәйрия фонды һәм башкалар ярдәм күрсәтте.

Ул чакта Кырым Украина составында иде әле. Фестивальгә ил чикләрен кичеп бара идек. Чараны ачу тантанасы диңгез буендагы Ленин мәйданында, импровизацияләнгән сәхнәдә уза иде.

Программа азан белән башланып китә, аннары фестивальнең гимны яңгырый:

Бөтен дөнья балалары, барчагыз да,
Ач-ялангач булсагыз да, арсагыз да,
Сез тыңлагыз безнең татар балаларын,
Сезгә дигән теләкләре бар аларның!
Без яшибез бер үк җирдә, без – күршеләр,
Әйдәгез, без дуслар булыйк, без – кешеләр,
Кипсен кояш нурларында күз яшегез,
Бөтен дөнья балалары, берләшегез!

Үскәчтен дә дошман булмыйк беребез дә,
Бары дуслык сүзе булсын телебездә,
Шатлык кына таратыйк без өйдән-өйгә,
Тик кунакка йөрешик без илдән-илгә,
Тынычлык, дип, барыгыз да бер дәшегез!
Бөтен дөнья балалары, берләшегез!

Килер безгә гомумбәхет дәвере бер,
Җир бомбасыз Җир шарына әверелер,
Самолетлар бомба түгел, гөлләр чәчәр,
Кешеләр бер гаиләдәй гөрләп яшәр.
Һәммәбез дә күгәрчендәй гөрләшербез,
Бөтен дөнья балалары, берләшегез!

Алып баручылар Альбина Мөхәммәтшина (саф татар телендә) һәм Әхтәм Сәетаблаев (кырым шивәсендә) фестиваль кунакларын сәламли иде. (Җөмләдән, Әхтәм бүген Киевта эшли, данлыклы режиссер, депортацияләнгән кырым татарлары турындагы «Хайтарма» фильмының авторы.) Концерт башыннан ахырына кадәр татар телендә бара, төрле милләт, хәтта чит илләрдән килгән туристлар да концертны рәхәтләнеп карый иде. «Нигә урыс телендә алып бармыйсыз?» – дип, ник бер кеше сорасын. Татар моңы, татар теле, милли киемнәребез, җырларыбыз тамашачыларның игътибарын нык җәлеп итте. Әле дә хәтеремдә: бер марҗа карчыгы, Марат Фәйрушин җырлаганда, урыныннан тора да утыра, тора да утыра. «Бабушка, торопишься что ли, уйти хочешь, да?» – дип сорыйм моңардан. «Да, миленькая, надо идти, дома внук один остался. Я проходила мимо, на минутку остановилась и не могу уйти. Неужели это все татары? Костюмы какие, какая мелодия! Не отпускает ведь!» – димәсенме!

Фестивальне азан белән башлау җитәкчеләрне бераз шүрләтте. Әмма минем өчен азан – иң матур җыр, азатлык символы, Аллаһы Тәгаләгә сыену. Ул – намазга чакыручы изге оран, бу очракта безнең балаларыбыз колагына кереп, иманнарын ныгытучы илаһи моң булды. Шушы моң безне матурлыкка, гүзәллеккә, камиллеккә омтылырга чакырды. Аллаһы Тәгаләнең янәшә булуын искәртә, көч-куәт бирә, балаларга чит җирдә кыюлык өсти иде ул. Шуңа күрә дә фестивальгә килүче малайларга Сәйдә абыстаебыз (ул күп фестивальләрдә катнашты, балаларга әхлакый тәрбия бирде, аңа Аллаһның рәхмәте яусын!) беренче көннән үк азан өйрәтә, аннары бәйге оештыра, җиңүче малай фестивальне ачу тантанасын азан белән башлап җибәрә иде. Ул бәхет, гадәттә, Рабит Батулланың улы Байбулатка эләкте.

Фестивальнең күркәм башлангычы: беренче көнне үк кулларыбызга дәүләт байраклары һәм чәчәкләр тотып, күкрәкләребезгә – «Сөембикә варислары» эмблемасы, өстебезгә – «Мин татарча сөйләшәм» сүзләре төшерелгән ак футболкалар, башыбызга «Кырым» дип язылган бейсболкалар киеп, саф-саф тезелгән килеш шәһәр урамнары буйлап, «Сөембикә варислары» гимнын җырлый-җырлый, сөргенгә җибәрелгән кырым татарлары һәйкәле янына җыела идек...

Безнең сафта, балалар белән беррәттән, аларның укытучылары, әти-әниләре, арттарак – җитәкчеләребез, эшмәкәрләр, волонтерлар, оештыручылар бара иде:

– Кырымга тынычлык, иминлек, бердәмлек!

– Яшәсен татарларның Ватаны – Кырым!

– Ура!

– Сәлам Казаннан!

– Казакъстаннан! Хаҗитарханнан! Себердән! Уралдан! Балтыйк буе илләреннән! Дагъстаннан! Алтайдан!..

Һәркем туган җиреннән сәлам тапшыра, аннары һәйкәл янында митинг оештырыла иде. Мәдәният министры Илдус Тарханов, Дәүләт Советы депутаты Разил Вәлиев, язучы Рабит Батулла, бертуган Тәлгать һәм Ринат Абдуллиннар сөйләде, шулай ук башка төбәкләрдән килгән җитәкчеләрнең дә чыгыш ясаганы булды. Ник бер милиция-фәлән туктатсын! Шуннан, сафларга тезелеп, җырлый-җырлый, күренекле татар язучысы Галимҗан Ибраһимов яшәгән йортка юл тотабыз. Барып җиткәч, укытучылар аның иҗаты турында сөйли, балалар язучының әсәрләреннән өзекләр укый. Рухына багышлап дога кылабыз. Аннары, әйтелгәнчә, Ленин мәйданына юнәләбез...

Фестивальне Сөембикә ханбикә исеме белән атау да очраклы булмады. Ул – Кырымнан Казанга чакырылган Сафагәрәй ханның җәмәгате. Бер яктан безне шулай Кырым белән тоташтырса, икенче яктан, Йосыф морзаның кызы буларак, нугайлар белән тоташтыра, туганлаштыра. Ике мәгърур ыруны Казан белән дә ялгасаң, Бөек Болгар һәм Алтын Урда дәүләтләрен тулаем күзаллый башлыйсың...

Фестиваль-җыенга без, төрки-татар дөньясының мәшһүр әдәбият-сәнгать әһелләре белән бергә, төрле һөнәр осталарын, тарихчыларны, сәясәтчеләрне, галим-голәмәне, акыл ияләрен дә чакыра килдек. Алар, төрле елларда катнашып, дәрес-сабак биреп кенә калмадылар, үз-үзен тотышлары, яшәешләре белән балалар өчен асыл үрнәк тә була белделәр.

Без татар әхлакый кануннарын саклаган зур гаилә, тулы җәмгыять булып яшәдек. Арабызда иң олысы Җәвит ага Котдусов иде. Ул – 40 ел буе Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә хор җитәкчесе булып эшләгән, Казан мәдәният һәм сәнгать институтында яшьләргә белем биргән, Кырым индустриаль педагогия институтында кафедра мөдире, профессор булып торган күренекле шәхес. Җыр сәнгатен аннан да тирәнрәк, нечкәрәк белүче бар идеме икән?! Ул барлык фестивальләрдә киңәшчем, таянычым булды. (Ни кызганыч, берничә ел элек арабыздан китеп барды. Дөнья бәһасе кеше иде, урыны җәннәттә булсын мәрхүмнең!) Жюри эшендә катнашырга берсүзсез ризалык бирде. Гомумән, хөкемдарларның барысы да бик мәртәбәле шәхесләр иде: халык язучысы Рабит Батулла, җырчы, композитор Мәсгут Имашев, фольклорчы галим, музыкант, фән кандидаты Геннадий Макаров, сәнгать белгече Розалина Шаһиева, журналист, вокал серләрен яхшы белүче Филүсә Арслан, Галиәсгар Камал театры балетмейстеры Сәлимә Әминова, композитор Риф Гатауллин, җырчы Рөстәм Асаев, мәшһүр Сара Садыйкованың кызы – балерина Әлфия Айдарская, ике иҗади шәхес тәрбияләп үстергән ана Гүзәл Маликова, Семәйдән (Җидепулат) – композитор, җырчы, педагог, җәмәгать эшлеклесе Габделхак Ахунҗанов, Кырымнан – композитор, җырчы, «Кырым» җыр һәм бию ансамбле җитәкчесе Сәрвәр Какура, композитор, музыкант, халыкара конкурслар лауреаты, продюсер Сәрвәр Мостафа, әдип, җәмәгать эшлеклесе Диләвер Османов... Соңгы елларда җырчы Марат Фәйрушин җитәкчелегендә балалар жюрие дә эшләде. Шунысы игътибарга лаек: аларның бәяләмәләре һәрвакыт өлкән жюриныкы белән туры килә иде. Әйткәнемчә, Марат Фәйрушин турында бер китап язарлык. Биш яшеннән алып бүгенге көнгә кадәр сәхнә аша милләткә хезмәт

итүче башка баланы мин белмим. Ә репертуарының зурлыгы, киңлеге, затлылыгы! Сәхнәдә сөйләгән сүзләре, костюмнары, үз-үзен тотышы гел милли! Итагатьле, соклангыч һәм үтә тыйнак егет ул.

Бер елны «Сөембикә варислары» фестиваленең жюрие эшендә Казан дәүләт консерваториясе ректоры Рубин Абдуллин да катнашты (жюри әгъзалары һәрдаим алышынып торды, биш кеше генә алыштыргысыз иде). Ул елны кырымтатарлардан гаять талантлы музыкант Алим Рамазанов гран-прига лаек булды. Конкурс көннәрендә жюри 12шәр сәгать эшләде. Балалар күп, барысын да тыңлап, карап чыгарга өлгерергә кирәк. Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлегеннән килгән балаларның саны 300-400гә җитә! Шуңа өстәп, Кырымның үзеннән 3-4 бию ансамбле (һәрберсендә 2-3 зурлар төркеме, бер зурлар төркемендә 20-30 ар бала!) катнаша. Тагын күпме кечкенә төркемнәр, солистлар… Алар, автобусларга төялеп, Ялтага киләләр; чыгыш ясагач, өйләренә кайтып китәләр. Башка балалар кебек санаторийда яшәргә матди мөмкинлекләре юк. Әмма үз-үзләрен тотышлары, тәртипләре белән алар бик күпләргә үрнәк күрсәтте. Әле кайчан гына үз Ватаннарына кайткан кырымтатар халкы шундый бердәм, кыю, горур иде! Киемнәрен күрсәң: барысы да милли бизәкле, аяк киемнәре ялтырап тора, кызларның барысында да төрки-татарча чигелгән, көмеш белән бизәлгән билбау. Кечкенә малайлар үзе – бер карыш, башындагы каракүл бүреге – ике карыш; җырлаган җырлары, нигездә, Ватан, туган җир, ата-ана, әби-баба, мәңгелек кыйммәтләр турында. Биегәндә куллары кошлар сыман күктә (безнекеләрнең куллары һаман да аркада, богауда әле)! Дагъстаннан килгән нугай балаларының кулларында – думбыра (бөтен төрки халыкларның үз думбыралары бар, ә без, татарлар, һаман үз думбырабызны булдыра алмыйбыз, төрекнекендә уйныйбыз, гәрчә Геннадий Макаров татар думбырасын ясап, балаларыбызга өйрәтеп йөрсә дә), җырларында – дала киңлеге, гайрәт, горурлык, Ватан кадере. Сокланмый мөмкин түгел! Кырымтатар бию ансамбльләренең җитәкчеләре дә яшь кызлар шикелле сылу, мөлаем, зәвыклы. Сөйләшүләре әдәпле. Горбәтлектә яшәү, күрәсең, аларны башкалардан җиде баш югарырак булырга өйрәткән. Сокландым, бик сокландым, ләкин… күңелемнән генә борчылдым да. Их, әгәр дә мөмкинлекләре булып, безнең балалар белән аралашып, бер-берләреннән үрнәк алып, санаторийда яшәсәләр, кемнәрне генә тәрбияләмәс идек без!

Миңа фестивальләр чорында, ягъни 20 ел эчендә, өч тапкыр Дагъстанда яшәүче нугай татарлары янында булырга туры килде. Кечкенә генә бер районнары бар, шунда «тау иле»нең барлык нугайлары тупланган. Алар үзләре бер дәүләт булып яшәп яталар. Иң күренекле шагыйрәләре Кадрия вафат инде. Бу дөньядан яшьли киткән. Һәр нугай кешесе аның әсәрләрен яттан белә. Дәүләт халык уен кораллары ансамбле, җирле телевидение бар. «Айланай» ансамбле дастаннарны халыкка кайтара. Җырлыйлар, бииләр, борынгы уен коралларында уйныйлар, халыкара конкурсларда катнашып, җиңүләр яулыйлар…

Миңа атаклы нугай җырчысы, композиторы Яхъя Кудайбирденең (ул Дәүләт музыка уен кораллары ансамблен җитәкли) 50 яшьлек юбилеенда һәм шулай ук Россиянең халык артисты Асият Кумратованың Махачкалада узган концертында катнашырга насыйп булды. Шул вакытта нугайларның бердәмлеген күреп шаклар каткан идем. Дәүләтләре булмаса да, горур халык бу! Үзләренең кемлеген яхшы беләләр, телләрен дә, диннәрен дә саклаганнар, эшмәкәрләре дә милләт дип янып тора.

Безнең фестивальдә нугайлардан ике җырчы малайның катнашканы булды. Берсе – Сәфәрби Уразаев, икенчесе – Үзәер Найманов.

Сәфәрби авыр юл үтеп, бер транспорттан икенчесенә көчә-көчә, Кырымга килде. Килеп җитүгә авырый башлады, температурасы бик югары иде. «Бәлки, чыгыш ясамассың?» – дидем. «Юк, чыгыш ясыйм, мин тереләм», – диде ул. Һәм, чыннан да, савыкты, лауреат дәрәҗәсен алды.

Үзәер Найманов исә барлык фестивальләрдә катнашты диярлек. Бигрәк тә Казанга ашкынып килә иде. Ул күп тапкырлар лауреат, бер тапкыр хәтта гран-при иясе дә булды. Үзәерне Казанга чакыртып, үз өемдә яшәтеп, Казан музыка көллиятендә яхшы педагогларда белем алдырдым. Аннан соң Мәскәүдә сәнгать академиясен тәмамлады. Бүген Сургутта яши, төрки-татар дөньясына хезмәт итә. Җәмәгате дә үз милләтеннән, бала үстерәләр. Клиплары дөньяга чыгып тора. Гомумән, нугайлар бик талантлы, хезмәт сөючән, горур халык. Бер районга сыйган Ватаннарын зурлап, шуның белән горурланып, җырлары һәм дастаннары аша милләтне күтәрәләр. Яхья Кудайбирде һәм Терекле-Мәктәп (Дагъстанның Нугай районы үзәге) мәдәният бүлеге җитәкчесе Нәрбикә Арслан фестивалебезгә нугай балаларын китерү өчен күп көч куйды. Бөек төрки-татар сәнгатенә яңача бизәкләр өстәп, чарабызны һәрдаим баетып, матурлатып тордылар. Ә без…

Без, Ватаныбыз була торып та, аның кадерен белмичә, аның өчен көрәшмичә, газиз телебезне этләрдән талатабыз, үзебезне мыскыл иттерәбез. Мәгънәсез җырлар, мәзәкләр белән сәхнәне, эфирны тутырып, әтрәк-әләмнәр тарафыннан милләтне мәсхәрәләтәбез. Җитмәсә, залга ак яулыклы апаларны чакырып, шуларның авыз ерып утыруларын телевидение аша күрсәтеп, динебезне рәнҗетәбез. Авылның иң ямьсез гадәтләрен күпертеп күрсәтеп, безне: «Менә, карагыз, бу сез, татарлар, менә сез нинди! Надан, аңгыра, үзегезнең тамырыгызны да, кемлегегезне дә белмисез! Мең еллар буе сакланып килгән ана телегезне дә хөрмәт итмисез, динегезне аңлау да хәлегездән килми! Сезнең киләчәгегез шуның белән бетте, бүгенге көндә тәмам!» – дип ышандырырга телиләр…

Юк! Халкымның затлы, зыялы, тәрбияле өлеше зуррак! Сәнгатьне, сәхнәне шуларга хезмәт иттерәсе иде бит! Сәнгать, сәхнә – тәрбия учагы лабаса! Анда беркемнең дә пычрак аяк, пычрак авыз белән керергә хакы юк! 2000 еллык дәүләтчелеге, 1000 еллык язма әдәбияты булган бөек төрки-татар дөньясын, аның мәдәниятен нәҗесләргә дә һичкемгә хокук бирелмәгән!.. Милләт тә, тел дә, дин дә – Аллаһы Тәгаләдән бирелгән зиннәтле бүләк, хәзинә. Моны аңламау, моны сакламау – Аның каршысында зур җинаять.

…«Сөембикә варислары» фестивале шушы фикерләрне алга сөреп, бүген безгә сәхнәдән, телевизор экраныннан агылган шакшыга альтернатива буларак үткәрелеп килде. Шуңа күрә дә аның иганәчесе халык үзе булды. Бу тамаша, шоу түгел. Монда бар да милли, борынгы. Заманчасы да милли тамырларга тоташкан, аннан үсеп чыккан. Бу мәктәп аша узган балаларны юлдан яздыру җиңел булмас, алар корыч иманлы.

Фестивальнең берничә лауреаты хакында аерым әйтеп үтәсе килә.

Альбина Мөхәммәтшина (Насыйрова) – «Бала Сити» мәгариф оешмасының җитәкчесе. Аңа кадәр телевидениедә «Мәдәният дөньясында» тапшыруларын алып барды. Бүген балаларыбызга, туган телебез белән беррәттән, башка телләр дә өйрәтә, милләтебезгә хезмәт итә, нәүбәттәге чакырылышта Дәүләт Советы депутаты булып сайланды.

Илшат Рәхимбай татар кино сәнгатен дөньяга таныту өчен тырыша. Ул күп кино конкурсларында җиңү яулады, затлы клиплары дөньяга чыгып тора. Минем «Әй, татарлар!», «Әй, киң төрки даласы» исемле җырларыма да клипларны Илшат төшергән иде. Узган ел аның белән бергә Төркиядә булырга, халыкара кинофестивальдә катнашырга туры килде. Анда ул иҗат иткән фильмнарга зур бәя бирделәр.

Бертуган егетләребез – Нурбәк һәм Байбулат Батуллалар – шулай ук чын сәнгатькә хезмәт итәләр. Милли сәнгатебезнең сырхау халәте белән килешә алмыйча, аны савыктыру юлларын эзлиләр. Нурбәк, Санкт-Петербургта Югары балет мәктәбен тәмамлап, Казанга кайтты. Байбулат Мәскәүдә кино сәнгате серләренә өйрәнде, шунда эшли. (Нигә Мәскәүдә? Бездә аңа урын юкмыни?!)

«Голос» телевизион проектында җиңү яулаган кызыбыз Эльмира Кәлимуллина да – «Сөембикә варислары» мәктәбен узган бала. 2003 елда ул беренче урынны яулаган иде. Хәзер дә ничек тырыша! Казанда концерт куйды, татар җыр сәнгатенең офыкларын барлады. «Голос»та бөтен халык аны яратты, аңлады, таныды. Без дә шундый талантны танырбызмы, аңларбызмы?!

Фестивальнең лауреаты, искиткеч сәләткә ия җырчыбыз Айгөл Зыятдинова (Айгөл туташ) татар һәм төрек телләрендә җырлый, уникаль тембрга ия. Үзе дә җырлар яза. Туган җире Алабугага багышлап язылган җыры шәһәрнең гимнына әверелде. Үзенең музыкаль җыентыгын чыгарды.

Гөлназ Гафурова татар халык җыры «Гөлҗамал»ны башкарып күпме милләт вәкилләрен таң калдырды. Бүген дә тынгысыз ул: милли киемнәр тегә, репертуары чиксез дә, тиңсез дә, халык җырлары белән беррәттән, классик композиторларыбыз әсәрләрен дә җаныннан уздыра. Казан шәһәр филармониясендә эшли, музыка мәктәбендә укыта. Гаилә корып, бала үстерә.

Бик матур, талантлы, үзләренә генә хас тембрлары белән аерылып торган кызларыбыздан Тамчыгөл, Гүзәл Әхмәдиева, Фәридә Сөнгатова, Гөлназ Асаевалар да үз репертуарларын булдырып, сәхнәдәге урыннарын табып, милләткә хезмәт итәләр. ИншәАллаһ, киләчәкләре хәерле булыр!

Җырчы кызыбыз Ләйсән Әсхәтова турында да аерым әйтәсем килә. Ул кечкенәдән үзе җырлар язды, беркемгә дә охшамаган уникаль тавышка ия. Меңнәр арасыннан аерып алырлык! Бүген дә иҗат итә, яза, җырлый. Ул Казанда һәм Кырымда үткәрелгән барлык фестиваль-концертларда катнашып, тамашачының мәхәббәтен яулады. Бик тәрбияле, сабыр холыклы бала.

Ләйсән белән бер дулкында тирбәлүче тагын ике кыз бар: Алинә Булатова һәм Сәйдә Мөхәммәтҗанова. Бу балалар мөнәҗәт әйтеп тавышларын чарладылар, моң дәрьясында коенып, үзләренә гомергә җитәрлек мая-җим тупладылар. Беркемне кабатламыйча, үз юлларын үзе тапкан балалар бу. Гүя безне: «Ишетегез, менә бу безнең борынгы бабаларыбыз авазы, аларның изге тавышы бүген дә безнең арада яшәргә хаклы!» – дип кисәтәләр.

Лауреат кызларыбыз арасында бик моңлы тавышлы Илнара Хуҗиева бар әле. Махсус белем алып, профессиональ сәхнәгә күтәрелгән матур, тыйнак кызларыбыз Тамчыгөл һәм Гүзәл Әхмәдиевалар да халкыбызга хезмәт итә.

Башкортстаннан Артур Шөгаепов, Артур Хафизов, Булат Гыйниятуллин, Альберт Ситдиков исемнәре дә сезгә таныштыр, мөгаен. Алар барысы да зур сәнгать юлында. Нәфис сүз остасы Дима Баранов та сәхнәдә үз урынын, образын тапты. Бу яшьләргә мин зур ышаныч баглыйм.

Хәзер инде сүзем оныгым Ширин хакында. Ул беренче фестивальләрдән үк катнашып, балалар башкарган барлык җырларны да өйрәнеп үсте. Бәйгеләрдә аңа беркайчан да алдынгы урыннар бирдермәдем (жюри рәисе үзем идем). Тавышы көчле, күкрәктән чыга, тембры бик үзенчәлекле, матур, репертуары да бик бай. Ул кырым татарлары җырларын да, инглизчә, башка телләрдә дә җырлап, бәет-мөнәҗәтләр көйләп үсте. Әмма үсенмәсен, башкалар да «үз оныгын яклый» дип әйтмәсен өчен, аны гел күләгәдә тоттым. «Юк, сиңа тагын да тырышырга кирәк әле», – ди идем.

Күзеннән тәңкә-тәңкә яшьләр тамса да, сер бирмәде, сабыр булды. Ниһаять, «Созвездие-Йолдызлык» фестивалендә лауреат исемен яулагач, күңеле тынычланды, үзенең кем икәнлеген башкалар алдында исбат итте һәм миңа: «Дәү әни, менә, өлгердем бит!» – диде.

Ширин, Казан дәүләт университетының социология бүлеге белән беррәттән, ГИТИСны да тәмамлады. Аннары «музыкотерапия» дип аталган һәм чит илләрдә бик популяр булган дәвалау өлкәсе белән кызыксынды. Вашингтон университетына укырга керде. Хәзер аны тәмамлау алдында тора. Халкыбызда зәвык тәрбияләргә язсын аңа, иншәАллаһ! Ширин берочтан, музыка көллиятенең алыштыргысыз педагогы, 40 ел буе Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә хезмәт куйган күренекле Венера Гәрәевада дәресләр алып, халык җырларын башкару осталыгына да өйрәнде. Шөкер, чиксез шөкер!

2010 елда фестивалебезне Айгөл Хәйри белән Илүсә Хуҗина бизәде. Ялтада 2000 кеше сыйдырышлы концерт залында, татар халык җырларының иң гүзәл үрнәкләрен төрле милләт вәкилләре алдында башкарып, алар һәркемне таң калдырды. Рим Хәсәновның «Ак чәчәкләр»ен икесе бергә җырлап, күңелләрдә иң чиста, иң саф хисләр уяттылар, бу әсәрне дөнья мәдәнияте югарылыгына күтәрделәр. Без дә, аларга сокланып, үзебезнең тагын берничә баскычка күтәрелүебезне тойдык. Мондый кызлар татар сәхнәсенең йөзек кашы булырлык! Алар 4 ел музыка училищесында, 5 ел консерваториядә укыдылар, аннары чит җирләрдә белем эстәделәр… Кайда аларга сәхнә? Юк ул! Чөнки алар – «неформат». Чөнки алар сәхнәгә чыкса, «коммерсант»ларга анда урын калмаячак.

«Сөембикә варислары» фестивалендә күп тапкыр катнашып, лауреат булган Тимур Ибраев хакында да аерым әйтеп узыйм. Тимур 4 яшеннән бирле җырлый. Казанда узган «Юный вокалист» конкурсында «Битлз» репертуарыннан җыр башкарып, 7 яшендә 1 нче урын алды. Мәскәүдә «Голос XX века» бәйгесендә катнашып, шулай ук җиңү яулады. Халыкара «Дельфийские игры»да лауреат булды, халыкара «Звезды мира – детям» чарасында катнашып (һәм анда Монсеррат Кабалье белән бергә җырлап) дан казанды. «Утренняя звезда» проектында җиңде. Казанның Зур концертлар залында мәшһүр дирижер Фуат Мансуров җитәкчелегендәге симфоник оркестрга, Анатолий Шутиков җитәкчелегендәге халык уен кораллары ансамбленә кушылып чыгышлар ясады. Шундый залларда меңләгән тамашачы алдында җырлаган чакта бу бала нинди генә хисләр, дулкынланулар кичермәгәндер! Аның костюмнары гына да ни тора иде! Европа стандарты! Шул ук вакытта үтә милли дә. Ул Резеда Вәлиева һәм Луиза Батыр-Болгари иҗат иткән «Әтием» җырын җырлаганда зал елый иде:

Күңелем күгендә балкыйдыр бүген дә,
Балкыйдыр бүген дә бер исем,
Тормышка юл биргән, җаныма нур өргән
Иң якын, газиз лә бер кешем.

Әткәем, әткәем, күңелемдә, җанымда,
Мәңге син яшь булып калырсың...
Әткәем, кадерлем, күзләрең нурында
Яшермә йөрәгең сагышын...

Кайда бу җырлар хәзер? Кемнәр җырлый аларны? Гомумән, балаларыбыз нинди җырлар җырлап үсә? Бу җырларны Тимур көн дими, төн дими Луиза Батыр-Болгари студиясендә язып калдырды лабаса! Үзе дә сабый килеш безнең балалар өчен шул рәвешле күпме тырышлык, көч куйды, нинди бүләк ясады!

…Фестиваль тарихына янә күз ташласак, шуны күрербез: 1999 елда башланган төрки-татар балалары җыены 4 ел рәттән бернинди тоткарлыксыз уздырылып килде. Төп иганәчебез «Кара алтын» банкы җитәкчесе Ринат Абдуллин булды. 2003 елда,

фестиваль башланырга бер атна кала, иганәчебез ярдәм күрсәтүдән баш тартты.

Фестивалебез биш номинациядә уздырыла иде: җыр, бию, музыка уен коралларында уйнау, нәфис сүз һәм гамәли сәнгать. Барлыгы 25 лауреат билгеләнә, аларга акчалата премия бирелә (гран-при иясенә – 2000 доллар). Авыргарак төшкәндер шул бердәнбер иганәчегә...

400гә якын бала катнашырга әзер, билетлар – кулда, санаторийда урыннар алынган, әмма... фестивальне үткәрергә акча юк. 8000 доллар табарга кирәк! Кая гына мөрәҗәгать итеп карамадым – булышучы табылмады. Шулвакыт елый-елый Аллаһтан: «Йа Раббым, миңа шушы фестивальне үткәрергә ярдәм ит», – дип ялвардым. Икенче көнне Донецкта яшәүче танышым Фәридә:

– Гөлзадә апа, фестиваль буламы? Мин балалар алып килмәкче идем, – дип шалтыратты.

– Була, әмма акча юк, – дидем. – Карале, әгәр дә мин Ринат Әхмәтовка (ул чагында «Шахтер» футбол командасының президенты, эшмәкәр) хат язсам, тапшыра алырсыңмы?

– Тапшырырмын, – диде.

Мин төне буе утырып, бөтен җанымны салып: «Татар балаларының фестивале өзелү алдында тора, син дә татар баласы бит, ярдәм ит», – дип хат яздым. Факс аркылы җибәрдем. Иртәгесен Ренат Әхмәтов фестивальне уздыру өчен 8000 доллар акча күчерү турындагы хатка кул куйган иде... Чараны иң югары дәрәҗәдә оештыра алдык. Балаларга тартма-тартма лимонадлар, футболкалар, бейсболкалар җибәрде. Аллаһның рәхмәте яусын аңа!

Гөлзадә Сафиуллина,
Татарстан Республикасының халык артисты,
Муса Җәлил исемендәге премия лауреаты,
Кырым Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе

Ахыры киләсе санда ■

Безнең мирас №2 февраль 2021

Чал тарихка бер караш

Марат Хәбибуллин, Татарстанның атказанган артисты

Әтнә театры коллективы. 1925 ел

Үзенең байлыгы, зурлыгы, милли бию көе, такмаклары белән байтак кешеләргә билгеле булган Әтнә авылында 1918 елның актыкларында без, шул волостьтагы укытучылар, аң-белем эшчеләре татарча театр куярга ниятләдек...

Мөхәммәт Парсин

Әтнә халкы – гаҗәеп театраль халык. Ни өчен болай – Ходай үзе генә белә, тик хаклык шунда: милли сынлы сәнгать, яки, әйтик, опера, балет әлегә Әтнә якларына килеп җитә алганы юк, ә татар театры, дөньяга туып аягына басуга ук, беренче адымнарын Әтнәгә таба атлаган. Уйлап карагыз: гасыр башында дини кануннар кысаларыннан үсеп чыккан шәкертләр, алдынгы фикерле татар зыялылары мәдрәсәләрдә, аерым кешеләрнең өйләрендә качып-посып «театр уйный» башлаганнар. 1906 елның декабрендә инде татар театры үзенең дөньяда барлыгын яшермичә әйткән: Казанда беренче ачык спектакль уйналган. Ә тагын 12 елдан (тарих өчен мизгел дә түгел бу) театр әтнәлеләр капкасын шакыган. Шакып кына калганмы әле – аны тупсаларыннан алып ыргыткан! Һәм шул ерактагы, болгавыр 1918 елдан бирле Әтнәләрнең ишек-капкалары театр дигән бөек сәнгать өчен гел ачык: клуб сәхнәләрендә генә түгел, һәр йортта ул – иң сагынып көтелгән кунак, иң хөрмәт ителгән киңәшче, иң ышанычлы сердәш, иң тугрылыклы дус...

Кем белә, бәлки, театр Әтнәгә иртәрәк тә килгән булыр иде, аның Тукай туган якларга тартылуы бер дә гаҗәп түгел. Тик Герман сугышы, аннан соң революция... Тынычландык дигәндә генә, гомер ишетмәгән чехлар килеп төшкәннәр. Мәрхүмә әбием сөйли иде: «Әле аклар киләләр, әле кызыллар!.. Төсләренә карамастан, берәрсе Әтнәгә якынаюга, әткәйләр, абыйлар безне, яшь хатыннарны, кызларны, ат арбасына утыртып, Күәм ягына таба (Казаннан аргы якка), Ашыт елгасы буендагы куаклыкка качыралар иде...» Эх, дөньясы, дөньясы! Кем хаклы, кем юк икәнен йөз ел узгач та хәл итеп бетерә алмыйбыз, тик ишкәннәр инде ишәк чумарын аклары да, кызыллары да, чуарлары да...

Ниһаять, 1918 елның җәендә ак чехлар Казаннан куылгач, авылда Совет власте урнаша, август айларында Әтнәдә ярлылар комитеты төзелә. Тормыш рәтләнә төшүгә, давыллы елларда күңелнең иң тирән почмакларында яшеренеп торган, ләкин бернинди сынауда да сынмас халыкның сәнгатькә омтылышы уяна башлаган. Тик, ни дисәң дә, Әтнә – Тукай ягы шул һәм бу изге омтылыш безнең халыкта су буендагы уеннар, кич утырулар белән генә канәгатьләнә алмаган. Маркс бабайның тарихи сүзләрен үзгәртебрәк әйтсәк: «Өрәк йөргән Әтнә буйлап, театр өрәге». Һәм менә октябрь, ноябрь айларында театрны күбесе ишетеп, бик сирәге генә күреп белгән район оешмалары хезмәткәрләре, Бәрәскә, Бәрәзә, Өшкәтә, Мәңгәр, Кече Әтнә авыллары мәктәпләрендә эшләүче укытучылар – Сәгъдәт Вәлиева, Гөлсем Габдерәшитова, Габдерахман Садриев, Әминә Гобәйдуллина, Бари һәм Габделхәй Шакировлар һәм башкалар, җыйналып киңәшеп, үзешчән театр коллективы төзү турындагы фикергә киләләр. Һәр эшнең үз гаеплесе була, дигәндәй, дистәләгән еллардан Олы Әтнәнең йөзек кашына әвереләчәк театрның нигезенә беренче ташны 1918-1920 нче елларда Әтнә һәм Алат волостьларында мәгариф эшләре инспекторы булып эшләгән Мөхәммәт Парсин сала. Аның җитәкчелегендәге үзешчән артистлар Әтнәнең беренче сәхнәсенә тәүге адымнарын атлыйлар.

Мөхәммәт Парсин (1899-1963) – журналист, публицист, драматург, театр тәнкыйтьчесе. Ул милләтебезнең бик күп зыялылары, асыл егетләре кебек үк, 30 нчы еллар азагында нахакка репрессияләнгән. Аллага шөкер, исән калган, 1956 елда акланган. Гомеренең соңгы елларын Зеленодольск шәһәрендә яшәп, шунда җирләнгән. Тумышы белән Әтнә төбәгеннән, Кабакса авылыннан дип фаразлана. Ул авыл күптән җир йөзендә юк инде, аның җирләре бүген «Шахтер» хуҗалыгына карый (Әтнә муниципаль районының Комыргуҗа авыл җирлеге). Мөхәммәт, авылдан яшьли чыгып китеп, ниндидер юллар белән «Сәйяр» труппасына кушылган, профессиональ артист булган. Моның дәлилен «Развитие филологических и исторических наук в Татарии» (Казан, 1969) дип исемләнгән фәнни хезмәтләр җыентыгында театр белгече Хәсән Гобәйдуллин китерә: «Организаторами любительских трупп в татарских деревнях в первые годы Советской власти выступали, в основном, артисты профессиональных трупп. Член труппы «Сайяр» Мухаммет Парсин (по сцене Агайбаш) в деревне Олы Атня в конце 1918 года организовал Атнинскую труппу имени Владимира Ильича Ленина. 14 февраля 1919 г. она поставила «Беренче театр» («Первый театр») Г.Камала и пьесу «Мөгаллим һәм мужик» («Учитель и мужик») М.Парсина. В этой труппе принимали участие преподаватели Кече Атня, Береза и Береска...» («Татарский театр в период Октября и в годы Гражданской войны», 87 бит). Әлеге мәгълүматны табарга ярдәм иткән якташыбыз, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, фольклорчы Илгиз ага Кадыйров үзе үк сорау куя һәм аңа җавабын да бирә: *«Хәсән ага бу мәкаләне нинди дәлилләргә таянып язган? Татар театрына караган шактый китапларны актарып чыксам да, «Сәйяр» труппасында Агайбаш-*

Парсин турында мәгълүматка тап булмадым. Тик минем Хәсән ага Гобәйдуллинның бу мәкаләдә китерелгән фикеренең чын икәнлегенә бер шигем дә юк. Миңа 1968-1977 нче елларны СССР Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында сәнгать секторында Баян ага Гыйззәт, Илтани Илалова, Хәнүз Мәхмүтов, Дания Гыймранова һәм беренче булып театр белгечләре арасында сәнгать фәннәре кандидаты дәрәҗәсе алган Хәсән ага Гобәйдуллин белән эшләргә туры килде. Уфада туып-үскән бу интеллигент татар театры тарихы, бигрәк тә аның октябрьгә кадәрге чорын су кебек эчә иде. Аның архивында булган театр афишалары коллекциясе, белмим, бүген кайсы музейда бар икән.... Ә бит афиша – рәсми документ, һәр хәрефе цензор аша үтә... Әгәр бу язма дөреслеккә туры килсә, Әтнә труппасы татар театрының башлангычы булган «Сәйяр» труппасының дәвамчысы була түгелме соң? Әтнә халык театры белән Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театры арасындагы күп еллар буена сузылган иҗади дуслык шуннан башланмыймы?..»

Мөхәммәт Октябрь революциясен хуплап каршы ала, актерлыгы белән генә түгел, үткен каләме белән дә большевикларның идеяләрен алга сөрергә керешә, көн кадагына пьесалар яза. Бүгенге заман күзлегеннән караганда артык мактаулы булмаса да, чордашлары ул эшен югары бәяли: *«Мөхәммәт иптәш Парсинның басылып чыккан һәм күп уйналган комедияләреннән «Бал графинасы» белән «Ураза бәйрәмендә»се дингә каршы көрәшнең сәхнәгә килеп кергән беренче адымнары булдылар»,* – дип яза Габдерахман Сәгъди 1926 елда татар театрының 20 еллык юбилеена багышлап Казанда нәшер ителгән мәкаләләр һәм истәлекләр җыентыгына кергән «Татар театр әдәбияты һәм аның үсү тарихы» дип исемләнгән язмасында.

Тик «Татар театры. 1906-1926» (Казан, 1926 ел) җыентыгы безгә бүтән яктан кадерле. Җыентыкны төзүчеләр өчәү: М.Парсин, М.Мутин, З.Баязитский. Анда тупланган дүрт дистә язманың иң төбе (исеме буенча да, күләме һәм эчтәлеге буенча да) – «20 ел эчендә татар театры» дип аталганының авторы да – татар театрының 20 еллык юбилее бәйрәмен үткәрү комиссиясе рәисе ярдәмчесе, үз исемен татар театрына нигез салучылардан һәм аның күренекле эшлеклеләреннән булган Мөхтәр Мутин (1886-1941) һәм Зәки Баязитский (1889-1959) белән янәшә куярга батырчылык иткән шәхес – Мөхәммәт Парсин. Әйе, нәкъ шул үзе, бу вакыйгага кадәр сигез ел алдан Олы Әтнәдә театр оештырган Мөхәммәт Парсин. (Сүз уңаеннан, юбилей комиссиясен ТАССР Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы рәисенең урынбасары Шәйгардан Шәймәрданов җитәкли, комиссия секретаре атаклы актер Мөхтәр Мутин була, ә юбилей кичәсендә Татарстан Республикасының иң югары партия һәм совет җитәкчелеге катнаша.) Мөхәммәт Парсин үз мәкаләсендә Әтнә театрының беренче адымнарын да искә ала: *«Үзенең байлыгы, зурлыгы, милли бию көе, такмаклары һәм башкалары белән байтак кешеләргә билгеле булган Арча кантонындагы Әтнә авылында 1918 елның актыкларында без, шул волостьтагы укытучылар, аң-белем эшчеләре татарча театр куярга ниятләдек. Авылдагы иң зур мәктәпне сайлап алып, шуның бер читендә сәхнә урыны ясаттык. Чыпталарны бурыштыргалап, декорацияләр эшләдек, төрле кешеләрдән чаршаулар, бутафория әйберләре җыйдык. Мәктәп пичендәге формалардан грим, сарык йонынннан париклар «оештырдык». Идеологиясе алама булучылыкка карамыйча (чөнки кулыбызда идеология ягыннан яраклы булган җиңел әсәрләр юк иде әле. – М.П.), [Казан артисты] Фәхриевнең «Бәхет кошы» дигән нәрсәсенә хәзерләндек.*

Моңар чаклы театр дигән нәрсәне күрмәгән Әтнә халыклары җыелдылар. Спектакль беренче мәртәбә һәм бушка булу сәбәпле, Әтнә халкының барысы да диярлек

Спектакльдән бер күренеш. 1924 ел

килгән иде. Бу халык дулкынын басу – тәртипкә өндәү турында милиционерларга бик күп маңгай тире түгәргә туры килде.

Башладык. Караучы халыкның күңелендәге шатлану, дәртләнү, рәхәтләнү галәмәтләре дәрья кебек ташырга тотынды. Бөтен мәктәп эче туктаусыз көлү, шаркылдау тавышлары белән күмелде. Антракт вакытларындагы гармун-мандолина-скрипка «оркестры» залдагы халыкның җырлары белән кушылды. «Әпипә», «Әтнә» көйләре уйналган вакытта, йөрәгенә дәрте сыймый торган бер төркем халык, озын-озын эскәмияләрне бер читкә этеп, бер дә тартынмыйча биергә керește. Кыска гына әйткәндә, халык дулкыны үзен бөтенләй онытыр дәрәҗәгә килеп җитте.

Беренче спектакль бетте. Керә алмыйча калган халык кара болыт шикелле булганга күрә, беренче төркемне чыгарып җибәрү белән, шул ук нәрсәне яңадан кабатларга туры килде. Әле моның белән дә керә алмыйча калган халык дулкыны бетеп җитмәде.

Менә шушы рәвешле башланган эш көннән-көн тамырланды, киңәйде, алга китте, мәктәп сәхнәсен калдырып, 3-4 йөз кеше сыярлык «Ленин клубы» оештырылды. Казаннан яңа әсәрләр, гримнар, париклар кайтарылды. Киндердән чибәр генә бернича декорация эшләтелде. Укытучылар тарафыннан башланган эшкә акрынлык белән крәстиян егетләре, крәстиян кызлары катнаштырыла башлады. Театр өчен махсус реаль, яхшы-яхшы мебельләр табылды. «Бәхет кошы»ннан башланган эш «Мөгаллим», «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин», «Алдым-бирдем», «Бәхетсез егет», «Дәҗҗал» кебек шәһәр сәхнәләрендә генә уйнала торган зур-зур әйберләргә кадәр барып җитте. Соңга табан авыл яшьләренең театр эшләрендәге йогынтылары, хезмәтләре тагын да зурайды. Халыкның театрга булган карашы яхшырганнан-яхшыра барды.

Менә шушының шикелле хәрәкәтләрне миңа, Арча кантонында мәктәптән тыш мәгариф эшләре инструкторы булып эшләгән вакытта, Мәңгәр, Суыксу, Күлле Киме, Мәмдәл һәм Тукай волостьларында да күрергә туры килде; Күлле Кимедә эшләр аеручa күзгә бәрелерлек иде».

Театрның 40 еллыгын бәйрәм иткәндә. Уртада Мөхәммәт Парсин утыра. 1958 ел

1926 елда гына түгел, кайсы заманда да, китапка барын да язып бетереп булмый. Мөхәммәт Парсин да, бәян иткән вакыйгалардан соң сигез ел вакыт узгач, инде Казанда эшләгән җаваплы җитәкче, театр белгече күзлегеннән чыгып, тарихны бераз «гримлап», бизәп тә җибәргәндер. Әтнә җирендә тәүге адымнарын китаптагыча – бөтенләй кытыршысыз, шома гына юлдан атламый театр. Биеп-җырлап, мөнәҗәт әйтеп йөрү генә түгел, коры урында барлык сәнгатьләрне үзенә берләштергән ТЕАТР тудырырга кирәк бит...

Ул заман яшьләре, якты киләчәк турында еш хыяллансалар да, болытлар арасында очып йөрмиләр, театр оештыру эшен дә төптән башлыйлар: иң элек бина табу мәсьәләсен хәл итәләр. «Театр бинасы»н булдыруда район милиция начальнигы Кленцов ярдәмгә килә. Гомумән, «наганлы кеше» – иптәш Кленцовны, күпмедер дәрәҗәдә, Әтнә драмколлективының «кендек әбисе» диярга була. Заманына күрә укымышлы, зыялы кеше булгандырмы мәрхүм, әллә салкын чекист йөрәгенең яшерен бер почмагында сәнгатькә мәхәббәт чаткысы пыскыганмы, ничек кенә булмасын, оешып килгән көннәреннән үк театрны үз канаты астына ала милиция начальнигы. Ул вакытта «меценатлык» үзенчәлекле булган: революцион тәвәккәллек белән, иптәш Кленцов Әтнәнең Фазылҗан исемле баеның йортын спектакль кую өчен һәвәскәр артистларга вакытлы файдалануга алып бирә. Дөрес, Фазылҗан бай моңарчы ук «контрибуция»гә эләгә – аның зур йортының бер өлешендә, байның күпсанлы гаилә әгъзаларын, асрауларын, хезмәтчеләрен кысырыклап, мәктәп ачкан булалар. Ә хәзер менә – «төятыр»! Мескен байның хәлен аңларга була: «Үз кулларым белән тапкан хәләл малым хисабына атам нигезендә салган йортымнан урыс мәфтәге ясадылар –дәшмәдем! Югыйсә азмы Әтнәдә мәдрәсәләр?! Кызыл Әрмия файдасына дип, кашка айгырымны алып чыгып киттеләр – тешемне кысып түздем! Инде хәзер түремә кереп «төятыр» уйныйбыз, диләр! Игелекләрем, малым белән түгел, йортымда пәри туе узганы белән тарихка кереп калсам, Аллам сакласын!» – дип өзгәләнгәндер бахыр... Рухы тыныч ятсын, йөз елдан соң да искә алабыз Фазылҗан байны, нәкъ менә Әтнәдә театр туган көн белән бәйләп искә алабыз.

...Шулай итеп, Фазылҗан бай йортының зур залында сәхнә корылып, урыннар хәзерләнә. Сәхнә чаршауларыннан башлап, өстәл, урындык һәм башка барлык сәхнә кирәк-яракларын табуны да иптәш Кленцов оештыра.

Бернинди тәҗрибәсе, уйнар өчен сәхнәсе һәм кирәкле җиһазлары да булмаган коллективка эш итүе никадәр авыр булганлыгын күз алдына китерә торгансыздыр. Күпчелеге күрмәгән-белмәгән «театр» дигән нәмәрсә уйнар өчен (җитәкчеләре, «Сәйяр» артисты Агайбаш-Мөхәммәт Парсин сөйләп кенә аңлата, үзе уйнап кына күрсәтә ала, «Инстаграм»да Кариевлар уйнаган видеоны карау мөмкинлеге юк ул заманда!) эш сәгатеннән соң күрше авыллардан унар чакрымга кадәр көзге пычракны чабата белән изеп репетицияләргә йөргән энтузиастлар алдында баш иясе генә кала…

Шунысын да язып бетерә алмаган Мөхәммәт Парсин узган гасырның 20 нче елларында: баштарак спектакльләргә дә, яшьләр куйган концертларга да гади крестьяннар бик күп йөрми, хатын-кызлар исә бөтенләй килмиләр. Беренче тамашачыларның күпчелеге Әтнәнең яшьрәк сәүдәгәрләре була. Алар: «Без театр яратабыз, шуңа күрә һәр спектакльгә йөрибез. Крестьян халкы театрны яратмый һәм аңламый», – дип сөйләнәләр. Дөрес, бу хәл озакка бармый: тамашаларга акрынлап крестьян яшьләре тартыла, балаларын «шайтан туе»ннан өйгә куып кайтарырга килгән җирдән, кызыксынып, тамаша карап калган агайлар, «әстәгъфирулла»ны әйтә-әйтә булса да, үзләре үк театрга йөри башлыйлар. Авыл муллалары да, ирексездән, халыкта театр белән кызыксыну уяталар.

…Котдус хәзрәт, Мәлик хәзрәт һәм Мөхәммәтҗан хәзрәт берничә буын Әтнә халкына исем кушкан, никахлаштырган, соңгы юлга озаткан. Шәригать нигезендә әдәплелеккә дә өйрәткәннәрдер, хәмер эчмәскә, урлашмаска, гомумән, гөнаһта яшәмәскә чакырганнардыр. Тик тарихка алар, кызганыч, шушы игелекле эшләре белән түгел, ә театрга каршы коткы таратучы «кара йөзләр» буларак кереп калганнар. Әллә инде шәригать кануннарына иҗади карый белмәгәннәр (югыйсә театр сәнгате халык күңелендә шул ук әдәплелек буразналарын сөрә, «яктылыкка, нурга илтә, кире юлга җибәрми, уңга илтә»), әллә инде мулла абзыйлар, качып кына «Беренче театр»ны карап, Хәмзә бай образы белән илһамланалар… Әтнәдә икенче спектакль куелганнан соң, ак сакаллы хәзрәтләр халыкны театрга каршы үгетли башлыйлар. Тик «газзават» кире нәтиҗә бирә: моңарчы театрны, сәерсенеп, читтән әйләнеп узган кешеләр дә, «мулла хурлагач, начар әйбер булмас, бәлкем», дип, спектакльләргә тартыла башлый.

…Шулай итеп беренче спектакль 1918 елның декабрь ае ахырларында, җомга көнне Фазылҗан бай йортында куела. Ә 1919 елның февралендә «Эш» газетасында бу спектакльгә рецензия басылып чыга. «Бәхет кошы» спектакленең «идея эчтәлеге ягыннан әле бик түбән булуын» тәнкыйтьләсә дә, бу мәкалә Әтнә театрының барлыгын, дөньяда яшәвен белдергән беренче документ булып тора һәм шуның белән кадерле дә.

Әйтергә кирәк, Октябрь революциясеннән соң Мөхәммәт Парсин сыман «сәйяр»ләр чәчкән театр орлыклары Казан губернасының Буа, Минзәлә, Мамадыш, Бөгелмә кебек бик күп төбәкләрендә дә, татарлар яшәгән башка губерналарда, Урта Азия, Кавказ, Кырымда да мул шытып чыгалар. Тик бәләкәй үсенте, тамырларын тирән җибәреп, мул җимешле мәһабәт агач булып күтәрелер өчен игелекле орлык белән бакчачының тырышлыгы гына җитми, уңдырышлы туфрак та кирәк. Йөз ел элек оешкан үзешчән театр труппалары да, берничә спектакльдән, бер-ике елдан соң, бик санаулылары исә берничә дистә ел эшләгәннән соң, яшәүдән туктыйлар. Бары тик Әтнә театры гына, йөзьеллык юлны өзмичә узып, 1918нең декабрендә «Бәхет кошы» белән театр тудырган һәвәскәрләрнең тулы хокуклы варисы булып, бүген дә иҗат итә. Туфрактан килә бу, дуслар, Казан артының уңдырышлы туфрагыннан! ■

ТАТАР ҖЫРЧЫЛАРЫ. КАДЕРЛЕ МИЗГЕЛЛӘР

Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Лидия Әхмәтова укытучылар гаиләсендә алтынчы бала булып дөньяга килгән. Әти-әнисе, яше җиткән абый-апалары ул чакта җырлый, бии, нинди дә булса уен коралында уйный торган булган. Авыл бәйрәмнәрендә, концертларда гел катнашып, гадәти кичләрдә дә гармун, думбыра уйнап яшәгән гаиләдә туган төпчек кызның беренче күргән уенчыгы да караваты янындагы диварда эленеп торган саз булгандыр, мөгаен.

Авыл клубына мөдир кирәклекне уйлап, район мәдәният бүлеге мөдире Лидиягә, мәктәпне тәмамлагач, Алабуга мәдәни-агарту училищесына керергә киңәш биргән. Апастан Алабугага ара якын түгел. Кызның үзен генә җибәрергә шикләнеп, әти-әнисе аның белән бергә гармунда шәп кенә уйнаучы олы абыйсын да шунда ук укырга юллаган. Ярты ел укыганнан соң, Лидиянең киләчәге башкачарак булачагы күзалланган – аңа Казан музыка училищесына күчәргә тәкъдим иткәннәр. Ярты елга соңга калып кыш уртасында гына килеп тыңланырга уйлаган кызга училищеның иң көчле педагогларының берсе Клавдия Щербинина: «Моңа кадәр кайда йөрдең?» – дигән. Лидия икенче уку елы башыннан әлеге педагог классында укый башлаган.

Музыка училищесының тромбон классында Лидиядән бер генә курс алда укып йөрүче Казан егете Рөстәм Әхмәтов, кыз кайда гына фортепиано дәресләрен кабатламасын, ерактан булса да күзәтеп торган. Сүз кушарга кыймаган, артык тыйнак егет булган, күрәсең. Көннәрдән беркөнне Лидиягә укытучысы Клавдия Щербинина: «Обрати на него внимание, он очень хороший, воспитанный, талантливый парень», – дигән.

4 курста укыганда алар өйләнешкән. Уллары Илдар, кызлары Әдилә туган. Икесе дә музыка мәктәбе, Казан педагогика институтының музыка факультетын тәмамлаганнар. Рөстәм белән Лидия хәзерге көндә өч тапкыр әби-бабай да инде.

Лидия Әхмәтова Казан педагогика институтының (хәзер КФУ составында) музыка факультетында 30 елга якын укыта. 2006 елда ул институтта студентларыннан «Сәлам» ансамблен оештыра. Әлеге ансамбль фольклор туплау юнәлешендә зур эшләр башкара, керәшен җырларын табып, эшкәртеп халыкка җиткерә. Көннән-көн камилләшеп торучы «Сәлам» – масштаблы бәйрәмнәр, дәрәҗәле шәхесләр катнашындагы чараларның даими кунагы.

Илһам ага Шакировның керәшеннәргә аерым игътибары бар кебек тоела иде миңа. Бер мәзәктә аның үзе турында: «Монда иң карт керәшен мин», – дип шаяртуы хакында да укыганым бар. Лидия Әхмәтовага да, яратып: «Нихәл, керәшен!» – дип сәлам бирә торган булган ул.

Бу фото 1997 елда Камал театрының сәхнә артында Яңа елга багышланган концерттан соң төшерелгән. Фотосурәттә: Әлфия Авзалова, Илһам Шакиров, Лидия Әхмәтова һәм Тәлгат Әхмәтов.

Лидия Алексей кызы Әхмәтова 2014 елдан Филармония джаз-оркестрында җитәкче вазыйфасында. Оркестр репертуары, концертларны оештыру, костюмнар, инструментларны яңартып тору, клиплар төшерү һәм башка бик күп күңелле мәшәкатьләрнең берсе дә аның катнашыннан башка узмый.

Оркестрның Яңа елга багышланган программаларының башкаручы директоры да ул.

«Әгәр җырчы булмасам, йә биюче, йә табиб-терапевт булыр идем», – диде ул. Бу эшләрнең һәммәсенең дә нигезендә «дәва» төймәсе бар бит...

Журналга ***Зимфира Гыйльметдинова*** *әзерләде.* ■

Җуелмас хәзинә

«Тәфтиләү» җыры

«Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр».

Габдулла Тукай

Тәртип радиосы

Тәфтиләү

(Татар халык көе, Г.Тукай сүзләре)

И мөкатдәс, моңлы сазым!
Уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен,
Айрылабыз, ахрысы!

Очты дөнья читлегеннән
Тарсынып күңлем кошы,
Шат яратса да, җиһанга
Ят яраткан Раббысы.

«Тәфкилев» көе

«Борынгы Тәфкилев фамилияле бер мөфтинең урысча укый торган бик матур бер кызы бер француз җегетенә гашыйк була. Кыз француз җегетен, ата-анасы күрмәгән чакта, өенә дә китерә.

Бервакыт шулай, мөфти хәзрәт өендә кыз белән җегет күрешеп торган чагында, өстләренә мөфти хәзрәт үзе керә.

Кыз, аптырауда калып, үзенең мәгъшукын зур пыяла шкаф эченә яшерә.

Алай да мөфти хәзрәт җегетне күрә. Таягын алып, җегетне кыйнарга килә башлый.

Җегет исә, тиз генә шкафны ватып чыгып, тәрәзәдән сикереп кача.

Шкафны ватканда, җегетнең битенә вә кулына пыялалар керә. Идәнгә җәелгән хәтфә паласлар өстенә кайнар каннар тама...

Минем исемдә шулкадәр генә калган.

Аннан соң җегет белән кыз арасында нинди маҗаралар булгандыр, миңа мәгълүм түгел. Ләкин «Тәфкилев» көенең моңлылыгына караганда, җегет белән кыз арасында мотлак бер фаҗига булгандыр дигән фикер килә».

Г.Тукай

«Тәфтиләү» көе тарихының берничә варианты бар. Шулардан икесе морза Тәфкилевләр нәселе белән бәйле. Габдулла Тукай «Халык әдәбияты» язмасында «Тәфкилев» көе тарихын Оренбург диния нәзарәтендәге дүртенче мөфти Сәлимгәрәй морза Тәфкилев (1837-1885) гаиләсендә булган күңелсез вакыйгага нисбәт итә. Бүгенге башкорт әдәбиятчылары исә аның тарихын тагын йөз ел элегрәк яшәгән морза Котлымөхәммәт Тәфкилев эшчәнлегенә бәйли. Тәфкилев фамилиясе, үзгәрешләр кичереп, тора-бара «Тәфтиләү»гә әйләнгән булса кирәк.

Сезнең игътибарга Тәфтиләү исеменә бәйле бәет тәкъдим итәбез.

Тәфкилевләр йорты, Уфа. Тол калган Фатыйма бикә бинаны банкка арендага бирә.

Тәфтиләү бәете

Тәфтиләү байның гурничасы,
Йорт уртасында аның мунчасы.
Тәфтиләү байның кызы чукынган,
Үксеп елый аның әнкәсе.

Тәфтиләү байның икедер кибете,
Ак уканы салалар үлчәүгә.
Тәфтиләү байның кызы чукынган,
Поплар илтәләр аны чиркәүгә.

(Сәхифә «Тәртип» радиосында яңгыраган «Саф вә раушан күзге» тапшыруы материаллары нигезендә әзерләнде. Тапшыруның авторы һәм алып баручысы – Гөлфия Мөхәммәтгәрәева.) ■

Көлке куа килә...

Шамил Маннапов (1938-2012)

«Кирәкмәс шул!»

Түгәрәк юбилеенда Сибгат Хәкимгә Казан мехчылары бик һәйбәт, бик затлы бүрек бүләк итәләр. Башына ук кигереп куялар.

Юбилей кичәсенең концерт өлеше башлана. Җырчылар, шагыйрьнең үзе әйтмешли, аны «үз җыры белән сыйлый» башлыйлар. Алып баручы чираттагы җырның исемен әйтә: «Башка берни дә кирәкми...»

Шулвакыт залдан Нәби Дәүлинең карлыккан тавышы гөрләп ишетелә:

– Кирәкмәс шул! Шундый шәп бүрек бирсәләр, минем дә башыма берни дә кирәкмәс иде!..

Илдус Гыйләҗев (1946-2018)

Ярдәм итмәсме?

Өйләнешкәч, күздән йокы китә,
Башка чыгу уе тартамы?
Әллә без дә, мәйтәм, өйләндереп
Карыйкмы, дим, йончу татарны...

Илдус Гыйләҗев.
Н.Хаҗиәхмәт шаржы

Хакимҗан Халиков (1933-2002)

Ни булды, дисәм...

Өч көн инде күршем нигә
Сәлам бирми үтә, дисәм –
Хәзер бит ул «Тойота»да
Миллионерны йөртә икән.

Ф.Вахитов шаржы

Роберт Миңнуллин (1948-2020)

«Бала-чага бик тиз үсә бит ул!»

Беркөнне радиода эшләүче Лена Шәфыйкова янына шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов килеп керә:

– Лена апа, әле генә кызыбыз туды. Иртәгә алып чыгарга кирәк. Кулымда бер тиен акчам юк. Үтермә, бала чүпрәкләре алырга биреп тор инде бераз! Гонорар алу белән кайтарырмын!

Нишләсен, бала хакына дип, Лена ханым булган акчасын Мөдәррискә тоттыра. Тегесе кош тоткандай очып чыгып китә. Бер атна уза, ике атна, бер ай, ике ай...

Күпмедер гомер узгач, Лена ханым урамда Мөдәррисне очрата:

– Нихәл, Мөдәррис, кыз үсәме?

– Үсә, Лена апа, үсә! Өченче класска күчте инде!

– Ничек инде өченче класска? Әле берничә ай элек кенә туды түгелме соң кызыгыз?

– Һи-и-и, бала-чага тиз үсә бит ул хәзер! – ди дә Мөдәррис, тиз генә халык арасына кереп югала.

Локман Бадыйкшан (1919-2015)

Күңел башканы тели

Бер бабайдан сораганнар:

– Бабай, совет властена ничек карыйсың?

– Хатынга караган кебек, – дигән бабай.

– Ничегрәк инде ул?

– Әз-мәз куркам, әз-мәз яратам, кайчакта сүгеп тә куям, кайчакта мактап та алам. Шулай булса да, күңел башканы тели.

Нәҗип Мадъяров (1928-2002)

Сайлап маташмаган

Әптән Гәрәе сайлау участогыннан кайтып килә икән. Аңа Шәяхмәт очраган һәм:

– Күрше, әллә сайлап ук кайтышыңмы? – дип сораган.

– Юу-у-ук, дускаем, анда бик чибәр бер кыз, миңа елмаеп карап, өстәлдән ак, кызыл, зәңгәр бюллетеньнәр алып кулыма тоттырды. Мин аларны сайлап-нитеп тормадым, өчесен дә урнага төшердем дә җибәрдем. ■

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.*

ГЫЙНВАР

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 1 гыйнварда СССР Язучылар берлеге әгъзасы (1976), М.Горький исемендәге Бөтенсоюз әдәби конкурсының лауреаты (1985), Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1998), Татарстан Язучылар берлегенең Ф.Хөсни исемендәге әдәби премиясе лауреаты Әхәт Гаффар (Габделәхәт Габдрахман улы Гаффаров) вафат булды. Мәрхүмнең җәсәде 2 гыйнварда Курган зиратында җирләнде.

● 15 гыйнварда Актанышта «Көнчыгыш Кама аръягының тарихи-мәдәни мирасы һәм бүгенгесе» дигән темага төбәкара фәнни-гамәли конференция булып узды. Әлеге чарада Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих һәм Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтлары галимнәре – Р.Салихов, М.Гыйбатдинов, Л.Габдерәфыйкова, И.Измайлов, О.Хисамов, Р.Солтанова, төбәк тарихын өйрәнүчеләр, журналистлар, шул исәптән «Мәдәни җомга» газетасының һәм «Безнең мирас» журналының баш мөхәррирләре В.Имамов, Л.Лерон һәм әлеге басмаларның хезмәткәрләре И.Зәкиев, Л.Гобәйдуллин катнашты.

● 12-15 гыйнварда Буада «Буа Раштуа» кече фестивале (оештыручысы – Буа театрының сәнгать җитәкчесе Раил Садриев) булып узды. Әлеге фестивальдә Буа дәүләт театры Мирсәй Әмирнең «Фатыйма», Илгиз Зәйниевнең «Йорт», Искәндәр Сираҗиның «Тәүбә» драмаларын, Зифа Кадыйрованың «Бәхеткә юл кайдан?» мелодрамасын тәкъдим итте.

● 14 гыйнварда ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов Татарстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинга Татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе ярдәмендә нәшер ителгән «Татарча әлифба» китабын бүләк итте.

● 15 гыйнварда Азнакайда Һ.Такташ, Р.Төхфәтуллин, М.Хәсәнов исемендәге әдәби премияләр лауреаты, Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, милләтпәрвәр шагыйрь Илдус Гыйләҗевне (1946-2018) искә алу

кичәсе үтте. Ф.Садриев, М.Галиев, Н.Әхмәдиев, Д.Салихов, М.Гариф кебек могтабәр язучылар катнашында узган әлеге кичәдә шагыйрьгә нисбәтле «Яшәү – сөю» дигән истәлекләр китабы (төзүчесе – И.Гыйләҗевнең кызы Резеда Гыйләҗева, мөхәррире – Эльвира Ихсанова) тәкъдим ителде.

● 15 гыйнварда Мамадышта һәм Тулбай авылында күренекле татар әдибе Шәйхи Маннурга (1905-1980) нисбәтле әдәби-музыкаль чаралар булып үтте. Казаннан һәм Чаллыдан килгән бер төркем язучылар (З.Мансуров, М.Закир, М.Сафин, А.Фәлах, А.Аллабирде), шулай ук районда яшәп иҗат итүче каләм әһелләре, олуг әдипнең каберен зиярәт кылып, аның рухына дога багышлады. Язучы Камил Кәримов һәм төбәк тарихын өйрәнүче Фәрит Хисмәтов Ш.Маннур премиясенең быелгы лауреатлары булды.



● 19 гыйнварда СССР Язучылар берлеге әгъзасы (1986), Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге әдәби премиясе лауреаты, шагыйрь, журналист һәм публицист Рәфикъ Юныс (Рәфикъ Юныс улы Юнысов) вафат булды. Мәрхүмнең җәсәде аның туган авылы Кәче (Арча районы) зиратында җирләнде.

● 20 гыйнварда Татарстанның беренче Президенты, Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевкә 84 яшь тулды. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов үзенең «Instagram» битендә, Минтимер Шәрип улы Шәймиевне туган көне белән котлап: «Бергәләп эшлик һәм яшик әле, бергә җырлап алып барыйк тормышны, Минтимер Шәрипович!» – дип язды.

● 20 гыйнварда Казанның «Россия — минем тарих» мультимедиа паркында (Оренбург тракты, 8), «Республика затлары» проекты кысаларында, Татарстанның беренче Президенты, Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевкщ багышланган күргәзмә ачылды. 26 залдан торган әлеге күргәзмәдә олуг шәхескә нисбәтле фотосурәтләр һәм видеоязмалар карарга һәм Минтимер Шәймиевнең партиягә керү турындагы гаризасын, аның эш өстәлен һәм кулдан язылган автобиографиясен күрергә мөмкин.



● 20 гыйнварда Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1987), Татарстанның атказанган фән эшлеклесе (1995), «Драматические страницы истории Татарстана» (1993), «Сталин и «татарский след» (1994), «Татарстан XX век: личности, события, документы» (2003) дигән тарихи-документаль хезмәтләр авторы, күренекле галим Булат Солтанбәков 92 яшендә вафат булды. ■

МИРАСВОРД

Шарль Перро әкияте

... Зөлкарнәй



Габдулла Тукайның 1908 елда язган шигыре

Дунаев, Әюпов, Шәйхетдинов

Рафаил Төхфәтуллин повесте

Хельсинкида яши

Драматург Шәһиморат ...

Ир бала (иск.)

Борынгы Мисыр мифологиясендә – изге үгез

Марко ... (итальян сәүдәгәре һәм сәяхәтчесе)

Тавык (диал.)

Урта гасыр азәрбайҗан шагыйре

Гарәп хәрефе

Киндер сукканда кыстырыла торган җеп

Язучы Туктар, җырчы Газиев

Монгол кылычы

Мунчала тасмалардан сугылган тупас тукыма

«Җиделе лампа, бишле ...»

Язучы, «Хәзинә», «Идел кызы» романнары авторы

Күрәзәлек, юрау (иск.)

Капкын

Көнчыгышта киң таралган тынлы уен коралы

... Балакирев (рус композиторы)

Язучы ... Шабай

... Айтматов

Гаяз Исхакый повесте

... Тула (үзбәк әдибе)

Хәрби тоткын

Тию, кагылу

Бурыч, әҗәт

Тәртә бавы

Пешмәгән

Утлы күмер (диал.)

Шагыйрь ... Арсланов

Музыкант, дирижер Рөстәм ...

... Гыйззәт

Дошманны аттан егып әсирлеккә алу өчен элмәкле бау (иск.)

Борынгы грек шагыйре

Анда тукмак та бии

Винсент ... Гог

Татарстандагы район

1 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: Шабай, Муса, нәкыс, Хуҗа, торыпша, Үкәк, Ор, Гата, Авив, Нух, армада, музей, Бату, алачык, калта, какы, Кашапов, фай, Риф, Ишим, Адамс, шекә.
Өстән аска: шан, Мар, оракул, Бакиров, «Аваз», инеч, Йосыпов, Кашгарый, иде, агора, Кормаш, Кави, Мәхмүт, абак, фест, Кандалый, сәҗдә, Уатт, Кох, фрау.

Рәис Габдулла төзеде.

«Безнең мирас»
елъязмасы / февраль



Һади Такташ

240 ел элек (1781)

Вятка губернасының Сарапул өязенә караган (хәзер Татарстанның Әгерҗе районы) Иж-Буби авылында Бубилар мәдрәсәсе ачыла.

110 ел элек (1911)

Баку шәһәрендә «Ишыгъ» (Яктылык) исемле газета нәшер ителә башлый. Азәрбайҗан төркисендә чыккан ошбу атналык газетаның мөхәррире – самаралы татар Хәдичә ханым Сөбханкулова.

100 ел элек (1921)

25 февральдә Казанда Көнчыгыш халыклары өчен Югары партия мәктәбе ачыла. Ул мөселман, мари һәм чуаш бүлекләреннән тора.

95 ел элек (1926)

7 февральдә партиянең Татарстан Өлкә комитеты үзенең икенче пленумында татар телен гамәлгә ашыру турында карар кабул итә.

25 февральдән 6 мартка кадәр Баку шәһәрендә Беренче тюркология корылтае эшли. Татарлардан Галимҗан Ибраһимов анда «Төрки телләр имлясы» дип аталган нотык белән чыгыш ясый.

90 ел элек (1931)

17 февральдә 9 нчы Бөтентатар Советлар съезды ачыла. Һади Такташ съезд мөнбәреннән бу датага багышлап язган «Съезд ачылды» һәм «Безнең чор» шигырьләрен укый.

55 ел элек (1966)

Чиләбе каласында татар-башкорт китапханәсе ачыла.

15 ел элек (2006)

17 февральдә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында каһарман шагыйрь Муса Җәлилнең туууына 100 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә була. Сценарий авторы – М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты, шагыйрь Ркаил Зәйдулла. ■

*Журналга **Марат Закир** әзерләде.*

Содержание. Февраль 2021

И останется в мире слово моё...: Хакимзян Халиков.

Историческое наследие: «Печенеги». Л.Губайдуллин; «Налоги в Казанском ханстве». Н.Гариф; «Урок, преподнесенный хазарами». Ф.Нафиев; «Татары и удмурты». И.Газизуллин; «Страшный голод». Р.Шарафиева и Л.Губайдуллин.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Ориентация на вечность». И.Тагиров.

Литературное наследие: «Стихи Садри Хамида»; «Память о Хасане Туфане». А.Гаффар; «Чувство гордости». Э.Шарифуллина.

В глубинах памяти: «Записки учителя». Ф.Садыков; «В памяти, до сих пор в памяти!»

Океан воззрений: «Отчий дом». Р.Садриев; «Свет, излучаемый театром». Р.Сагди.

Художественное наследие: «Татарские певцы. Дорогие мгновения». З.Гильмутдинова

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Алхәбәр:

Ризаэддин Фәхреддин гаиләсе белән Сакмар елгасы буенда. Оренбург, 1915 ел

- **Актаныш төбәге Метрика язмаларында. Эльмира Сәлахова.**
- **Минзәлә өязе солдатлары Беренче Бөтендөнья сугышында. Лилия Габдерәфикова.**
- **Милләт бәйрәменең хөтбәсе. Ризаэддин Фәхреддин**
- **Кама аръягы төбәге тарихыннан. Нәкыйп Гафиятов**
- **Башкорт-мещеряк гаскәрендә татарлар (1798-1865). Рөстәм Әминев**

Хакимҗан Халиков — фотоларда

Х.Халиков Мөслим районының Тойгелде сигезьеллык мәктәбе укучыларына шигырь сөйли. 3 сентябрь, 1969 ел

Фотолар шагыйрь Хакимҗан Халиков (1933-2002) гаиләсе архивыннан алынды.

Шагыйрь сөекле хатыны Нурия, кызлары Зилә һәм Лилия белән. 1975 ел

Остаз шагыйрь Нури Арслан белән

Ике каләмдәш – ике бакчадаш: Хакимҗан Халиков язучы Габделхәй Сабитов белән Васильеводагы дачада. 1980 нче еллар

Мамыш авыл Сабан туенда – университеттан диплом алып кайткач. Уңнан беренче – Хакимҗан Халиков. 1960 ел

ИКЕ КАЗАН

Кизик дамбасы. 1920 еллар фотосы

Кремль транспорт дамбасы. 2020 ел. Ленар Гобәйдуллин фотосы

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

***«БЕЗНЕҢ МИРАС»* журналына башкача язылу:**
- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә электрон версия

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 51), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.